МӘГАРИФ

education

mağarif

просвещение

ТАТАР ТЕЛЕ

№1 / 2022

Оештыручысы:
«ТАТМЕДИА»
АКЦИОНЕРЛАР ҖӘМГЫЯТЕ

МӘГАРИФ education
mәgarif просвещение
ТАТАР ТЕЛЕ

МАРТ, 2022 ел

№ 1

12+

УЧРЕДИТЕЛЬ: **АО «ТАТМЕДИА».**
Телефон редакции: (843) 222-06-09

Адрес издателя:
420097, г.Казань,
ул. Академическая, 2

www.magarif-uku.ru

Создано при поддержке Республиканского агентства по печати и массовым коммуникациям.

Зарегистрирован в Федеральной службе по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций 04.09.2014 г.

Эл № ФС 77 – 59204

Периодичность выхода – 1 раз в квартал.

Мнение редакции не всегда совпадает с мнением авторов. Редакция не располагает возможностью выступать ходатаем в официальных организациях. За достоверность рекламных объявлений ответственность несёт рекламодатель.

Почтовый адрес:
420066, г.Казань, а/я 47
e-mail: magarif@bk.ru

Адрес: 420066, Казан,
Декабристлар ур., 2.
«Мәгариф» журналы редакциясе,
а/т 47
E-mail: magarif@bk.ru
Сайт: magarif-uku.ru
«Мәгариф», 2022 ел

Баш мөхәррир: **Таишева С.Н.**
Чыгаручы мөхәррир: **Фаизова Р.Г.**
Әдәби редактор: **Газизова И.М.**
Корректор: **Фәйзуллина Р.Ә.**
Вёрстка:
Зөфәрова Д.И., Шәрипова А.Г.
Беренче тышлыкта:
Алабуга шәһәренең 10 нчы мәктәбе директоры Рамил Гыйниятуллин, милли мәгариф буенча директор урынбасары Гөлнара Хөсәенова һәм Алабуга районы мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Резеда Яруллина.
Сөмбел Таишева фотосы

Журналда кулланылган фотосурәтләр «Мәгариф» редакциясе архивыннан алынды.

Журнал распространяется бесплатно.

ФАИЗОВА Р. Телне, гореф-гадәтләрне саклау – сәяси эш.....3

ЮСУПОВ Р. Телебезгә кадер-хөрмәт булсын..... 8

САБИР А. Туган телгә яшьтән салынган мәхәббәт сүрелми.....13

МИНҺАҖ Р. Гөлшат Галиуллина: «Туган телебез белән кызыксынуны арттыра» 18

МИНҺАҖ Р. Ничек язсак та ярыймы? 22

ГАЙНУЛЛИНА Г. Татар теле дәресләрендә сәнгать төрләреннән файдалану.....27

ФӘТХУЛЛОВА К., РАМАЗАНОВА Р. Туган җирем – Татарстан.....33

ҺАДИЕВА Г. Туган тел (татар) дәресләрендә сөйләм үстерү – заман таләбе 38

ЛОТФУЛЛИНА Ф. «Каюм бабай» 120 елдан соң 42

МОРТАЗИНА Л. Каюм Насыйри эшен дәвам иттерүче.....45

ЛАТЫЙПОВА А. Муса Җәлил дигән исеме, герой-шагыйрь дигән даны бар.....49

ВӘЛИЕВА Л. Кушма сүзләр..... 53

ФАЗЛИЕВА Л. Көндәлек режим. Муса Җәлилнең «Сәгать» шигыре 58

ГАЛИМУЛЛИНА З. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә кроссенс технологиясе.....64

НОГМАНОВА Г. Ничә телдә сөйләшәсең?.....68

ИШМӨХӘММӘТОВА В. Киләчәк замандагы фигыльләрнең зат белән төрләнеше.....77

МУЛЛАГАЛИЕВА Г. Рәвешләрне гомумиләштереп кабатлау. Рәвешкә морфологик анализ ясау 82

ХӘМИДУЛЛИНА А. Ренат Харисның «Сабантуй» поэмасы.....89

«Авыл укытучысы – 2022».....96

01

ТЕЛНЕ, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРНЕ САКЛАУ – СӘЯСИ ЭШ

Расиха ФАИЗОВА

ЯҢАЛЫККА ЙӨЗ ТОТЫП

Алабуга шәһәренең 1822 бала белем алучы 10 нчы мәктәбенә иртәнге якта – мәктәпнең гөр килеп торган чагында аяк бастык. Россиянең иң яхшы 500 мәктәбе исемлегенә кергән мәктәпләрнең берсе бу. Безне быелгы уку елыннан биредә директор булып эшләүче Р.Гыйниятуллин каршы алды. Рамил Мәүлет улын Түбән Камада мәгариф идарәсе җитәкчесе булып эшләгән вакыттан ук беләбез. 30 елга якын тарихы булган мәктәпкә баш итеп билгеләгәндә, биредә аның элеккеге директорлары Владимир Сергеевич Кузьмин, Роза Котдусовна Салиховалар туплап калдырган тәҗрибәгә таянып, уку йортына заманча сулыш өретүне таләп итми калмаганнардыр яңа җитәкчедән. Моңа омтылыш инде

хәзердән үк сизелә, юкса «Директорның заман таләбенә нигезләнгән төпле фикерләре, яңа идеяләре белән канатланып эшлибез»,– дияр идеме педагоглар. Профильле сыйныфлар ачу; югары квалификация категорияле, үз эшен яратып башкаручы, тәҗрибәле педагогларга уңайлы эш шартлары, югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлекләр тудыру; грантлар отып, мәктәпне заманча техника белән тәэмин итү; укытучыларның үзбелемен күтәрүгә даими игътибар бирү; ата-аналар белән кулга-кул тотышып эшләү үз нәтиҗәләрен бирми калмаган. Мәктәп Бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре буенча да, төрле конкурс, олимпиадаларда, спорт ярышларындагы җиңүләре буенча да шәһәр күләмендә үзен күрсәтә алган. Киләсе елдан 5 нчеләрдә лицей сыйныфы ачу да күз уңында тотыла икән. Тәҗрибәле укытучыларга таянып, олимпиада хәрәкәте шулай ук яңа күтәрелеш кичереп, инде республика күләмендә дә призлы урыннар күренә башлаган. Рамил Мәүлет улы исә тарих һәм җәмгыять белеме белән кызыксынучы укучыларны үз тирәсенә туплаган.

– Укучыларның үзидарә эше дә җайга салынды. 7–10 нчы сыйныф укучылары белән «Мәктәп сенатын» булдырдык, мәктәпнең үз символикасына бәйге игълан ителеп, анысын да эшләдек, – дип сөйли укытучылар.

Быелгы кыш егетләр хәтерендә мәктәп яны хоккей мәйданчыгы ачылу белән генә түгел, ишеп-ишеп яуган карлары белән дә истә калыр, мөгаен. Уйныйсың килсә, кулыңа көрәк тотмый хәлең юк. Җитмәсә, башлап директор үзе үрнәк күрсәтсә, ничек инде бу эштән читтә калмак кирәк.

– Дәрескә соңга калучылар белән көрәшкә дә чыккан әле ул быелгы кар. Соңга калучы югары сыйныф укучыларын акылга утыркан ул, ә кечкенәләр китапханәдә китапларны тәртипкә китереп, үз хаталарын төзәтергә мәҗбүр булганнар. Нишлисең, һәркем үз гамәле өчен җавап бирергә тиеш. Ә инде сыйныфта соңга калучы юк икән – бүләк отасың. Андыйлар шимбә көнне үзе теләгәнчә киенеп килә. Бу да тәрбия чарасы,– диләр укытучылар. Мәктәпнең Георгиев паркы белән ут күршеләр булып торуы да файдага гына: практик дәресләр, тәрбия чараларына шунда чыгалар.

МИЛЛИ ТӘРБИЯНЕ КЕЧКЕНӘДӘН

Укытучылар белән фикер алышканнан соң, безне әле «аулак өй» гә дә чакырмакчылар икән. «Аулак өй»гә киткәнче милли мәгариф буенча директор урынбасары, тумышы белән чын татар төбәге Сарман районы Татар Карамалы авылыннан булган Гөлнара Халис кызы Хөсәенова белән сөйләшеп алабыз. Ул мәктәптә һич кенә дә очраклы кеше түгел. Укытучы һөнәренең җиңел эш түгеллеген дә, шул ук вакытта иң абруйлы һөнәр иясе икәнен дә кечкенәдән белеп үскән. Чөнки әнисе Фәүзия Хәмит кызы Сафина – 30 ел буена балаларга белем биргән, тормышка юл күрсәткән мөхтәрәм укытучыларның берсе.

– Мин үземнең татар булуым белән горурланып яшим. Туган телемдә сөйләшү күңелемне иркәли, татар җыры, татар моңы авыр кичерешләрдән арындыра, рухи биеклекләргә күтәрә. Бүгенге көндә әти-әниләр һәм укучыларның 76%ы татар телен өйрәнүгә теләк белдерде, бу сан көннән-көн арта бара: уку елы дәвамында әти-әниләр татар төркемнәренә күчерүне сорап мөрәҗәгать итәләр,– дип башлый ул сүзен,– 9 тәрбия классы ачтык, бу тәрбия сыйныфлары белән мәктәп,

шәһәр, район күләмендә төрле милли чаралар үткәрәбез. Рус мәктәбе булуга карамастан, укучыларыбыз татарча бик теләп сөйләшәләр.Татар теле укытучыларыбыз татар телен һәм милли гореф – гадәтләрен саклап калу ниятеннән театр төркеме оештырып шәһәр күләмендә фестивальләр уздыру инициативасы белән чыгалар. Үз телен белгән кеше генә аның моңын, аһәңен аңлый, тоемлый. Татар телендә чиста, дөрес итеп сөйләшкән кеше һәммәбезне сокландыра. Аны тыңлап торуы күңелле. Ә үз телен санга сукмаган кешедән сорыйсы иде:

Телсез кем соң син? – дип.

Җавабым да бар:

Хәтерсез таш... Халыксыз, тарихсыз, язусыз, язмышсыз...

АУЛАК ӨЙ

Чигүле түрләмәләр, тәрәзә пәрдәләре, җете япмалар белән бизәлгән бу залга кем генә керсә дә бер мәлгә өнсез калыр кебек. Мондый матурлыкны чып-чын татар бизәкләрен күрсәң дә, бик сирәк авылларда гына күрергә була хәзер. Ә биредә таслап тутырылган бер сандык андый кул эшләре. Авыл түгел, ә Алабуга шәһәре мәктәбендә бит бу! Укытучылар Гәрәева Розалия Мазхар кызы белән Галиева Гөлфия Равил кызы «Аулак өй»нең бөтен матурлыгын сеңдерергә омтылганнар балаларына. Милли киемнәрдән килгән кызлар кич утырып, чигү чиксә, малайлар да егетлекләрен күрсәтергә тырышты. Бергәләп җыр-

ладылар, биеделәр, Интернет оныттырган «Түбәтәй», «Йөзек салыш» кебек уеннарны хәтердә яңарттылар, тел байлыкларын мәкаль-әйтемнәрдә чарладылар.

Бәйрәмгә әзерлек барышында кызларда чигү эшенә кызыксыну арткан. Әбиләренең сандыкларында сакланып калган чигүле сөлгеләр, ашъяулыклар, мендәр тышлары алып килүчеләр дә булган.

– Мондый бәйрәмнәр балаларда халкыбызның электән килгән гореф-гадәтләре, милли йолалары, халык авыз иҗаты белән якыннан таныштыруны, сөйләм телен үстерерү, баланың йокымсырап яткан иҗади мөмкинлекләрен ачуны күздә тотып уздырыла. Укучылар инде хәзердән үк тагын нинди бәйрәм үткәрәбез, дип кызыксыналар, – ди 36 ел гомерен яраткан эшенә багышлаган укытучы Гөлфия Равил кызы.– Бу юнәлештә эшлибез. Мәсәлән, «Сабантуй» бәйрәмен без укучыларыбыз белән берлектә бөтен шәһәр тамашачысына күрсәттек. «Сөмбелә», «Нәүрүз» бәйрәмнәре әти-әниләр, әби-бабайлар катнашында зурлап үткәрелә. Узган ел уздырылган «Әбием-әбекәем» кичәсе өлкәннәребезнең күңеленә хуш килде. Бәйрәм кичәсен карарга балаларның әбиләре ерак авыллардан да җыелдылар. Киткәндә: «Мондый чаралар-да тагын очрашырга язсын!» – дип, безгә, укытучыларга, зур рәхмәт әйтеп саубуллаштылар. Нәкъ менә шундый чаралар укучыларның сөйләм телен үстерергә, милли үзаң формалаштырырга ярдәм итә. Мәктәбебезнең милли белем бирү сыйныфында эшләү, минем өчен рәхәт тә, зур җаваплылык та, – дип сөйли ул.

Укытучы эшенең никадәр катлаулы, авыр хезмәт булганын белеп, күреп үскән Гөлфия ханым. Чөнки әнисе Фәтхуллина Резедә Нәҗип кызы Кукмара төбәгендә дүрт дистә ел буе балалар укыткан. Шул ук вакытта ул әнисенең кешеләр арасындагы абруе зур икәнен дә, хезмәте аңа куаныч китергәнен дә күреп, белеп торган. Шуңа күрә дә кечкенәдән укытучы булырга хыялланган.

– Безнең үзебезне дә кечкенәдән гаиләдә милли гореф-гадәтләрне саклап, йолаларны үтәп яшәргә өйрәттеләр (ул тумышы белән Мамадыш районы Түбән Тәкәнеш авылыннан. – *Ред.*). Халкыбызның уен-йолалары, татарча шигырьләре, җырлары аша укучыларымның күңеленә бөек шәхесләребез белән горурлану хисләре салырга, үз туган телләрен яратып, кызыксынып өйрәнүләренә ирешергә тырышам. Балага бу дөньяда яшәп китү өчен кирәкле белемнәрне бирү, аны яхшы шәхес итеп тәрбияләү – минем төп максатларымның берседер, мөгаен,– дип, коллегасының сүзен куәтли әлеге мәктәптә 24 ел башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләүче Розалия Мазхар кызы.

Әйе, әлеге мәктәп рус телендә гомуми белем бирү учреждениесе булуга карамастан, биредә татар телендә милли тәрбия сыйныфлары ачуга аеруча басым ясала. «Җитәкчеләребез белән берлектә әти-әниләргә аңлату эшен балалар бакчасыннан ук башлыйбыз, туган телнең бала өчен ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңлатабыз», – диләр укытучылар.

Сөмбел Таишева фотолары

Әлеге QR-код ярдәмендә язманың видео вариантын карый аласыз

02

ТЕЛЕБЕЗГӘ КАДЕР-ХӨРМӘТ БУЛСЫН

Рүзәл ЮСУПОВ,

академик, филология фәннәре докторы

Татар теле хәзер милләттәшләребезнең күбесе уйлаганнан кыенрак хәлдә. Дөресрәге, аларның күпчелеге туган телләренең бүгенге торышы, язмышы өчен бик борчылмыйлардыр да: күп кешенең уенда матди хәлен, тормышын, ашау-эчүен, кием-салымын яхшырту һәм яшәешендә башка төрле уңайлыклар булдыру. Беренче карашка, аларны моның өчен гаепләп тә булмый кебек: кешенең иң беренче ихтыяҗы – тамагын туйдырып, өстен-башын карау. Әмма бу – адәм баласының асылына, табигатенә гадиләштерелгән, примитив караш. Кеше биологик җан иясе генә түгел, бәлки иҗтимагый шәхес тә: аның матди ихтыяҗларыннан тыш, күптөрле рухи хаҗәтләре дә бар бит әле. Югары цивилизация кешесе – культуралы җәмгыять әһеле, димәк, аның матди кирәк-яраклары белән бергә мәдәният өлкәсенә караган ихтыяҗлары да күп була: ул белемен камилләштерә, культуралы ял итә, мәдәният хәзинәләрен үзләштерә (музыка, сәнгать, әдәбият белән шөгыльләнә һ.б.), һәртөрле рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә.

Рухи хәзинәләрне булдыру, алардан файдалану исә телдән башка мөмкин түгел. Татар халкының иҗтимагый тормышы, мәдәнияте, мәгърифәте, прогрессы аның туган теле – татар теленә нигезләнгән. Димәк, безнең туган телебез матди ихтияҗларыбызны үтәүгә ярдәм итү белән бергә, югары мәдәниятле рухи тормышыбызны коруга да хезмәт итә.

Шулай булгач, телгә көнкүрештә, гаиләдә гади аралашу, аңлашу чарасы итеп кенә карарга ярамый, тел ул – югары мәдәниятле кешелек җәмгыятенең уңышлы яшәве өчен иң әһәмиятле, хәлиткеч нәрсә.

Тел – кешелек җәмгыятендә беренче дәрәҗәдә мөһим, могҗизалы, илаһи күренеш. Ул – кешелек җәмгыятен барлыкка китерүдә, барлык матди һәм рухи хәзинәләрне булдыруда, кешене гади биологик җан иясеннән югары акыл һәм хис иясенә әверелдергән иң беренче, төп нәрсә. Тел төзелеше белән никадәр катлаулы һәм камил булса, чиксез күптөрле вазифалар башкаруы белән дә искиткеч күренеш тәшкил итә.

Һәр милли тел, камил аралашу коралы булу белән бергә, кешеләрнең югары интеллектуаль зиһенен эшләтү, катлаулы хис – тойгыларын белдерү чарасы да, халыкның телендә аның милли психологиясе, рухи үзенчәлекләре, тарихы, менталитеты чагылыш таба. Халыкның мәдәнияте барыннан да бигрәк аның туган теле ярдәмендә барлыкка килә һәм үсә. Аның алдыңгы милләт булып формалашуының нигезендә камил әдәби теле ята. Һәрбер халыкның миллилеге аның туган теле ярдәмендә барлыкка китерелә һәм саклана.

Ниһаять, туган тел ул – ата-анаңның, әби-бабаларыңның хәтерен, игелеклелеген саклап тору чарасы. Татар теле ата-анаңны, әби-бабаңны, кардәшләреңне, нәсел-нәсәбеңне хөрмәтләү чарасы булганлыктан, халык аны кадерләп ана теле дип атаган.

Хәзер менә шушы татар халкының гаять зарури, иң мөһим, могҗизалы, күркәм туган теленә милләттәшләрнең барысы да кадер-хөрмәт күрсәтәме, аңа милләтебез өчен үтә кирәкле нәрсә итеп карыймы икән? Юк шул, һич кенә дә юк. Туган телләрен санга сукмаган, аңа битараф һәм ваемсыз карашта торган татарлар күп һәм андыйларның саны арта бара. Татарстан президенты карамагындагы татар телен саклау һәм үстерү комиссиясенең рәсми мәгълүматларына караганда, республикабыздагы татарларның яртысыннан күбрәге үзара рус телендә аралаша: татарча начар белә яки бөтенләй белми һәм өйрәнергә дә теләми. Күп татар ата-аналары рус мәктәбендә укучы балаларын туган тел дәресләренә йөртергә теләми, үзләре исә татар китаплары, татарча газета-журналлар укымый, үз телендәге радио-телевидение тапшыруларын тыңламый һәм карамый.

Татарча газета чыгаручылар, телевидение тапшырулары әзерләүчеләр туган телне нык бозалар, мәгълүмат чаралары теле көннән-көн русчадан тупас калькалаштырылган, корама телгә әверелә бара. Телевидение тапшыруларында катнашучыларның татар телен бозып-җимереп кулануларын тыңлап, татарча газеталардагы тупас мәгънә һәм тел ялгышларын күреп, йөрәк әрни, күңелдә рәнҗү хисләре кабына.

Бу фикер буш сүз генә булып калмасын өчен, бүгенге көндә язма һәм сөйләм телебездәге меңләгән тупас тел ялгышларының кайберләрен генә булса да күрсәтеп китәрбез. Алар күптөрле: кайбер сүзләр һәм әйтелмәләр ялгыш мәгънәдә кулланыла, телнең табигый төзелеше бозыла: газеталарда, телевидение тапшыруларында сүзләрнең мәгънәле бәйләнеш кагыйдәләре (нормалары) һәм аларның грамматик бәйләү чаралары ялгыш кулланыла, татар теленең табигый сүз төзелеше бозылып, татарча сәер, аңлаешсыз сүзләр ясала, җөмләдәге сүзләр тәртибе ялгыш билгеләнә, урынсыз рус алынма сүзләре һәм искергән гарәп-фарсы сүзләре кулланыла, табигый авазлар бозып әйтелә һәм башка төрле тел чатаклыклары хөкем сөрә. Менә быелның 18 июнендә ТНВ каналында «Яшьләр тукталышы» тапшыруында катнашучылар шулай сөйләштеләр: «*Мин шулар белән кызыктым...*» «*Аларга нинди вопрос белән килсәләр дә...*» Тапшыруны алып баручы *хәм (һәм), хөнәр (һөнәр), Әлмәт шәхәрендә (шәһәрендә), хәрвакыт (һәрвакыт)..., «кабул итеп алдыр дагын», «Әлмәт текә шәхәр», «Татарстанның хәрбер шәхәре текә шәхәрләр*». «Башваткыч» тапшыруында катнашучы *каһарманнар урынына «кахарманнар» (каһарманнар*) дип сөйли. Татар теленең **h** авазын күп кешеләр, шул исәптән телевидение хезмәткәрләре дә, әйтә белми, аны **х** белән алмаштырып сөйлиләр.

«Ачыктан-ачык» тапшыруында катнашучы

«Иногда вот экспромптым да чыга инде» дип, ансамбль солисты Илдар «какой-то бер...», «вакытым җук» дип сөйли.

Мондый йөзне кызартырлык татарча әңгәмәләр еш була Казан телевидениесе тапшыруларында. Телебезне болай ботарлаучылар радио-телевидение тапшыруларында катнашырга тиеш түгел, әлбәттә.

Хәзер татар теленең дөреслегенә, сафлыгына иң зур куркыныч матбугат язмаларыннан килә. Һәм монда иң хәтәр, иң яман, күңел кайтаргыч хәл шул: телне тупас һәм күпләп бозып язу күренешләре, кечкенә форматлы, аз санлы район һәм хосусый газеталардагыга караганда, республика күләмендә чыга торган дәүләт газеталарында күбрәк. Бездә бу басмалардан, , шул исәптән республиканың татарча төп газетасыннан, алынган тел ялгышларына мисаллар меңнәрчә. Хәзер шуларның соңгы бер-ике айда дөнья күргәннәреннән аеруча гыйбрәтләләрен күрсәтеп китәрбез. Бу мәсьәләдә шунысы бигрәк тә аяныч: газета телендәге тупас ялгышлар күп еллар буена дәвам итеп килә: журналистларның күбесе телне начар белә һәм яхшы белерлек итеп өйрәнергә дә теләми. Хәлбуки өйрәнер өчен материаллар җитәрлек: соңгы елларда бу юллар авторының гына да бүгенге мәгълүмат чараларында телне бозып кулануга караган меңнәрчә мисалларга анализ ясап, ялгышларның барлыкка килү сәбәпләрен күрсәтеп һәм төзәтеп язылган йөзләрчә мәкаләләре, дистәләрчә китаплары басылып чыкты. Әмма журналистлар аларны укымый, телне үзебез дә яхшы беләбез, дип уйлыйлар, күрәсең. Язмалары исә мондый фикернең дөрес түгеллеген һәм каләм ияләренең күбесенең татар телен тиешле дәрәҗәдә белмәвен күрсәтә.

Журналистлар кайчакта, үзләре кулланган сүз-әйтелмәләрнең төгәл мәгънәсенә төшенеп җитмичә, тупас мәгънә хаталары җибәрәләр. Мәсәлән: *«Әле газетабызның алдагы саннарының берсендә генә мошенниклар кулыннан алданган ялгыз ана турында язып чыккан идек».* Алда (киләчәктәге, киләсе. – *Р.Ю.*) буласы (димәк, әле булмаган) эш-хәл турында ничек язып чыгып була? Журналист *алдагы* сүзен ялгыш мәгънәдә кулланган: «*... элекке саннарның берсендә...*» диярга кирәк иде. «*Коронавирус бирмәгән сабак».* «Коронавирус бирмәгән сабак» түгел, Коронавирус биргән, ләкин ул сабакны кемдер ала белмәгән: «*Коронавирустан сабак ала белмәгән»* кебегрәк итеп язарга кирәк иде. «*...республикада Коронавирус белән 26,8 мең кеше авырган, шуларның 23,1 меңе терелгән». Терелүнең* төп мәгънәсе – үлгәннән яки үлем чигенә җиткәннән соң тагын яши башлау. Монда *«шуларның 23,1 меңе савыккан яки сәламәтләнгән» диярга кирәк иде.*

«*Иртә яздан башланган эш кар төшкәнче дәвам итә».* Дөресе – «*Яз башында ук керешкән (тотынган) эш...*» «*Математика һәм табигый фәннәр белән кызыксынганга күрә...*» Бу җөмләдәге *табигый фәннәрдә* тиешле мәгънә тупас бозылган: «табигать фәннәре» булырга тиеш. «*Уҗым бодае – муллык чыганагы».* Сүз көзге бодай уҗымы турында бара булса кирәк: аны шулай атарга кирәктер дә. «*ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары».* Бу җөмләнең авторы *тормыш кыйпылчыкларының* нәрсә икәнлеген һәм нинди булуын үзе аңлыймы икән?

Безнең телебез соңгы елларда аеруча каләм ияләренең сүзләрнең сөйләмдә үзара мәгънәви бәйләнешкә керү үзенчәлекләрен исәпкә алмау яки аларны белмәү аркасында бозыла. Бу телебезнең табигый төзелешенә, ягъни аның асыл сыйфатына зур зыян китерә.

«*Чишмәле авыллар картаймый»* дип яза җитди статуслы республика газетасы. Ләкин *картаю* сүзе, гадәттә, җанлы нәрсәләр исемнәре белән генә табигый мәгънә бәйләнешенә керә: *кеше картая, хайван картая*. Ә җансыз нәрсәләргә карата бу сүз урынына *искерә, туза* кебек сүзләр кулланыла («*Чишмәле авыллар искерми*»).

«*Сак булыгыз: ялган бал*!» дип кисәтә икенче бер газета. Әмма *ялган* сүзе *бал* сүзе белән табигый мәгънә бәйләнешенә керә алмый; ул мәгънәне чын татарча «*кушылмаган бал*» яки *чын (табигый) бал* әйтелмәсе белдерә.

«*Белгечләр йөрәк-кан тамыры авыруларын кисәтү өчен түбәндәгеләрне истә тотарга киңәш итә».* Татар телендәге сүзләр бәйленеше кагыйдәләре буенча *кисәтү* кешегә (зат исемнәренә) карата гына кулланыла ала, җансыз нәрсәләр белән бу мәгънә мөнәсәбәтен башка сүзләр белдерә: «*...йөрәк-кан авыруларын булдырмау (булдырмый калу)», «йөрәк-кан авыруларыннан саклану»* һ.б.кирәк.

Сөйләмдә сүзләрнең үзара мәгънәле бәйләнеше үзенчәлекләрен исәпкә алмау аркасында соңгы елларда безнең мәгълүмат чараларында татарча табигый булмаган йөзләрчә тәгъбирләр барлыкка килде, һәм андыйларның саны көннән-көн арта бара. Мәсәлән: «*Төньяк Америкада бик салкын һава торган».* Саф татарча *«...һава яки көн бик салкын булган». «...тик сәләтле балаларны ачыклау, ярдәм итү өстендә эшләргә кирәк». Өстендә эшләү* –русчадан тупас ялгыш калька, дөресе – «*...балаларга ярдәм итү белән шөгыльләнергә кирәк». «Хәзерге вакытта анда шундый закон өстендә эшлиләр икән».* Дөресе*: «...шундый закон әзерлиләр икән». «РИА Новости» агентлыгы Россиядә сәламәт яшәү рәвеше алып барган халык яшәгән төбәкләрне ачыклаган».»...сәламәт яши торган халык гомер иткән төбәкләрне ачыклаган»* дисәң, табигый булыр иде*.»...мөнәсәбәтләрне Блинкен ике ил лидерының алда торган очрашуы күзлегеннән*

чыгып бәяләгән». Нинди мәгънәсез әйтелмә бу – *«күзлегеннән чыгып бәяләү»*. «*...очрашуына (яки очрашуның ничек булачагына) карап бәяләгән»* кирәк. «*Төркия хөкүмәте... Россия белән авиаэлемтәләрне туктатырга чакыра*». Монда бернинди дә *чакыру* сүзе булырга тиеш түгел: «*...авиаэлемтәләрне туктатып торырга өнди (яки туктатып торырга кирәк, ди»*) булырга тиеш. «*...поезд сәгатенә 70 чакрым тизлек белән хәрәкәт итә ала*». Ниндидер бөҗәк яки техника детале хәрәкәт итә диләр, ә *поезд йөри, бара*.

Республиканың төп газетасының 14 сентябрь (2021 ел) санында «Күңелдә бер үпкә калды» дигән исем белән бастырылган кечерәк кенә бер мәкаләдә 7 җөмлә *кыскарту* сүзе белән язылган: «эштән кыскартылган татар теле укытучысы...», «ике бала белән кыскартуга эләгү...», «татар теле дәресләре кыскарган», «кыскартулар турында хәбәр иттеләр», «татар теле сәгатьләрен кыскартып...», «укытучыларны кыскарту-кыскартмау мәсьәләсе...», «бер укытучыны да кыскартмадык». Менә ул русчадан тәрҗемә итә белмәү, телләрнең үзенчәлекләрен күрмәү, сүзлек запасының фәкыйрьлеге, гади генә эчтәлекле хәбәрне коры, казённый тел белән язу үрнәге. Безнең телдә бу тексттагы русчадан *сократить* сүзен уңышсыз калькалаштырып алынган *кыскарту*ны табигый яңгырашлы, күңелгә ятышлы итеп бирерлек әллә ничә сүз бар, бераз башны гына эшләтергә кирәк. Мәсәлән, ««*Эштән кыскартылган татар теле укытучысы Альбина Киселева*» җөмләсен «*Эшсез калдырылган* яки *эштән чыгарылган Альбина Киселева*» дисәң, фраза татарча ятышлырак булыр иде.

Безнең тел мәгълүмат чараларында да, башка төрле материалларда да сөйләмдә сүзләрнең үзара мәгънә бәйләнешенә керүгә хезмәт итә торган грамматик чараларны дөрес кулланмау аркасында да нык бозыла. Бу мәсьәләдә дә журналистларның телебезне тиешенчә белмәве һәм игътибарсызлыгы ачык чагыла. Соңгы бер-ике айда чыккан газеталардан алынган дистәләрчә мисалларның берничәсен генә күрсәтү белән чикләнербез.

Безнең телдә гадәттә *уртаклашу, бүлешү* сөйләмдә үзләренә ияреп килгән сүзләр белән баш килеш формасы (сүзләр янәшә торганда) һәм төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнә: *фикер уртаклашу, кем беләндер ниндидер фикерне уртаклашу, мал бүлешү, кем беләндер уртак малны бүлешү*. Һәм менә үтә гаҗәп хәл: соңгы вакытларда газеталарда *уртаклашу, бүлешү*гә ияреп килгән сүзләрне аларга *белән* сүзе ярдәмендә бәйләп яза башладылар: бу – рус телендәге шундый мәгънәле сүзтезмәләрне татарчага ялгыш механик рәвештә калькалаштырып алу нәтиҗәсе. Мисаллар: белгәннәре белән уртаклашты (чын татарча – белгәннәрен уртаклашты), үз тәҗрибәсе белән уртаклашты (дөресе – тәҗрибәсен уртаклашты), әзерләү серләре белән уртаклашты (әзерләү серләрен уртаклашты), уңай тәэсирләр белән уртаклашты (уңай тәэсирләрен уртаклашты), үзенең шатлыгы белән бүлешми түзә алмый (шатлыгын бүлешми түзә алмый).

Безнең телдә *кызыксыну* сөйләмдә үзе иярткан сүзгә *белән* бәйлеге ярдәмендә бәйләнешкә керә. Соңгы вакытларда кайбер каләм ияләре телебезнең бу катгый кагыйдәсен дә (нормасын да) тупас бозарга батырчылык итәләр: *туган телне өйрәнүгә кызыксынуны арттыру* (дөресе – *туган телне өйрәнү белән кызыксынуны арттыру), фәнгә карата кызыксынуны уятырга тырышам (фән белән кызыксынуны...). Җирнең бердәнбер иярчененә кызыксынулар бик күп тапкырга артты гына («... иярчене белән кызыксыну...артты гына» кирәк). Кешеләрнең сайлауга булган кызыксынуы көчле (сайлау белән кызыксынуы).*

Шуу сөйләмдә үзенә иярткән сүзгә баш килештәге исем ярдәмендә бәйләнә: *чана шуу, чаңгы шуу*. Хәзерге журналистлар бу кагыйдәне дә санга сукмый башладылар. Мәсәлән, «Анда төрле илләрдән килеп *чаңгыда шуалар*» (*...чаңгы шуалар* кирәк).

Рус теле әйтелмәләрендәге **под** предлогын ялгыш **ас(т)** бәйлеге белән тәрҗемә итү аркасында барлыкка килгән тупас хаталар күп: «татар мәктәпләренең эшчәнлеген *күзәтү астында* тота» (чын татарча: «татар мәктәпләренең эшен *күзәтеп тора*»). «Хәзер алар реанимациядә тәүлек буе *күзәтү астында* ята» («*...күзәтүдә ята*» булырга тиеш). «Төрле сәбәпләр астында районнарда яшереп кенә оптимальләштерү дәвам итә» (чын татарча: «Төрле сәбәпләр белән яки төрле сәбәпләр табып (уйлап чыгарып...) «470 ел буе изү астында яшәп...» (Дөресе: «470 ел буе изүдә (изелүдә) яшәп...»).

Рус телендәге **за** предлогын урынсыз **арт** бәйлеге ярдәмендә тәрҗемә итеп ясалган тәгъбирләр дә телебезнең катгый кагыйдәләренә каршы килә: «*Түгәрәк өстәл артына утырып сөйләшү». «Түгәрәк өстәл артында сөйләшүдән соң...». Түгәрәк өстәлнең* арты, алды буламы икән соң? *Түгәрәк өстәл янында* булырга тиеш, әлбәттә.

Татар халкы гомер-гомергә *туп уйнау, курчак уйнау, гармун уйнау* h.б.ш. дип сөйләшкән, ягъни безнең телдәге сөйләмдә *уйнау* сүзе үзенә ияреп килгән сүз белән баш килештә һәм төшем килешендәге кушымча (сүзләр янәшә тормаса) ярдәмендә бәйләнешкә керә. Ләкин хәзерге журналистлар, рус теле нормасын кулланып, телебезнең бу кагыйдәсен дә үзгәртә башладылар. Хәзер инде алар телендә гармун, баян, скрипка h.б. уйнамыйлар, бәлки (*играть на гармони, на баяне, на скрипке* өлгесендә) *гармунда, баянда, скрипкада* уйныйлар. «Америкада Барбара Шур, *пианинода уйнап*, 1852 җырны яттан җырлый». Телнең табигый төзелешен бозып, аннан баш тартып, чит тел үрнәген кабул итүнең кемгә кирәге бар икән? Үз белдеге белән телне бозарга беркемнең дә хакы юк!

Телебездәге табигый сүз бәйләнеше чаралары бу җөмлә һәм тәгъбирләрдә дә тупас бозылган: «Әти *телефон белән куллана* белгән...» («Әти *телефонны куллана* яки *телефоннан сөйләшә* белгән...» кирәк); «*Мөмкинлекләрне файдаланып* калыгыз» (дөресе – «*Мөмкинлекләрдән файдаланып* калыгыз»); «Менә мин *шул турыда мактанырмын*» («... *шуның белән мактанырмын*» кирәк); «...калганнары исә һаман да *томан артында кала*» (ни өчен томан артында кала? Томанның арты-алды кайда була аның? – «*томан эчендә кала*» дип әйтергә кирәктер); Республиканың төп газетасының (статусы буенча беренче газетасының. – *Р.Ю.*) 26 май һәм 27 июль саннарындагы «*Якшәмбе участокта көтәләр», «Яшелчә шимбә арзаная*» дигән информацияләрнең мондый исемнәрен ничек аңларга? «*Якшәмбедә* яки *якшәмбе көнне участокта көтәләр», «Яшелчә шимбә көнне* яки *шимбәдә арзана*я» дип әйтергә теләгәндер, бәлки, автор? Мондый язмалар республикабызның беренче дәрәҗәдәге дип саналган газетасында түгел, начар укучыларның язмасында гына очрарга мөмкин лабаса!

Безнең каләм ияләре сәгать исәбен татарча дөрес әйтергә кайчан өйрәнерләр икән, өйрәнерләрме икән? «Чара... *14 сәгатьтә* башлана» (ни өчен *сәгать 2 дә* түгел?). «...*10 нан 13:00 сәгатькә* кадәр...аралашабыз». Чын татар кешесе «...*сәгать 10 нан 1 гә кадәр* ...аралашабыз» дип әйтер иде.

Журналистларның кайберләре, татар телен яхшылап өйрәнеп, язмаларында аның бай мөмкинлекләреннән тулы файдаланасы урында, халыкка аңлашылмый торган искергән сүзләрне кулланылышка кертеп һәм, телебездәге сүз төзелеше кагыйдәләрен бозып, яңа сүзләр ясау белән шөгыльләнеп маташалар. Шундыйлардан бик мәгънәсез һәм ялгыш ясалган, шулай да журналистлар яратып куллана торган сүз – *ассызыклау*. *Дәүләтчелек* тә шундыйлар исәбеннән. Болар һәм башка «гарип» сүзләр турында безнең язмаларыбызда инде күп әйтелде: кабатлап тормыйбыз. Ә менә бу матбугатта соңгы көннәрдә генә күренгән «*Теләнмәгәннәр арта*», «Русия (ни өчен Россия түгел? – *Р.Ю.*) Юстиция министрлыгы *теләнмәгән оешмалар* исемлегенә тагын 5 оешманы керткән» дигән җөмләләрдәге **теләнмәгән** дигән сүзне ничек аңларга икән? Татар телендә моңарчы андый сүз юк иде. Әсәрләрен «Ватаным Татарстан»да бик актив бастырып килүче мөхтәрәм язучы Марат Кәбиров газетаның 14 июль санында «Минем абый бар. Икетуган» дип язган. *Икетуган абый* кем һәм нинди буладыр: беләсе иде. Безнең телдә моңарчы *икетуган абый* дигән сүз юк иде: ике туып та булмый торгандыр. Аны чын татарча әйтү чаралары бар безнең телдә.

Дистәләрчә еллар кулланылып килгән рәсми дәүләт органы Татарстанның *Югары Советы* исемен, республиканың төп газетасының 5нче октябрь санындагыча, «Татарстан *Югары шурасы*» дип атау кемгә һәм нигә кирәк булган?! Төрле газеталарда очрый торган «*Татарстан Президенты сүзчесе*» кем ул? Текстларның эчтәлегенә караганда, сүз президентның пресс-секретаре турында бара, димәк, аны шулай атарга да кирәктер, югыйсә *сүзчедән* андый мәгънә һич кенә дә аңлашылмый, һәм безнең телдә андый термин да юк.

Гомер-гомергә алынма исем белән атап йөртелгән *Кремль* исемен *Кирмән* дип үзгәртү кайсыдыр бер журналисттан башка тагын кемгә кирәк булды икән? «Республика көнендә без ...*Казан кирмәнен*, «Печән базары»н әйләнәбез («ВТ», 28 август, 2021).

Газета-журнал материаллары, радио - телевидение тапшырулары дөрес әдәби телдә, ягъни үрнәк телдә башкарылырга тиеш. Димәк, мәгълүмат чаралары телендә билгеле бер урынга гына хас диалекталь сүзләр һәм әдәби тел нормаларына туры килми торган гади сөйләм сүзләре кулланылырга тиеш түгел. Әмма кайбер каләм ияләре, бу хакыйкатьне танырга теләмичә, язмаларында кирәксезгә диалект һәм гади сөйләм сүзләре дә кулланалар. Мәсәлән, кайберәүләр, әдәби сүз *арзан*ны бөтенләй санга сукмыйча, аның урынына *очсыз* сүзен кулланалар. Ә кемнәрдер, әдәби сүз *аракы эчүне* ошатмыйча, аны гади сөйләм сүзе *салу* белән алмаштыралар: «Җинаятьләрнең дә күбесе нәкъ менә *салган баштан* кылына» («ВТ», 6 август, 2021 ел)(әдәби телдә «...(*аракы) эчкән* яки *исерек баштан* кылына»).

Хәтта җитди газеталарда эшләүче журналистлар да татар теленең элементар кагыйдәләрен бозалар. Мәсәлән: «Актка аның исем-фамилиясе, *кайда илтүе* турында... языла». Кайда илтүе түгел, *кая илтүе* бит! «Кабарда-Балкардан *ике* бик әзерлекле *студентларны* кабул иттек». *Ике студентлар* дип рус татарчаны бик начар белгән кеше генә сөйләргә мөмкин. Ә монда республика газетасы шулай яза (чын татарча: «...ике студентны кабул иттек»).

Бүгенге татарча газета-журналларда, радио-телевидение тапшыруларында (сөйләм телен әйтеп тә торган юк!) туган телебезгә битараф, ваемсыз караш, аны түбәнсетеп, әһәмиятсез нәрсә итеп карау, игътибарсызлык, башбаштаклык күренешләре, аны, начар белеп, бозып куллану дәвам итсә, ул, алдынгы, камил әдәби тел булуыннан туктап, ясалма, корама, калька теленә әвереләчәк һәм үзенең алдынгы татар мәдәниятенә хезмәт итү вазифасын торган саен ныграк югалта барачак. Тиешле дәүләт органнарына, җаваплы кешеләргә бу мәсьәләдә чаң сугарга күптән вакыт җитте. Телебезне кимсетү сәясәтен үзгәртергә кирәк. Туган телебез – милләтебезне саклап торган иң мөһим, иң кирәкле нәрсә. Аңа тиешле кадер-хөрмәт күрсәтелсен.

03

ТУГАН ТЕЛГӘ ЯШЬТӘН САЛЫНГАН МӘХӘББӘТ СҮРЕЛМИ

Кайбыч төбәге борын заманнардан бирле укымышлы кешеләре белән дан тоткан. Биредә, нигездә, татарлар яшәгән. Бүгенге көндә катнаш гаиләләр саны юк дип әйтеп булмый. Район мәгариф идарәсе җитәкчесе Илмас Илдар улы Хәмидуллин белән Олы Кайбычтагы «Миләшкәй» балалар бакчасына кергәндә, шуларны истә тотып, монда нарасыйларга нинди юнәлештә тәрбия бирелә, мәктәпкә әзерлек ни рәвешле алып барыла икән дигән сорауларга җавап эзләү иде максатым. Якты йөз, матур сүзләре белән каршы алган Сәвия Бәхетгәрәй кызы Тимуршина уйларымны белгәндәй үзе җитәкләгән бакча эшчәнлеге, төркемнәрдә тәрбияләнүче балалар, аларның тәүге уңышлары белән таныштырырга ашыкты.

– «Ел тәрбиячесе – 2022» район бәйгесендә хезмәттәшебез Язгөл Фатыхова җиңүче булды, бу безнең эшчәнлеккә дә зур бәя, – дип тезеп китте Сәвия ханым. Тәрбияче апалары кебек бездәге балалар бик актив, төрле бәйрәм, истәлекле көннәр уңаеннан үткәрелә торган әдәби-музыкаль чараларда теләп катнашалар. Әдипләрнең әсәрләрен өлешләп яттан, матур итеп сөйли беләләр. Чөнки без балаларга бөек Тукаебыздан башлап, каһарман шагыйрь Муса Җәлил һәм яшь буын каләм осталарының әсәрләрен өйрәтәбез. Шагыйрь, язучы Рафис Корбанның төрле елларда иҗат иткән шигырьләрен балаларга бүлеп бирдек, алар өйрәнеп бетергәннән соң, матур чара оештырдык әле, – ди ул куанып. – Балалар язучының «Куркуын җиңгән куян» дигән әкиятен дә уйнап күрсәттеләр. Без аларны кул эшләренә, җыр-бию, матур сөйләм чараларына, төрле, бәйгеләргә дә җәлеп итәбез. Балаларның шунда осталыклары да чарлана, җитешсез яклары да күренә. Балада ниндидер кимчелекләр бар икән, бу табигый хәл. Кемдер сөйләшкәндә хәрефне йотып калдырырга, кемдер тотлыгырга да мөмкин. Мондый балаларга логопед, тәрбиячеләр ярдәмгә килә. Шунысын куанып әйтеп узмыйча булдыра алмыйм: эш күрсәткечләре нәтиҗәле, андыйлар да башка яшьтәшләрен куып тота...

– «Миләшкәй» балалар бакчасы, «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» уңаеннан республика бәйгесендә катнашып, 500 мең сум күләмендә грант откан иде. Моны коллективның күркәм уңышы буларак кабул итәргә кирәк, – дип сүзгә кушыла район мәгариф идарәсе җитәкчесе Илмас Илдар улы. – Бу күркәм нәтиҗә

балалар бакчасын тагын да җанландырып җибәрде шикелле...

– Чыннан да, ул шулай, грантка бирелгән акча исәбеннән балаларга милли киемнәр, хезмәткәрләргә униформалар тектердек, спектакльләр өчен курчаклар алдык, стендлар ясаттык, мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларга «Күңелле Әлифба» китаплары булдырдык, – дип сөенә Сәвия ханым.

– Балаларга бакчадан ук хәреф таныттып, матур итеп сөйләргә, язарга өйрәтеп җибәрәсез, димәк. Быелгы чыгарылышта ничә малай һәм кыз булачак? Балалар саны артуга барамы, әллә?.. – дип кызыксынам.

– Соңгы вакытта Кече Кайбыч, Кошман кебек якын авылларның үзендә дә яңа балалар бакчалары ачылгач, бездә тәрбияләнүчеләр саны кими төште. Бинабыз 140 нарасыйга исәпләнгән, әле тагын 25 бала кабул итәрлек мөмкинлегебез бар, – дип аңлата Сәвия ханым. – Бүлмәләр иркен, уңайлы, килгән һәр балага сөенеп кенә торабыз.

Балаларга ясле яшеннән алып, чыгарылыш төркеменә кадәр аерым тәрбияче билгеләнгән. Моның исә «Миләшкәй» балалар бакчасы өчен сыналган эш алымы булып торуы, әлбәттә, күңелне сөендерә. Балалар билгеле бер тәрбиячегә күнегә. «Бу рәвешле эшләгәндә хезмәткәребез аларның холкын, нәрсәгә сәләтле булуын да яхшы тоемлый, белә, – дип куя җитәкче. – Узган ел 30 балага Кайбыч мәктәбенә юллама алган идек, быел исә 13 малай һәм 14 кызны тәрбияләп, гамәли һәм уку ягыннан башлангыч күнекмәләр биреп озатырбыз дип исәпләп торабыз».

Күпчелеге татар булса да, арада башка милләт балалары да бар. Балалар милләтләр арасында дуслык, татулыкны тоеп, төрле телләрдә аралашырга мөмкин икәнен белеп үсәләр...

– Әлеге мәсьәләдә безнең төбәктә, мәктәпләребездә тәртип,– дип җөпләп куя Илмас Илдар улы һәм бу хакта сөйләшүне Кайбыч мәктәбендә дәвам итәрбез дигән тәкъдим ясый. Минем өчен дә төрле фикерләр ишетү, мәктәп тормышы белән танышу бик урынлы булыр...

ОЛЫ КАЙБЫЧ МӘКТӘБЕННӘН ОЛЫ ШӘХЕСЛӘР ЧЫККАН

Мәктәп директоры Исламия Мирхәт кызы Мусина очрашуыбызның башында ук «Миләшкәй» балалар бакчасы белән тыгыз элемтәдә эшләүләре хакында ассызыклап узды.

– Ел дәвамында беренче сыйныфка керүче балаларның дәресләренә йөреп, укытучыларыбыз укучыларның белем, туган телне өйрәнү дәрәҗәләре белән танышалар, – диде ул. – Әлеге бакчада нинди генә кулланмалар юк?! Иң мөһиме, тәрбиячеләр татар телен камил беләләр, бары тик ата-аналар белән генә эшне көчәйтеп җибәрергә кирәктер дип уйлыйм.

Рус милләтеннән булган кайбер балалар татар телен теләп өйрәнәләр икән.

– Бакчадан килгәндә үк бу сизелеп тора, – ди мәктәп директоры. – Алар телне аңлыйлар, үзара аралашырга, сөйләшергә дә омтылышлары зур. Татарча җавап кайтарырга тырышалар, «Туган тел»нең беренче юлларын җырлап бирергә дә мөмкиннәр. Мәсәлән, Надежда Канашованы бакчага йөргән чагыннан ук беләм. Гел татарча: «Исәнмесез!», – дип исәнләшер, дөрес

әйтеп бетермәсә, шул сүзне төзәтеп кабатларга да кыенсынмый иде. Хәзер ул 3 нче сыйныфта укый, татар телен бик теләп өйрәнә, ярыйсы ук белә, аның кебек балалар күбрәк булсын иде...

Өченче буын ФГОСка юкка гына тәрбия мәсьәләсен беренче итеп куймаганнардыр?! Йортка ныклы нигез кирәк булган кебек, балаларга да беренчел тәрбия гаиләдә бирелергә тиеш. Бу очракта Исламия ханымның: «Тәрбияне мин мәхәббәт сүзе белән янәшә куеп карар идем. Телгә мәхәббәт белән караган бала, үсә төшкәч, ата-анасына, кешеләргә, гомумән, тормышка мәхәббәт белән карый кебек тоела миңа», – дигән сүзләренә кушылмый мөмкин түгел.

– Узган ел мәктәбебезгә беренче сыйныфка 32 бала кабул иткән идек, шуларның яртысы татар классында укырга теләк белдерде, – дип борчулы рухта дәвам итә сүзен мәктәп директоры. – Гәрчә бакчадан чыкканда балалары татарча сөйләшергә, аралашырга өйрәнсәләр дә, заманга ярарга тырышыпмы, кайбер татар милләтендәге ата-аналар балалары белән русча сөйләшергә тырышалар. Нәтиҗәдә баласы русча-татарча сүзләр кыстырып сөйләшә башлый, фикерен дә дөрес итеп аңлата алмый... Укучыда сүзлек запасы аз булса, бәйләнешле сөйләм теле дә үсә алмый. Ата-аналарга «бала үз ана телендә сөйләшеп үсәргә, фикерен җиткерә белергә тиеш» дип аңлатырга тырышабыз.

– Гаиләдә әдәби әсәрләр, гәҗит-журналлар укымау да үзен нык сиздерәдер, – дим.

– Әнә шул матур традицияләрне кайтарасы иде. Элек гаиләбездә әти-әниләр белән бергәләп гәҗит-журналлар уку гадәте бар иде. Без укыган мәкаләләрнең эчтәлеген сөйләргә өйрәнеп үскән буын бит, – ди Исламия Мирхәт кызы. – Балаларыма башлангыч белемне азкомплектлы татар мәктәбендә алырга, 5 нче сыйныфта исә күрше авылдагы рус мәктәбендә укырга туры килде. Әмма телләр өйрәнүнең кыен булуына зарланмадылар, чөнки алар ана телендә фикер йөртергә өйрәнеп үстеләр. Шуңа да туган телгә мәхәббәт гаиләдә салына дип уйлыйм мин. Бала

татар гаиләсендә туган икән, иң беренче авазы да, сүзе дә татарча булуы зарур! Шул вакытта безнең телебез сакланачак, гореф-гадәтләр яшәячәк. Шуңа омтылабыз, эшчәнлегебезне шул юнәлештә алып барабыз.

– Районда 12 мәктәптә 9 нчы сыйныфка кадәр барлык фәннәр дә татар телендә укытыла. Моңысын да уртак казаныш дип исәплим һәм һәр милләт үзенең телен, мәдәни мирасын сакларга, тарихын белеп үсәргә тиеш, – дип өстәп куя Илмас Илдар улы. – Туган телен өйрәнергә һәм аны баласына да өйрәтергә теләгән кешегә бүген бөтен мөмкинлекләр бар. Мәктәпләр дә заман таләпләренә туры китереп җиһазландырылган, укытучылар да тирән белемле.

Илмас әфәнде үзе дә шушы мәктәптә татарча белем алган. Сүз уңаеннан әйтим, мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган һәм югары белем алганнан соң, берничә ел биредә директорлык вазифасын башкарган.

– Бу – бай тарихлы, танылган шәхесләр тәрбияләп чыгарган мәктәп, – диде ул сүз барышында. – Татарстан гербы авторларының берсе – филология фәннәре докторы Назыйм Ханзафаров, Россия дәүләт икътисад университеты профессоры, фән докторы Рәис Борһанов, Петербургтагы атом-төш физика институты профессоры Валерий Фёдоров шундыйлардан. Бу исемлекне шактый дәвам итәргә булыр иде.

Коридор буйлап тезелеп киткән стендларда алар һәм башка талантлы укучылар турында бай материаллар тупланган. Әнә шундый талантлар яшь буынга тормышта үз сукмагын салганда бер кыйбла булып тора да инде.

– Шуны да әйтим, – дип саллы фикерләре белән бүлеште Илмас Илдар улы. – Олы Кайбыч мәктәбе туган телне саклау, үстерү юнәлешендә нәтиҗәле эшләп килә. Бу аларның укыту-тәрбия эшчәнлекләрендә, үткәргән мәдәни чараларында да күренеп тора. Узган ел алар да республика бәйгесендә җиңеп 500 мең сум күләмендә грантка лаек булдылар, бик күп матур чаралар оештырдылар. Үз чиратыбызда Татарстан хөкүмәтенең мәгариф өлкәсенә, халкыбызның бай мирасын һәм туган телләрне саклауга юнәлтелгән кайгыртучанлыгы эзсез югалмас, төбәгебездә сәләтле, өлкәннәр эшен уңышлы дәвам иттерердәй өметле яшь буын үсеп килә, дип ышанып әйтә алам.

Альберт САБИР.

Автор фотолары

ГӨЛШАТ ГАЛИУЛЛИНА: «ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУНЫ АРТТЫРА»

Бөтенроссия олимпиадасы кысаларында КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында татар теле һәм әдәбияты буенча яңа олимпиада булды. Әлеге вакыйга турында безгә институтның Г. Тукай исемендәге милли мәгариф һәм мәдәният югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы мөдире Гөлшат Галиуллина сөйләде.

– Гөлшат ханым, белүебезчә татар теле буенча республика олимпиадасы, халыкара олимпиада бар. Сезнекенең үзенчәлеге нәрсәдә?

– Әлеге чара Россиядә беренче тапкыр уздырыла. Илдә яшәүче халыкларның туган телләрен колачлаучы бөтенроссия олимпиадасы бу. Традицион рәвештә мәктәпләрдә физика, математика, химия һәм башка төгәл фәннәр, гуманитар фәннәр буенча Россия күләмендәге олимпиадалар уздырылып килә иде инде. Аларның нәтиҗәләре югары уку йортларына укырга кергәндә булышуы барыбызга да мәгълүм. Менә быел беренче тапкыр шундый олимпиада туган телләр буенча да үткәрелә. Бу ярышның төп яңалыгы шушы. Әлеге олимпиада туган телләр буенча укырга керүчеләргә өстенлекләр, баллар бирә. Илебездәге туган телләрнең статусын күтәрә. Икенчедән, укучылар өчен дә, укытучылар өчен дә файдалы: белемнәрне тирәнәйтә, офыкларны киңәйтә торган чара.

Әйткәнемчә, олимпиада төрле телләр буенча бара. Аны М.К. Аммосов исемен йөртүче Якутия-Саха Республикасындагы Төньяк-Көнчыгыш федераль университеты оештырганга, мәктәп укучыларының төньяк-көнчыгыш олимпиадасы дип тә атала ул. Ул – Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган олимпиада. Дөрес, быел әле ул башкорт теле һәм әдәбиятыннан, татар теле һәм әдәбиятыннан, эвенк, чечен, якут һәм тагын берничә телне генә колачлады. КФУ – шушы олимпиадаларны оештыручыларның берсе. Кыскасы, әле моны оештыру тәҗрибәсе юк. Шунлыктан олимпиадада катнашучыларга, гәрчә төп тезислары җиткерелсә дә, үзегез күзаллаганча уздырыгыз дигән шикелле, билгеле бер күләмдә ирек куелды.

Ул ике этапта үткәрелде. Беренче этабы онлайн-форматта узды. Мәктәп укучылары университет үткәрә торган мондый онлайн-олимпиадалар белән таныш. Беренче тур узган елның декабрь, быелның гыйнвар айларында

үтте. Анда әдәбият һәм тел буенча сораулар бергә туплап бирелде. Тест форматындагы сораулар иде бу. Беренче этап, әлбәттә, җиңелрәк була. Традицион тест инде ул. Дүрт сорауның берсен сайлап алу. Әдәбияттан да, телдән дә бер өлеше шундый булды. Икенче өлештә җавапны бер сүз белән яза торган берничә сорау бар иде. Инструкция буенча шулай таләп ителә. Өченчесе – тәңгәлләштерү тесты. Сорау һәм җавапларны тәңгәлләштереп язу форматы бусы.

Эчтәлеге ягына килгәндә, анда тел структурасына караган сораулар булды. Ягъни телнең эчке төзелешен ачыклаучы, төрле гасырларда язылган, мәктәп кысаларында өйрәнелә торган матур әдәбият әсәрләренә анализ форматы. Анысы да менә шушы тест эчендәге анализны күздә тота. Терминны, яисә герой исемен табу, жанр үзенчәлеген ачу... Барлык сораулар да мәктәп программасы кысасында өйрәнелгән темаларга кагыла. Әмма әлеге олимпиаданың бер моменты бар: һәр сыйныф аерым түгел. VIII–IX сыйныфлар өчен бер олимпиада, X–XI сыйныфлар өчен бер олимпиада. Бер тема, әйтик, сигезенчедә үтеп, инде бераз онытылган булырга мөмкин.

Икенче турның сораулары, билгеле инде, катлаулырак. Анасы бездә 28 февральдә уздырылды. Монда инде тест форматы түгел; сорауларга җавап язу таләп ителә. Оештыручылар эшкә иҗади якын килүне күз алдында тотты, ягъни логик, аналитик фикерләү, материалны белү үзәккә алынды. VIII–IX сыйныфлар аерым, X–XI сыйныфлар аерым. Сорауларның таләбе – уртак моментларга игътибар итү. Әмма иҗадилык өстенлек алды. Әйтик, кроссвордны чишегез, яисә шигырь юлларыннан терминны табыгыз кебек биремнәр булырга мөмкин.

Тел материалын белү, фикерләү дә мөһим. Әйтик, теория өлешенә килгәндә, җөмләнең баш кисәкләрен языгыз яки җөмләнең баш кисәге булган хәбәргә билгеләмә бирегез, төрләрен билгеләгез, мисаллар китерегез кебек биремнәр бар иде. Җәмгысы сигез сорау иде. Шуларның дүртесе – телгә, өчесе әдәбиятка карый. Сигезенчесе таләп – 150 сүздән дә артмаган инша язу.

Инша язуны балаларның язма сөйләмен тикшерү, фикер йөртү рәвешен ачыклау өчен кирәк. Миңа калса, бик отышлы, кирәкле бирем ул. Чөнки тест белән генә укучының белем дәрәҗәсен билгеләү бик катлаулы, ул объектив булмаска мөмкин. Инша язганда, укучының тел һәм әдәбиятны, грамматиканы һәм тыныш билгеләрен белүе, фикер йөртүе ачыла. Шуңа күрә инша варианты калды.

Хәзерге вакытта олимпиада эшләрен тикшерү бара. Миңа калса, беренче тәҗрибә уңышлы үтте шикелле. Киләчәктә инде бу олимпиада

традициягә кереп ел да үтеп барыр дип, зур өметләр баглыйбыз. Башка фәннәр буенча олимпиадалар предмет укытучыларына, укытучыларга финанс ягыннан файда бирсә, статусын күтәрсә, хәзер туган телләр укытучыларына да мондый мөмкинлек туа дигән сүз. Әйе, хәзерге вакытта халыкара туган тел олимпиадасы, республика олимпиадасы да файдалы. Ә бөтенроссия күләмендә үткәрелгәне бер этәргеч, стимул булыр дип ышаныйк.

Дөрес, быел беренче тапкыр үткәрелгәч, белүчеләр бик күп булмады. Икенче турга йөзләп кеше чыкты. Бу аз түгел инде. Тик Россия күләмендә күбрәк катнашучыны күрәсе килә.

– Олимпиадада Татарстан укучылары гына катнаштымы, башка төбәкләрдән дә булдымы?

– Элек без башка төбәкләрдә дә оештырылыр дип уйлаган идек. Әмма тажлы вирус зәхмәте һаман дәвам итү аркасында Татарстанда гына тукталдык. Беренче турда Башкортстан, Пенза, Чувашия Республикасыннан, Ульян өлкәсеннән дә укучылар катнашты. Икенче турда Башкортстан укучылары гына калды. Казанга килә алмасалар да, Башкортстанда башкорт теле һәм әдәбияты буенча олимпиада уздырылгач, алар шул мәйданчыкны файдалана алды. Киләчәктә һәр төбәктә укучыларга тиешле мәйданчык булыр дип өметләнәбез. Башта Россиянең кимендә 5–6 төбәгендә оештырырбыз, моннан укытучыларыбыз да барып, булышырлар дип уйлаган идек. Әмма ахыр чиктә соңгы этапны Казанда гына уздыру вариантына тукталдык.

– КФУда Каюм Насыйри институты эшләп килә. Аның төрле төбәкләрдә филиаллары бар. Бәлкем сезгә шул мәйданчыкны файдаланыргадыр?

– Бик кызыклы фикер бу. Шәт, тагын бер ул мәйданчыкны файдаланырбыз. Без элек бүтәнчәрәк күзаллаган идек тә, оештыру барып чыкмаган, күрәсең. Әле бу олимпиада хакында укытучыларның да күбесе белеп бетерми. Укытучыларның белемен күтәрү курсларына килүчеләрдән сораштыру шуны күрсәтте. Барыбер беренче турдан йөзләп бала үткән икән, бу – әйбәт. Беренче коймак төерле була дип юкка гына әйтмиләр ич. Беренче этап узган елның 1 декабреннән быелның 17 гыйнварына кадәр үткәрелде. 14 октябрьдән 30 ноябрьгә хәтле теркәлергә була иде. Олимпиада игълан да ителде, оештырыла да башлады. Моның арасы кыскарак булды шул. Инде менә хәзер сезнең журнал аша да күбрәк кеше белер дип ышаныйк. 10 мартка олимпиаданың нәтиҗәләре билгеле булыр дип көтәбез.

Әңгәмәдәш – Рәшит МИНҺАҖ

05

НИЧЕК ЯЗСАК ТА ЯРЫЙМЫ?

Татарстан Фәннәр академиясендә татар лексикографиясенең актуаль мәсьәләләренә багышланган «Түгәрәк өстәл» булды. Сөйләшүдә тел, әдәбият галимнәреннән тыш, ТР Президенты Аппараты, Дәүләт Советының җаваплы хезмәткәрләре, Татарстан китап нәшрияты мөхәррирләре, журналистлар катнашты. Фикер алышуны Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘhСИ) оештырды.

Сөйләшү барышында сүзлекләр төзү мәсьәләсе үзәктә торды дисәм, һич тә ялгышмамдыр. Академиянең җыелышлар залында оештырылган гыйльми хезмәтләр күргәзмәсендә дә төп өлешне сүзлекләр тәшкил итә иде. Тәгаен алганда, соңгы елларда нәшер ителгән ике томлык русча-татарча сүзлек, татар теленең кыенлыклар сүзлеге, үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге, татар теленең орфоэпик сүзлеге, татар теленең этимологик сүзлеге белгечләрнең уңай бәясен алды. Әлбәттә, бер сүзлек тә телдә кулланылышта булган барча кәлимәнең тәрҗемәсен биреп бетерә алмый. Әйтик, үземә күптән түгел генә дару үләннәре турында мәкалә язарга туры килгән иде. Ике томлык сүзлектә сныть (сәрдә), цикорий (һиндыба), девясил (андыз) сүзләренең тәрҗемәсен таба алмадым. Үсемлек атамалары сүзлеген кулыма алгач, эзләгәнемне бик тиз таптым мин.

– Мин үзем соңгы вакытта сүзлек эзләп йөрмим, TATZET электрон платформасына (SUZLEK. ANTAT.RU) гына керәм. Анда 42 татар сүзлеге тупланган, – дип белдерде бу уңайдан фикер алышу барышында «Татаринформ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе баш мөхәррире Рәмис Латыйпов. ТӘhСИ директоры урынбасары Олег Хисамов: «Монда казанышларыбыз белән мактанып утырырга җыенмыйбыз. Безгә нәрсә җитми шуны беләсе килә,» – дип чыгыш ясагач, журналистларның башлап сүз алуы гаҗәп түгел. Чөнки без, журналистлар, көн саен сүз белән эш итәбез, хәбәр-мәкалә язабыз, термин-атамаларны тәрҗемә итеп, укучыга үзебезчә, татарча җиткеррергә тырышабыз. Рәмис белән ничек килешмисең?

– Сүзлекләрдә кайбер сүзләрнең тәрҗемәсе бөтенләй юк. Менә «промышленность» сүзе урынына сәнәгать сүзе кереп китте бит. Нишләп галимнәр «производство», «предприятие» кебек гади генә төшенчәләрне дә тәрҗемә итми икән?! Производсво җитештерү дигән гади генә сүздән алынган бит инде. Үзебездә булмаса, берәр төрки телдән сүз алып буладыр. Нигә телне җимерә-җимерә «производство» дип сөйлибез, язабыз? Самолетны «очкыч» дип яза алабызмы, юкмы? «Татарстан яшьләре» газетасы вертолетны боралак дип яза башлаган иде. Нигә бу сүзне кулланылышка алмаска? Сүзлек төзүчеләр шатырдатып «вертолет» дигән рус сүзен калдыра да, хәл элеккечә дәвам итә. Мәгънәсе төгәл ачыкланып бетмәгән «эшкуар», «эшмәкәр» кебек сүзләр бар. Миңа калса, эшкуарны бизнесмен сүзе урынына, эшмәкәрне предприниматель сүзе урынына кулланып булыр иде. Төгәл билгеләмә юк. Сүзлектә ике сүзне дә кулланалар. Кайсын телисең, шунысын яз... Аннан килеп, ике төрле языла торган сүзләр бар. Инкарьме, инкярме? Ядкарьме, ядкярме? Ничек язсаң да ярыймы? – дип аһ орды журналист.

Татарстан китап нәшрияты мөхәррире Зилия Шәйхразиеваны да бу хәл бик борчый икән. «Кайсы гына сүзлекне ачсаң да, төрле вариантларга очрыйсың. Кушымчаларны дөрес ялгамау, дөрес төрләндермәү очраклары да шактый күп. Әйтик, «шортыйсы», «шортысына», «шортлар» дип язалар. Югыйсә шортые, шортыена, шортылар булырга тиеш (хәер, кыенлыклар сүзлегендә дөрес язылыш китерелгән – Р. М.). «Тәрәкъкый» сүзендә ике «к» уртасында катылык билгесе бар. Тик «диккать» сүзе уртасындагы катылык билгесе ни өчендер төшереп калдырылган. Без инде күптән матур әдәбиятны нәшер иткәндә «йә», «йа» дип язабыз, тик мәктәп дәреслекләрендә һаман бу кисәкчәне «я» дип яза бирәләр. Рус телле укучылар өчен дә «йә», «йа» дип язу отышлы булыр иде. Телне аңлап бетермәгән кешеләр бу кисәкчәне йомшак укыргамы, каты укыргамы икәнен тиз генә төшенми ләбаса. Элек безне телдә нечкәрү процессы бара дип өйрәтәләр иде. Хәзер нишләптер калынайта башладылар. Элек без «киребеткән» сүзен кушып яза идек, хәзер нишләптер

аералар. Югыйсә, ике өлештән торган бу сүз бер төшенчәне белдерә. Догалар языльшына игътибар итсәң, чәчләр үрә торырлык. Бер үк китапта бер үк доганы биш-алты төрле язу очрагы бар. Крепость, собор атамаларын тәрҗемә иткәндә дә кыенлыклар туа», – дип, ул беренче чиратта орфографик сүзлек төзүне ашыктырырга чакырды. (Дөрес языльш мәсьәләсен бездә закон дәрәҗәсендә күтәрергә вакыт җиткәндер, шәт. «Юлдаш» газетасын гына алсак, татар сүзләрен ничек кенә «имгәтеп» язмады әлеге газета. Ник бер чара күрүче булсын? Хәер, соңгы вакытта анда хәл бераз уңай якка үзгәрә башлады сыман.)

Мин дә үз чиратымда сүз алып, сүзлек төзегәндә кабатлана торган берничә хилафлыкка тукталдым. Әлеге дә баягы 80 меңләп сүзне эченә алган ике томлык русча-татарча сүзлектә «карьер», «карьера», «карьерист» сүзләренең, бернинди аңлатма бирелмичә, кертеп җибәрелүенә аптыравымны белдердем. Әйтик, анда «визит», «визитная карточка» кебек сүзләр дә тәрҗемәсез кереп киткән. Югыйсә визит күреп китүне, барып кайтуны аңлата. Визит карточкасын, миңа калса, танытма кәгазе, танытмасы дип тәрҗемә итеп булыр иде. Бәлкем, контекстка карап «таныклык» сүзен дә кулланырга мөмкиндер. Әгәр яңа сүзләр ясалмаса, башка телләрдән үзгәртелмичә, телебезгә яраклаштырылмыйча алынса, сүзлек байлыгыбыз, табигый, отыры ярлылана, төссезләнә барачак. Дөрес, «председатель», «съезд» кебек төшенчә-атамаларны тәрҗемә итәргә ярамаган еллар да булган. Хәзер андый заман түгел ич инде.

Кабат сүзлеккә кайтыйк әле. «Копчик» сүзен койрык сөяге дип тәрҗемә итүләре миңа бик сәер тоелды. Оча сөяге бит ул. Шөкер, мондый хаталар сүзлектә сирәк очрый. «Заповедник» сүзен тыюлык дип тәрҗемә итүләренә дә эчем поша минем. Саклаулык ич ул, дәүләт тарафыннан саклана торган урын. Бу дәгъвама ТӘҺСИнең лексикография бүлеге мөдире Ринат Сәфәров: «Кулланышка шулай кереп киткән инде», – дип кенә куйды. Сүз уңаеннан шуны да әйтим: Ринат әфәнде инде байтак вакытлар «Идел» журналында саннан санга татар телендә дөрес языльш кагыйдәләрен тәфсилләп аңлатып килә. Галим «Гаилә һәм мәктәп» журналында да шушындый рухтагы остаханә алып барырга вәгъдә бирде.

«Түгәрәк өстәл» барышында ТР Дәүләт Советы җаваплы хезмәткәре, ТР законнары һәм ТР Дәүләт Советының норматив-хокукый документлары текстларын тәрҗемә итү һәм тәңгәлләштерү бүлеге мөдире Рөстәм Мөхәммәтшинның чыгышы да бик урынлы булды. Ул бүлек хезмәткәрләре тарафыннан төзелеп нәшер ителгән «Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлек»не үрнәк итеп китереп, хокукый-норматив документларны матбугатка биргәндә, көндәлек эштә кулланганда каләм әһелләрен игътибарлырак булырга чакырды. «Соңгы вакытта, муниципаль район берәмлекләрендә тәрҗемәче вазифасы барлыкка килгәч, безнең эш бераз җиңеләйде. Әмма бу вазифаны башкаручыларга 10-15 мең сум хезмәт хакы гына билгеләнгән. Димәк, бу вазифага пенсиягә чыккан берәр укытучы алына. Яки бу эшне берәр хезмәткәргә өстәмә вазифа итеп тагалар. Нәтиҗәдә хокукый-норматив документларны татарча эшләгәндә яки татарчага тәрҗемә иткәндә бай

так кына хата китә. Республика оешма-учреждениеләренең дә күбесе, күз буяп, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче, дип кенә эшли. Килеп кергән кайбер документларны кулга алгач, андагы хаталарны күргәч, күзгә яшьләр килә», – дип авыр сулый ул. Бик яхшы аңлыйм мин Рөстәм Мөхәммәтшинны. Әнә метро тукталышларында, вагоннарында ТР Министрлар Кабинетының метрополитеннан файдалану хакындагы карары элеп куелган. Анда җөмлә саен хата. Янәшәсендәге русча текстта мондый тупас хаталар булса, күптән инде күршеләр чаң каккан, шау-шу чыгарган булыр иде. Тик безнең халык дәшми. Бу хакта узган елның июль аенда сайтыбызда язып та чыккан идек чыгуын. Сигез ай үтте, игътибар итүче күренми. Хаталы элмә такталар һаман үз урынында. Югыйсә республикабызда эшләп килүче «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы баш модераторы, Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская. Былтыр җәмәгатьчелегебез язуларда һәм атамаларда ачыклаган хаталар төзәтелде, дип хәбәр иткән иде. Шөкер, 1 март көнне язу һәм атамаларда, элмә такталарда, юл күрсәткечләрендә, топография билгеләмәләрендә, торак йортлардагы урам исемнәрендәге хаталарны ачыклау буенча конкурс дәвам иттереләчәге билгеле булды. Шәт, бу юлы әлеге хилафлыкны күрми калмаслар дип өметләник.

Кайбер галимнәр, лексик фонд үзгәреп тора, дип белдерсә дә, сүзлекләр халыкларның меңәр ел дәвам иткән мәдәниятен, тарихын саклап килә. Без, каләм әһелләре, бу хакыйкатьне яхшы аңлап, шушы бәһасез байлыкны милләтебезгә мөмкин кадәр тулырак, төгәлрәк җиткерергә тырышсак иде.

Рәшит МИНҺАЖ

06

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӘНГАТЬ ТӨРЛӘРЕННӘН ФАЙДАЛАНУ

Гөлназ ГАЙНУЛЛИНА,

филология фәннәре кандидаты, доцент

Татар теле һәм әдәбияты – татар халкының чал тарихлы бай рухи хәзинәсе, күңеле матурлыгы, хисләре сафлыгы һәм матур хыялларының үткәне, хәзергесе һәм киләчәгенең сәнгатьчә чагылышы. Шуның өчен дә мәктәпләрдә, гимназияләрдә татар телен укыту, иң беренче чиратта, телебезнең байлыгына һәм киң мөмкинлекләренә, нәфислегенә, халкыбызның, тел осталарыбызның талантына, сәнгатебезнең камиллегенә соклану хисләре тәрбияләү чарасы ул.

Билгеле булганча, сәнгать яшь буынны тәрбияләүдә, укучыларның фәнни белемнәрен тирәнәйтүдә, эстетик зәвыгын формалаштыруда кыйммәтле чара булып санала. Сәнгатьнең нәкъ менә тәрбияви үзенчәлекләрен истә тотып, аның төрләрен татар теле дәресләрендә дә файдаланырга мөмкин. Бу үз чиратында укучыларда гүзәллекне тою хисен үстерергә, сәнгать әсәрләрен аңлый һәм бәяли белү сыйфатларын да тәрбияләргә ярдәм итәчәк.

Укучыларның туган телне тирән аңлавы өчен җитди шартларның берсе – телне яхшы үзләштерүдән тыш, укучыларны образлы күзалларга, образлы яки сәнгати фикерләргә өйрәтү, ә бу исә эстетик тәрбия бирүнең бер компоненты. Моңа, нигездә, туган әдәбият, милли мәдәният, милли традицияләр, гореф-гадәтләр йогынтысында ирешелә. Бу өлкәдә әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре белән чагыштырып өйрәнү максатка ярашлы.

Сәнгати тәрбия бирү әдәбият, музыка, сәнгать, рәсем, хезмәт дәресләрендә генә түгел, татар теле дәресендә дә тормышка ашырыла. Гомумән, иҗат төрләреннән хәбәрдар булмау кеше интеллектының тирән үсешенә комачаулык итә, кешегә көчле йогынты ясау чарасы булган тел, эстетик тәрбия бирү мөмкинлекләрен чикли. Тел укытучысына әлеге хасиятне аңлап, укучыларда матурлык тойгысы, эстетик зәвык, иҗади фантазия тәрбияләүгә әһәмият бирү зарур. Биредә күренекле педагог В.А.Сухомлинскийның сүзләрен китерү урынлы: «Матурлык аша – кешелеклелеккә – тәрбиянең законча лыгы шуннан гыйбарәт, – ди ул.

Нәрсә соң ул сәнгать? Сәнгатьнең нинди төрләре бар? Сәнгать төрләре һәм тел, әдәбият арасында нинди бәйләнеш яши?

Әдәбият, музыка, сынлы сәнгать, скульптура, театр, кино, радио һәм телеэкран h.б. сәнгатьнең төп төрләрен тәшкил итәләр. Сәнгать төрләренең асыл сыйфаты, барыннан да бигрәк художестволы фикерләүдә нинди материаль чаралар куллану белән билгеләнә. Һәр сәнгать төре үзенә генә хас булган материал белән эш итә. Мәсәлән, сынлы сәнгатьтә – буяу, музыкада авазлар, скульптурада – балчык, агач, мәрмәр, кино, театр, телеэкранда – сүз һәм хәрәкәт, радиода – сүз һәм авазлар. Матур әдәбиятта тормышны сурәтләү, образлар тудыру чарасы булып сүз тора.

Яшь буынга белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә роле гаять зур булганга күрә, алдынгы укытучылар татар телен укыту процессында сәнгатьнең башка төрләреннән файдалануга зур әһәмият бирәләр.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен, гадәттә, балалар яратып укыйлар, аларны чын күңелдән, гаять көчле хисләр, тойгылар аша кабул итәләр. Чөнки халык авыз иҗаты саф балалык, мәңгелек яшьлек хисләре белән сугарылган. Бу үзенчәлектән тәрбия максатында киң һәм нәтиҗәле файдалану сорала. Шунысы үзенчәлекле: бала башта күпмедер гомерен әкиятләр тыңлап, укып уздыра, бераз үсә төшкәч, халыкның музыка иҗатына бәйле әсәрләр – җырлар, бәетләр, такмаклар белән, соңрак легендалар, эпослар, дастаннар, батырлар турындагы поэмалар белән мавыгып яши.

Халык авыз әсәрләренең һәр төренең үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Шуны истә тотып, татар теле дәресләрендә теге яки бу теманы өйрәнү процессында аның жанрына карап, махсус алымнарга таянып

эш ителә. Мәсәлән, 6нчы сыйныфта морфология бүлегендә «Хикәя фигыльнең заман формалары» темасын үткәндә, аерым алганда, мәгънә үзенчәлекләрен аңлатканда, мәкаль һәм әйтемнәрне куллану максатка ярашлы. Мәсәлән, күпмедер дәрәҗәдә тышкы матурлыкка ия булып та, эчке дөньясы гүзәллектән, матурлыкны тоя белүдән, гамьнән мәхрүм кешеләргә карата юкка гына ирония белән *«тыштан ялтырый, эчтән калтырый»* димиләр. Бу җөмләдәге *ялтырый, калтырый* фигыльләре затка хас гадәти эш-хәлне белдерә, дигән нәтиҗә әйтелә.

Халык авыз иҗатының кайсы гына төре булмасын, анда шул халыкның гореф-гадәтләре, холык-фигыле, тарихы, хәтта географик атамалары да урын ала. 6 нчы сыйныфта «Ялгызлык исемнәр» темасын үткәндә, укытучы түбәндәге мәкальләрне куллана ала: ***Урал*** *таудай тау булмас,* ***Урал*** *аша су булмас;* ***Ослан*** *тавы күренә;* ***Акбүзат*** *йолдыз,* ***Күкбүзат*** *йолдыз,* ***Тимер*** *казык бер ялгыз;* ***Идел*** *бер, чишмәсе мең; Күп елгадан* ***Идел*** *дә болгана. (417) h.б.* Бу мәкаль-әйтемнәрдә аталган объект төшерелгән рәсемнәр күрсәтелсә, тагын да отышлы.

Туган төбәк тарихын, атамаларын, килеп чыгышын белү – үзе үк эстет шәхескә хас сыйфатларның берсе. Халыкның үзенең рухи байлыгына хәзинә итеп каравы, аны кадерләп саклавы, үстерә һәм һәртөрле формаларда буыннан-буынга тапшыра баруы һәркайсыбызда милли горурлык хисе уята.

Сәнгать әсәрләрен дөрес һәм тулы аңлый алу, иҗат итү осталыгына ирешү кешедә үзеннән-үзе генә тумый. Моңа даими эзләнү, өйрәнү, фәнни-тикшеренү эшләре алып бару, җитди хезмәт итү процессында гына ирешеп була. Бу өлкәдә сәнгать әсәрләре турында язылган әдәбиятны детальләп өйрәнү, даими рәвешттә төрле музейларда, күргәзмә залларында урнаштырылган сәнгатьнең төрле жанрларына караган әсәрләрне үзләштерү, аерым иҗат коллективларының музыкаль һәм хореографик характердагы чыгышларын сәхнәдән, телевизор экраннан карау, радиотапшырулар тыңлау, яңа спектакльләр, кинофильмнар, теле- һәм видеофильмнар белән танышып бару, әдәби музыкаль иртәләр, кичәләр уздыру, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре (язучылар, композиторлар, артистлар, музыка белгечләре h.б.) белән зур хәзерлекле очрашулар үткәрү максатка ярашлы. Сыйныфтан тыш чараларда күренекле язучы яки җырчы белән очрашу оештырылып, нигездә, тәрбияви максат тормышка ашырылса, татар теле дәресләрендә исә белем бирү һәм тәрбияви максатлары күз алдында тотыла. Мәсәлән, 8 нче сыйныф программасында «Кереш сүзләр» темасын үзләштерү каралган. Бу темаы өйрәнер алдыннан күренекле кеше белән очрашу үткәрергә мөмкин. Дәрестә грамматик материалны үткәннән соң, өйгә кереш сүзләр кулланып, әлеге шәхес турында сочинение язу биремен үтәп килергә кушарга була.

Сәнгатьнең үзенчәлеге аның образлылыгында,чынбарлыкны тасвирлау шартлылыгында чагыла. Укучыларның яшь үзенчәлекләренә бәйле образлы фикер йөртү сәләтен истә тотып, татар теле дәресләрендә сәнгать төрләрен кулланырга мөмкин. Бу, бер яктан, укучыларның тел белеме нигезләрен яхшырак үзләштерүгә этәргеч булса, икенчедән, сәнгать белән таныштыру һәм эстетик тәрбия бирү юлында яхшы адым булып тора.

Мисал өчен, 8 нче сыйныфта «Бер составлы җөмләләр яки ким җөмләләр» темасын үткәндә, Г.Камалның «Беренче театр» спектакленнән өзекне видеоязмада карарга була. Укытучы укучыларга персонажларның сөйләменә, җөмлә төзелешенә игътибар итәргә кирәклеген әйтә. Комедиядән алынган аерым җөмләләрне тактага язып куярга яки интерактив тактада күрсәтергә мөмкин. Укучылар ким җөмләләрнең, нигездә, гади сөйләм телендә кулланылуын истә калдырырга тиешләр.

Укучы сәнгатьле образның катлаулы төзелешен аңламаган очракта да әсәр-

нең идеясенә төшенеп ала, әмма ул бу очракта сәнгать әсәрен бөтен яклап художестволы үзләштергәндәге кебек үк эмоциональ һәм әхлакый йогынтыны татымый. Шуның өчен бер генә дәреслек тә эмоциональ тәэсир итү көче ягыннан сәнгать әсәрләре белән чагыштырыла һәм сәнгать башкарган тәрбияви рольне, вазифаны үти алмый.

Татар теле дәресләрендә укытучы җыр сәнгате үрнәкләрен дә файдалана ала. Җырларны фонетика, морфология, синтаксис тармакларын өйрәнгәндә дә кулланырга мөмкин. «Аваз үзгәрешләре» тармагын үзләштергәндә, мисал өчен, татар халык җырлары ярдәмгә килә ала. Бу темага караган дәресне музыка укытучысы белән интегральләштерелгән дәрес итеп итә үткәрергә мөмкин. Җырны тыңлаганнан соң, укучыларга: «Аваз үзгәрешләрен табыгыз, төрен билгеләгез» дигән бирем тәкъдим итәргә мөмкин:

Камчаткалы **бүркең** бар синең,

Башларыңа кисәң тар синең. *(«Ятка күңелеңне бирми тор»)*

Күк күгәрчен, сандугачым,

Синең **күңлең** кемне уйлый? *(«Күк күгәрчен»)*

Җырны тыңлап, укучылар биредә редукция күренеше булуын әйтә. Алдагы җырларны тыңлап, алар протеза күренешенә мисалларны табарга тиеш була:

Өстәл өстем күләгә,

Өстәл өстем кенәгә. *(«Туй җырлары»)*

Безнең әткәй – староста,

Ат яллый бер олауга. *(«Староста кызы»)*

Җырларны тыңлаганнан соң, укучылар татар халык җырларында уртага аваз өстәлү күренеше ешрак татар сүзләрендә дә күзәтелә дигән нәтиҗәгә киләләр:

Без генә китәбез фәйлән җиргә

Ростов аша безнең юлыбыз. *(«Чит-ят җирләрдә»)*

Чакырма ла кәүкүк, әй, каршымда,

Чакырсанай агач башындай. *(«Юлбикә»)*

«Әнекәем, монда килсәнә» җырында *әнкәем* сүзендә уртага [е] авазы өстәлгән, мондый өстәлү ритм таләбе буенча эшләнгәненә игътибар итәргә тиешләр:

Әнекәем, монда килсәнә,

Китәм – хәлләремне белсәнә. *(«Әнекәем, монда килсәнә»)*

Сүз уртасына авазлар өстәлү тартыклар өлкәсенә дә карый. Борын авазы [ң] артыннан [г] тартыгын өстәп әйтү бер төркем сүзләрдә чагыла: *киңгәш – киңәш, җиңгел – җиңел, күңгел – күңел, яңга – яңа, миңга – миңа, синга – сиңа, аңга – аңа, аңгышу – аңышу* һ.б.

Сүз уртасы һәм ахыры закончалыгына караган материалны өй эше итеп тә тәкъдим итәргә мөмкин. Укучылар җырны тыңлый, аваз үзгәрешләренә мисалларны язып бара.

Алдагы җырлардан укучылар сүз башындагы аваз төшеп калу очракларын табарга тиеш була. Мәсәлән,

Уйсу болыннарда ак **марталык**

Авыз итим дисәң балы юк. *(«Ярлы егет»)*

Берничә тартыкка беткән сүзләргә тартыкка башланган аффикслар кушылганда, тамыр белән кушымча арасында өстәмә сузык барлыкка килә. Бу фонетик күренешне Р.Шакирова **парагогия** дип атый. Мәсәлән, *Омск – Омыскига, Омыскида, Уральск – Уральскида* һ.б. Татар халык җырларыннан китерелгән үрнәкләргә игътибар итик:

Тал[э]ьянский кушак син буласың,

Әллә нинди күркәм буласың. *(«Алтын кармак»)*

Шул сылу кызларның куенында

Ике **Бохар[ы]ский** алма бар. *(«Кызларыгыз белән уйнадым»)*

Татар теле дәресләрендә рәсем сәнгате әсәрләрен дә кулланырга мөмкин, чөнки рәсем – кеше фикерен график ысул белән чагылдыру чарасы. Мәктәптә картина-рәсем белән эшләүнең төп максаты – андагы вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, күңел күзе белән карый, аңлый белергә өйрәтү. «Лексикология» бүлеген үткәндә, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү максатыннан картина буенча эш төрләрен куллану отышлы һәм үзен аклый.

Рәсем буенча әңгәмә рәсемдәге теге яки бу төшенчәләрне белдергән лексик берәмлекләр арасындагы ассоциатив бәйләнешләрне аңлауга этәрә, әлеге сүзләрне беренчел семантизациядән соң да күп тапкырлар кулларга нигез булып тора. Картина, кешегә эмоциональ тәэсир итү чыганагы буларак, укучыларга эмоциональ-экспрессив лексиканы аңларга ярдәм итә. Рәсем буенча эшләгәндә, укытучы сүзлек эшен билгеле бер эзлеклелектә оештыра: сүзләр картинаны сурәтләү нигезендә кирәкле эзеклелектә урнаштырыла; сүзлек запасын баетуга гына түгел, ә пассив, алда үтелгән лексиканы да активлаштыруга юнәлтелә. Икенче төрле әйткәндә, укучылар булган лексик запаска да, яңа лексик берәмлекләргә дә таянырга тиешләр.

Укытучы, бәйләнешле сөйләм үстерү дәресләрендә картинаны кулланып, беренче чиратта укучыларны картинаны «укый» белергә өйрәтергә тиеш. Картинаны «уку» рәссамның иҗади уйдырмасын аңлау, рәсем телен «сөйли торган» образлар сәнгате, краска, төсләр буларак кабул итү, алга таба исә, боларның барысын аңлап, картинаның эчтәлеген һәм идеясен дәрестә үтелгән тиешле лексик берәмлекләрне урынлы кулланып җиткерү дигән сүз. Шуңа бәйле картиналарны дөрес сайлый белү зур әһәмияткә ия. Беренче чорда тематика ягыннан кызыклы, укучыларга якын һәм аңлаешлы, композицион яктан катлаулы булмаган жанрлы картиналардан башлау максатка ярашлы. Мәсәлән, «Сөйләм үстерү өчен картиналар» сериясеннән «Көзге урманда», «Кышкы уеннар», «Без – кошларның дуслары», «Яз» рәсемнәрен кулланырга мөмкин.

Мисал өчен, И.И.Шишкинның «Имәнлек» («Дубовая роща») картинасын «Сүз һәм аның мәгънәләре» темасын үткәндә, күрсәтмә әсбап буларак файдаланырга мөмкин.

Укытучы, әлеге рәсемдә Татарстан табигатеннән күренеш тасвирланганын әйтә, алга таба укучыларга сораулар куя:

– Укучылар, бу рәсемдә нәрсәләр сурәтләнгән?

– Бу рәсемдә имәннәр, һава, алан тасвирланган.

– Әйтегез әле, имәннәр нинди?

– Нык, горур, карт, яшь, яшел, таза, матур... һ. б.

Укучылар, сорауларга җавап биреп, *имән, һава, алан* сүзләренең табигать күренешләрен белдерә торган сүзләр булуын хәтергә сеңдерә, *нык, горур, карт, яшь, яшел, таза, матур* сүзләренең кешеләргә карата гына түгел, табигать күренешләренә мөнәсәбәтле кулланылуын да аңлыйлар. Бу сүзләрне кулланып, фразеологик әйтелмәләр, чагыштырулар уйлау, алар белән җөмләләр төзү дә отышлы *(имәндәй нык, горур имән, һава кебек кирәк һ.б.).* Төс белдерә торган лексик берәмлекләр-

нең эпитет буларак кулланылуы, сөйләмдәге вазифалары турында мәгълүмат бирү уңай нәтиҗә бирә *(яшел яфрак, яшел ут, зәңгәр күк, ак юл, кара җир, кара фикер һ.б.).* Аннары укытучы туган ягыбыз табигатенең матурлыгы турында нәтиҗә ясый.

Рәсем буенча эш башкарганда иң әһәмиятлесе – рәсемнең сюжеты буенча әңгәмә үткәрү. Билгеле, укытучы балаларның игътибарын картинаның әһәмиятле деталь¬ләренә юнәлдерә. Бергәләп план төзелә. План буенча берничә укучының төзегән җөмләләре тыңланыла һәм сүзлек эше үткәрелә, сюжетта кулланырга мөмкин булган яңа сүзләр тактага язып аңлатыла. Бу нисбәттән Б.Урманченың «Урал буйларында» дип аталган рәсемен файдаланырга мөмкин:

Эчтәлек буенча бәйләнешле сөйләм тудыру эше билгеле бер максатка хезмәт итә; укучылар сурәтләүне логик эзлеклелектә, тулы эчтәлекле итеп, матур фразалар белән бирергә өйрәнә. Сүзлек запасын тулыландырып, баетып торалар. Сыгылмалы, төзек, матур җөмлә – төзү җиңел эш түгел, шуңа күрә дә андый төрдәге күнегүләр даими башкарылырга тиеш. Мәсәлән, «Лексикология» бүлеген кабатлау дәресендә, өйрәнелгән темага караган биремнәр файдаланып, аерым бер картина буенча эш үткүрергә мөмкин. Рәсем буенча төзегән җөмләләрендә синонимнар, эмоциональ-экспрессив лексика, образлы гыйбарәләр куллану укучыларның «Лексикология» бүлеген үзләштерү дәрәҗәсенә генә тәэсир итеп калмый, ә бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен ныгыту максатына да хезмәт итә, шул ук вакытта эстетик тәрбия бирү дә тормышка ашырыла.

Әңгәмә шулай ук рәсемгә карап, укыганны бәяләү рәвешендә, шәхси күзәтүләр, караган кино яисә спектакльләр, мөстәкыйль укыган китап турында фикер әйтү рәвешендә була ала. Биремле әңгәмә: чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар кулланып сөйләү исә образлы сөйләргә һәм сөйләшергә өйрәнү ягыннан әһәмиятле.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар теле дәресләрендә халкыбыз мәдәнияте үсешендә зур роль уйнаган чиктәш сәнгать әсәрләрен комплекслы файдалану укыту процессының тәрбияви йогынтысын бермә-бер арттыра төшә, чөнки сәнгать әсәрләре (музыка, сынлы сәнгать, кино, театр һ.б.) кешенең сиземләү, тою сферасына төрлечә йогынты ясый, укучыларның интеллектуаль һәм шулай ук эмоциональ мөмкинлекләрен активлаштыра.

Дәресләрдә сәнгать төрләреннән урынлы һәм чамасын белеп куллану зарур, шул очракта гына укыту-тәрбия эше нәтиҗәле булачак, укучыларда туган телгә һәм сәнгатькә кызыксыну артачак, эстетик тойгылары байыячак.

07

ТУГАН ҖИРЕМ – ТАТАРСТАН

Кадрия ФӘТХУЛЛОВА,

Казан федераль университеты доценты, педагогика фәннәре кандидаты

Розалия РАМАЗАНОВА,

Биектау районы Коркачык урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Татар теле укытучыларының эшчәнлегенә методик таләпләр арта бара. Заман белән бергә атлау өчен, аларга дәресләрдә эш алымнарын төрләндерергә, балаларның яшь үзенчәлегенә карап яраклы эш төрләрен кулланырга туры килә. Шунлыктан әлеге юнәлештә фикер алышулар оештыру, алдынгы тәҗрибә белән уртаклашу, аеруча яшь укытучыларга ярдәм күрсәтү зарур. Татар теленнән үрнәк программада билгеләгәнчә, укучыларда аралашу осталыгы булдыру төп максат булып тора. Әлеге осталык, коммуникатив максатка ирешү өчен, телдән (диалогик һәм монологик) һәм язма сөйләм оештыра алудан гыйбарәт. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә, укытучы һәр сыйныфта системалы эш алып бара (бирелгән ситуация буенча әңгәмә кору; сөйләшүне башлау яки дәвам итү, диалогны тулыландыру, сораулар бирү һәм аларга җавап кайтару, рәсем буенча сөйләшү үткәрү, ситуатив биремнәр эшләү һ.б.). Укучылар диалогик сөйләмнәренә үзбәя биргәндә, аралашу максатына ирешүләрен; репликаларның лексик-грамматик яктан дөрес булуын; татар сөйләм этикеты үрнәкләрен урынлы куллануларын, итагатьле әңгәмәдәш булуларын истә тотып эш итәләр. Татар теле дәресләрендә укучыларның монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен дә кызыклы биремнәр, аралашу ситуацияләреннән мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга кирәк. Мәсәлән, тәкъдим ителгән ситуация буенча хәбәрләмә әзерләп сөйләү; биремдәге сорауларга нигезләнеп, сөйләм булдыру; сорауларга киңәйтелгән җаваплар бирү; рәсемне тасвирлау; ике рәсемне чагыштыру һәм алардагы аермаларны әйтеп бирү һ.б. Монологик сөйләмгә үзбәя биргәндә, укучылар түбәндәгеләрдән чыгып эш итәләр: коммуникатив максатка ирешүләре; теманы тулысынча ачып бирүләре; бәйләнешле сөйләмне лексик-грамматик яктан дөрес оештыра алулары. Укучыларның телдән сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә һәр дәрестә игътибар бирү сорала. Ә инде сөйләм үстерү дәресендә укытучы барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга омтыла, дәреслекләрдә бирелгән күнегүләр белән генә чикләнеп калмый, заманча һәм укучыларда кызыксыну уята торган биремнәрне куллана, барлык иҗадилыгын эшкә җигә.

Заман таләпләрен искә алып, 6 нчы сыйныфның рус төркемендә **«Татарстан – туган җирем»** темасына үткәрелгән татар теле дәресе эшкәртмәсен укытучыларның игътибарына тәкъдим итәргә булдык.

Дәрес тибы: телдән сөйләмне үстерү дәресе.

Максатлар: 1) өйрәнелгән сүзләрне, сүзтезмәләрне кабатлау, аларны сөйләмдә куллану күнекмәләрен үстерү; 2) укучыларның тыңлап аңлау, диалогик һәм монологик сөйләмен активлаштыру; 3) татар халкының тарихына кызыксыну уяту, хөрмәт тәрбияләү, шул гадәтләр аша итагатьлелек, бер – береңне хөрмәт итү кебек сыйфатлар тәрбияләү.

Җиһазлау дәреслек: Татар теле. Татарский язык. 6 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык). /Р.З.Хайдарова, З.Р. Назипова. – Казань: Татармультфильм, 2014., 160 с.

Методик ярдәмлек: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту. 6 нчы сыйныф. Укытучылар өчен методик кулланма / Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова – Казан: Татармульфильм, 2014. Компьютер, дәрескә әзерләнгән презентация материалы, экран.

Дәрес барышы

I. Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру, укучыларны аралашуга тарту.

Укытучы: – Исәнмесез, укучылар, утырыгыз! Кәефләрегез ничек? Хәлләрегез яхшымы? (*Музыка яңгырый.*
1 нче слайд *күрсәтелә).*

– Укучылар, күз алдыгызга китерегез әле, сез кечкенә орлыклар, ди. Бакчачы орлыкларга су сибә. Кояш нурлары җылысында орлыклар үсә. Нинаять, шатлыклы мизгел җитә: искиткеч матур чәчәкләр күренә. Чәчәкләр матурланганнан матурлана бара. Чәчәкләр кояшка тартыла.

– Балалар! Чәчәкләр кояш яктысына тартылган кебек, кешеләр дә белемгә тартыла. Сезнең дә күп беләсегез, күп өйрәнәсегез килә. Тормышта бәхетле булырга телисез, уңышларга ирешәсегез килә, дусларыгыз күп булуын телисез. Боларның барысына да кайда ирешергә мөмкин соң? Сез ничек уйлыйсыз? Әйдәгез, фикерләрегезне әйтеп китегез әле. *(Укучылар чиратлашып әйтеп баралар.)*

II. Белемнәрне актуальләштерү.

Укытучы. Укучылар, дәресебезне Гөлшат Зәйнашеваның «Туган ягым – Татарстан!» шигыре белән башлап җибәрәбез. Сез игътибар белән тыңлагыз. Аннары бергәләп бу шигырь нәрсә турында соравына җавап бирергә тырышырбыз.

Идел ярларына нурлар сибеп,

Матур булып ата бездә таң.

Таң шикелле якты Туган илем,

Бәхет биргән җирем – Татарстан.

Дәрес максаты белән таныштыру. Темаы ачып бирү.

Укытучы. Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, без бүген нинди тема буенча сөйләшербез икән? Әйе, дөрес әйтәсез, без Татарстан турында сөйләшүне бүген дә дәвам итәбез. Укучылар, шигырьдәге төп сүзләрне атыйк әле. Әйдәгез, кем башлый? Укучылар (чиратлашып) Идел, Татарстан, туган илем, бәхет.

III. Беренчел ныгыту.

1) Диалогик сөйләм үстерү ***(3 нче слайд).*** Татарстан турында өйрәнгәннәрне кабатлап, ныгытып китү.
(2 укучы Татарстан картасы янында парлап үзара әңгәмә коралар; алга таба тагын 1-2 парның җавабы тыңлана.)

2) Монологик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

Укытучы. Укучылар, сез мәктәптә инглиз телен өйрәнәсез. Күп кенә укучылар чит илләргә, мәсәлән, Германиягә, Австриягә кунакка бара. Кайберләре мәктәптән соң бу илләрдәге уку йортларына укырга да керә әле.

Әйдәгез, шундый ситуацияне күз алдына китерик. Бер укучы, Германиягә баргач, анда немец дусларыбызга Татарстан турында сөйли. *(Укучы сөйләгәннән соң, башкалар аңа сораулар бирәләр, үзара аралашалар.)*

3) Язу күнекмәләрен үстерү *(Укучылар дәфтәрләрендә сүзтезмәләрнең тәрҗемәләре белән туры китереп язалар; аерым укучыларны тактада язарга да чакырып була)*.

Шәһәргә кадәр	*жил в Чистополе*
Чистайда яшәгән	*вода Вятки холоднее*
Татарстанның башкаласы	*до города*
Нократ суы салкынрак	*столица Татарстана*

V. Икенчел ныгыту.

1. Татарча әйтү.

По Татарстану протекают 4 крупные реки.
От Казани до Бугульмы 220 км.
Волга – самая длинная река.
Река Белая короче Волги.
2. Кирәкле репликаларны әйтү ***(5 нче слайд)***

Спроси у друга (подруги):

• какие города есть в Татарстане;

• в каком городе он(она) живёт;

• знает ли реки Татарстана.

Спроси у знакомого:

• разговаривает ли он на татарском языке;

• на какой улице он живет.

Предложи другу:

• поехать в Казань в аквапарк;

• спеть песню на татарском языке.

Как скажете, что:

• вам нравятся уроки татарского языка;

• Татарстан – большая и богатая Республика.

Попроси маму привезти с поездки:

• мягкую игрушку

• красивую футболку.

3. Текстны уку һәм язмача тәрҗемә итү.

Татарстан – туган җирем. Ул – бай һәм зур республика. Татарстанның иң зур байлыгы – аның халкы. Татарстанда татар, рус, чуваш, удмурд һәм башка милләтләр дус-тату яшиләр.

4. Сорауларга телдән җавап бирү (*чылбыр буенча)*.

1) Татарстанның дәүләт телләре нинди ләр?

2) Сез мәктәптә нинди телләр өйрәнәсез?

3) Синең туган телең нинди тел?

4) Син нинди телләрдә сөйләшәсең?

5) Син татарча яхшы беләсеңме?

5. Ситуатив биремнәр.

1) Ты собираешься на Сабантуй. Твоя подруга не хочет идти. Убеди её, что на празднике будет весело.

2) Скажи комплимент однокласснику, который очень красиво спел песню на татарском языке.

3) Предложи другу выучить песню на татарском языке.

4) Уговори друга сходить в татарский театр.

6. Сүзләрне тиешле тәртиптә куеп, җөмләләр язу.

а) Республикасында, без, яшибез, Татарстан.

б) Яши, республикада, милләт, артык, 170 тән.

в) Авторы, флагының, Татарстан, Тавил, Хаҗиәхмәтов.

г) Манарасы, Кремлендә, урнашкан, Сөембикә, Казан.

д) Тарихи, Казан, шәһәр.

VI. Өй эшен аңлату: сорауларга җавап бирергә әзерләнеп килү.

Син ничә тел беләсең? Берничә тел белү сиңа ошыймы? Телләр белү ни өчен файдалы?

VII. Йомгаклау. Рефлексия.

Укытучы: – Балалар, бүген без Татарстан турында булган белемнәребезне кабатладык, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен ныгыттык. Әйтегез әле:

Дөрес җавап

– Сез Татарстан турында нинди яңа мәгълүмат алдыгыз?

– Татарстанның зур шәһәрләре нинди ләр?

– Татарстан аша нинди елгалар ага?

– Татарстанда нинди милләтләр яши?

– Дәрестә сезгә нәрсәләр ошады?

Укучылар үзләренең эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр, билгеләрен дәлилләргә тырышалар. Укытучы аларга ярдәм итә.

Укытучы. – Укучылар, хәзер бәяләү карточкалары белән үзегезгә билге куегыз. Кем үзен бик яхшы дип бәяли, яшел, кем яхшы ди – сары, кем мин дәрестә начар эшләдем ди – кызыл карточкасын күтәрә.

VIII. Хушлашу

Укытучы. – Балалар бик зур рәхмәт сезгә. Сез дәрестә бик яхшы эшләдегез. Мин сездән канәгать. Дәресебезне Салават Фәтхетдиновның «Мин яратам сине, Татарстан!» җыры белән тәмамлыйбыз (күмәк рәвештә җыр башкарыла). Дәрес тәмам. Сау булыгыз!

Дәрес эшкәртмәсеннән күренгәнчә, укытучы кулланган эш төрләре рус телле балаларның татар телендә бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерүгә, шулай ук Татарстан Республикасы, аның шәһәрләре, елгалары һәм табигый байлыклары, анда гомер итүче халыклар турында хәбәр итәргә өйрәтүгә хезмәт итә. Әлеге биремнәрне эшләү барышында балалар уку эшчәнлеген нәтиҗәле оештырырга өйрәнә: үзара аралашуда катнаша; ситуациягә бәйле репликаларны әйтә; өйрәнелгән мәгълүматны сөйләмдә кулланырга күнегә; үзтикшерү күнекмәләренә ия була; дәрес ахырында, нәтиҗә ясап, үзбәя бирә. Шуны да ассызыклап үтик: сөйләм үстерү дәресендә укытучының эшчәнлеге дәрес этаплары арасында бәйләнеш булдыру; төркемдә һәм парлап аралашу алымнарын куллану (күмәк эшчәнлек оештыру); мөстәкыйль эшчәнлеккә төп игътибарны юнәлтү; өстәмә чыганаклардан киң файдалану; яңа мәгълүматның гамәли әһәмиятенә басым ясау; үзбәя бирүне методик яктан дөрес оештыру; һәр эшчәнлекне уңай бәяләү кебек эшләрне үз эченә ала.

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР) ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ҮСТЕРҮ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ

Гөлнара ҺАДИЕВА,

Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасының өлкән укытучысы

Мәктәптә укыту-тәрбия процессындагы үзгәрешләр мәгариф системасында барган яңалыклар белән билгеләнә. Бүгенге көндә иң мөһим үзгәреш – яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (31.05.2021). Алар белем бирү оешмаларында 2022 елның 1 сентябреннән 1 нче һәм 5 нче сыйныфлар өчен гамәлгә кертелә. Федераль дәүләт белем бирү стандартларындагы үзгәрешләр «Туган тел һәм туган тел әдәбияты» предметы өлкәсенә дә карый.

Төп гомуми белем бирү оешмаларында «Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле» уку предметына стандарт таләпләре буларак түбәндәге өлеш кертелде: «Формаль һәм формаль булмаган шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда әйләнә-тирәдәге кешеләр белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне тәэмин итә торган сөйләм эшчәнлеге төрләрен (аудирование, уку, сөйләү һәм язу) камилләштерү». Димәк, татар теле дәресләрә дә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен үстерүгә юнәлтелгән булырга тиеш.

Белем бирү оешмасында предмет һәм метапредмет нәтиҗәләре (коммуникатив универсаль уку гамәлләре) формалаштыру да укучыларның сөйләмен үстерү, ягъни уйлый һәм фикерли белү күнекмәсе, укылган, тыңланган, күргән мәгълүматны анализлау һәм бәяләү, бу анализ нәтиҗәләрен телдән яки язма сөйләмгә әйләндерү аша бара.

«Туган тел һәм (яки) Россия Федерациясе республикасының дәүләт теле» уку предметының кайбер предмет нәтиҗәләре функциональ грамоталылыкның мәҗбүри структур компоненты булган уку грамоталылыгы нигезендә формалаштырыла. Мәгариф системасындагы яңа нәтиҗәләр укучыларны төрле ситуацияләрдән чыгып эш итү һәм үзгәреш чорында яшәргә әзерләү белән бәйләнгән «XXI гасыр күнекмәләре»нә барып тоташа. Уку грамоталылыгы укучының язма текстларның аңлау һәм куллану, алар турында фикер йөртә белү, үз максатларыңа ирешү, белем һәм мөмкинлекләрне киңәйтү, социаль тормышта катнашу өчен белем алу, уку максатын күзаллый. Төп һәм урта гомуми белем бирү баскычында укучыларда уку грамоталылыгы формалаштыру түбәндәге күнекмәләр белән бәйле:

– мәгълүматны эзләү – кирәклесен эзләп табу һәм үзгәртә белүне камилләштерү;

– мәгълүмат, төрле форматтагы текстларны (текст, тексттан өзек, инфографика һ.б.) аңлау һәм куллану;

– кирәкле мәгълүматны үзгәртә белү;

– текстны мәгълүмати-мәгънәви эшкәртә белү;

– текстның билгеләнешен, авторның коммуникатив максатын, логик структураның, тел чараларының ролен аңлау.

Бүгенге көндә мәгариф өлкәсендә барган төрле тикшеренүләр укучыларның предмет буенча нәтиҗәләрен генә түгел, ә турыдан-туры уку компетентлыгын бәяләү белән бәйле. Башлангыч, төп һәм урта белем бирү баскычларында нәтиҗәләрне чагыштыру исә югары сыйныф укучыларының уку грамоталылыгы күрсәткечләренең түбән булуын күрсәтә. Уку сыйфатын бәяләүгә нигезләнгән халыкара тикшеренүләрнең (PISA) нәтиҗәләренә таянып, югары сыйныф укучыларының уку грамоталылыгы белән бәйле типик хаталарын санап китәргә мөмкин. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– текстта сорауга җавап булган өлешне таба белмәү;

– кирәкле урында синонимик рәтне куллануда кыенлыклар (мәсәлән, журналист – каләм иясе);

– конкрет мәгълүматны сайлау һәм тәкъдим итүдә авырлык (сорауга җавап өчен кирәкле текстның кирәкле өлеше тулысынча бирелә, конкрет фраза аерып алынмый, шуңа да турыдан-туры күчерү килеп чыга);

– текстның төрле өлешендә урнашкан ике яки аннан артык берәмлек мәгълүматны аерып ала алмау;

– текстан алынган мәгълүмат нигезендә үз фикереңне әйтү урынына цитата буларак җөмләне китерү (бирем мәгълүматны үзең аңлаганча җиткерү, шәрехләү кебек күнекмәләрне актуальләштерүгә юнәлтелгән булган очракта).

Татар теле дәресләрендә текст белән эшләү укучыларга дөрес язу һәм сөйләү күнекмәләрен бер эшчәнлеккә берләштерергә мөмкинлек бирә. Әлеге эшчәнлек аша укучыларда уку грамоталылыгы күнекмәләре дә формалаштырыла. Дәрестә текст куллану даирәсе төрле булырга мөмкин, бу эш яңа материалны үзләштерү этабында да, ныгытуда да кулланыла ала.

Татар теле дәресләрендә укучыларның уку күнекмәсен үстерү өчен дәреслектәге материал (күнегүләрнең биреме, тексты, кагыйдә) да нигез була ала. Шулай ук укытучыга кейслар төзү өчен тормыштагы төрле ситуацияләрне чагылдыра торган матур әдәбият әсәрләре, фәнни-популяр әдәбият, вакытлы матбугат, аналитик басмалар, реклама текстлары, фотография, инфографика, презентация, рәсми сайтлардагы документлар, интернет-ресурслар чыганак була ала.

Татар теле дәреслекләрендә бирелгән материал нигезендә телдән һәм язма сөйләмне үстерүгә нинди биремнәр төзеп булганын карыйк. Мәсәлән, 10 нчы сыйныф татар теле дәреслегендә (авторы Сәгъдиева Р.К.) кагыйдә тексты да укытучыга дәрестә укучыларның сөйләме өстендә эшләү өчен нигез була ала:

«Сөйләмдә фразеологизмнарны бер сүз белән алыштырып була. Фразеологизмнар – әдәби әсәрдә, шигъриятта төп тел-сурәт чараларының берсе. Аннан оста файдалана белү – язучы иҗатының уңышлы һәм отышлы ягы. Алар ярдәмендә автор әдәби әсәр телен образлырык итә, эмоциональлек өсти, аңа үзенчәлекле яңгыраш кертә».

1. Текстны укыгыз. Фразеологизмнар турында фикерне чагылдыра торган 2 җөмлә уйлагыз һәм язып куегыз.

2. Текттагы мәгълүматка таянып, фразеологизмның сөйләмдәге роле турында языгыз (3 җөмләдән дә ким булмасын).

3. «Тел» сүзе – күпмәгънәле сүз. Бирелгән текстта ул нинди мәгънәдә кулланылган? Биремне үтәгәндә, аңлатмалы сүзлектән файдаланырга мөмкин.

4. Текттагы мәгълүматка таянып, «уңышлы», «отышлы» сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз. Авырлык туса, аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

5. Кагыйдәне укыгыз. Фразеологизмнар турында 3 сорау төзегез, бу сораулларга җавап кагыйдә текстында булмаска тиеш.

Уку грамоталылыгын формалаштыруга

биремнәр тәкъдим иткәндә, укучының белем алу ихтыяҗы һәм мөмкинлеге дә исәпкә алынырга тиеш. Әлеге максаттан чыгып, текст белән эшләүгә корылган биремнәр төрле дәрәҗәдә (база һәм катлаулы) булырга мөмкин. Укучыларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләреннән чыгып, язма һәм телдән сөйләмне үстерүгә иҗади характерда да төрле эшләр тәкъдим итәргә була. Алар дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек барышында кулланыла ала. Мәсәлән:

«Күз алдына китерегез, сез фәнни конференциядә катнашырга телисез. Сезгә катнашу шартларын ачыклау өчен оештыру комитетына хат язарга кирәк. 2–3 кешедән торган төркемнәргә бүленегез. Хат текстын төзегез. Башка төркем белән хатларны алмашып, оештыру комитеты исеменнән хатка җавап языгыз».

«Сезне «Татар китабы көне» дигән зур бәйрәмгә оештыручы итеп чакырдылар. Бәйрәм кунакларына һәм катнашучыларга чакыру уйлап табыгыз. Җавабыгызны язып куегыз».

«Сыйныфташыгыздан блогерлык һөнәре турында интервью алыгыз. Үзегезнең сорауларны һәм алган җавапларны язып куегыз».

«Плакатта прививка ясату турында мәгълүмат бирелгән. Бу плакатның исемен чагылдыра торган 4 мәгълүмат өлешен табып языгыз».

«Татарстан турында мәгълүмат булган слайдны карагыз. Слайдта җавабы булмаган 3 сорау төзегез».

«Инфографиканы карагыз. Социаль челтәрләрдә эмодзилардан ничек куллану турында җавапка туры килгән 4 сорау төзегез».

«Мәктәптә уздырыла торган экологик акциядә катнашырга өндәп, кызыклы белдерү-чакыру (берничә сүздән торган кыска хәбәр форматында) әзерләгез».

Биремнәрдә тәкъдим ителгән мәгълүмат укучыларның әйләнә-тирә дөнья турында күзаллауларын киңәйтергә, шәхес буларак үстерергә, предмет буенча (татар теле) белемнәрен тирәнәйтергә һәм метапредмет күнекмәләрен камилләштерергә тиеш.

Татар теле дәресләрендә текст белән эшләүнең төрле алымнарын куллану укучыларның сөйләмен үстерү өчен кирәкле шарт булып тора һәм предмет, метапредмет нәтиҗәләрен формалаштырырга ярдәм итә. Үз фикерен дөрес итеп формалаштыра һәм төрле мәгълүмат белән эшли белгән укучы гына бүген глобаль дәрәҗәдә конкурентлык сәләтенә ия булырга мөмкин. Димәк, укучыларда функциональ грамоталылык формалаштыру мәгариф системасы һәм һәрбер педагог өчен мөһим бурычларның берсе булып тора.

Кулланылган әдәбият

1. Забродина Н.П. Читательская грамотность: пособие по развитию функциональной грамотности старшеклассников. – Москва: Академия Минпросвещения России, 2021. – 80 с.

2. Сәгъдиева Р.К. Татар теле: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы. 10 нчы с-ф.– Казан: «Мәгариф - Вакыт» нәшр.

«КАЮМ БАБАЙ» 120 ЕЛДАН СОҢ

КАЗАННЫҢ 80 НЧЕ УРТА МӘКТӘБЕНДӘ МӘГЪРИФӘТЧЕ КАЮМ НАСЫЙРИ СКУЛЬПТУРАСЫ УРНАШТЫРЫЛДЫ.

Узган ел мәктәпкә күренекле мәгърифәтченең исеме бирелгән булса, быел февраль аенда Каюм Насыйрига багышланган бик матур скульптур композиция ачылды. Шул ук көнне биредә беренче тапкыр «Насыйри укулары» дип аталган төбәкара фәнни-практик конференция дә үз эшен башлап җибәрде.

Конференцияне мәктәп директоры, педагогика фәннәре кандидаты, Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Роберт Мансуров ачып, аның дәвамлы булачагына ышандырды. «Бүгенге чаралар Каюм Насыйри тарафыннан 1871 елда татар балалары өчен ачылган дөньяви мәктәпкә 150 ел тулу вакыйгасы белән бәйле. Ул үзенең бер хезмәтендә бу зур эшне, күп еллар үткәч искә төшереп, бәя бирәчәкләрен язып калдырган. Февраль бөек мәгърифәтченең туган ае, шулай ук быел аның вафатына 120 ел тула», – диде Роберт Мияссар улы.

Шушы вакыйгаларга багышлап, республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре җитәкчелеге булышлыгы белән Каюм Насыйрига багышланган скульптур композиция әзерләнгән. Казанның бу төбәге турыдан-туры Каюм Насыйри исеме белән бәйле. Иске Татар бистәсенең бер урамы бөек мәгърифәтченең исемен йөртсә, 80 нче мәктәпнең күршесендә генә К.Насыйри музее эшли. Татар өстәл календареның атасы саналган галимнең эшчәнлеге филология, әдәбият, фольклор белән генә чикләнми, ул математика, педагогика, география, тарихтан да күп хезмәтләр яза. Казанда татар балаларына рус телен дә өйрәтү өчен ачкан мәктәбен ябарга мәҗбүр булганнан соң, үзенең туган авылы Югары Шырданда (хәзерге Яшел Үзән районы) мәктәп оештыра.

Роберт Мияссарович мәгърифәтченең мирасы бүгенге укыту-тәрбия эшендә дә ярашлы дип саный. Ләкин аның педагогикага, төрле фәннәргә багышланган хезмәтләрендәге мәгълүматларны укытучы балаларга бүгенге күзлектән карап, заманча итеп җиткерә алса гына уңышка ирешергә мөмкин.

– Министрлык мондый инициативаларны күтәреп алырга әзер. Изге ният белән тотынган башлангычларыгыз уңышка ирешсен, без исә үз чиратыбызда сезгә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер, – дип, Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова мәктәпкә Каюм Насыйри исеме бирелгәннән соң аның алдында калыккан җаваплы бурычларны да билгеләп үтте. – Әле без татар халкын белемле, тәрбияле итүдә бу галимнең тырышлыгын билгеләп бетерә алмыйбыз. Янәшәдәге К. Насыйри музее белән бергәләп эшләсәгез, уңышка ирешерсез. Бүгенге конференция бу юнәлештәге эшнең башы гына әле ул.

Конференция эшендә күп шәһәрләрдән килгән галимнәр һәм татар теле, әдәбияты укытучылары катнаша. Аны ачу тантанасына КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, Казан федераль университет профессоры, педагогика фәннәре докторы Фираз Харисов, республиканың Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, танылган каллиграф Нәҗип Нәккаш һәм башка күренекле шәхесләр чакырылган иде.

Фәния ЛОТФУЛЛИНА

10

КАЮМ НАСЫЙРИ ӘШЕН ДӘВАМ ИТТЕРУЧЕ

Ләлә МОРТАЗИНА,

Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, педагогика фәннәре кандидаты

Хуҗа Бәдигый татар фольклористикасында яңа сәхифә ачучы, аны яңа бер баскычка күтәрүчеләрнең берсе булды.

Хәмит Ярми

XX гасыр башы – татар җәмгыятендә, татар тормышында, мәдәният, әдәбият һәм мәгариф үсешендә хәлиткеч үзгәрешләр, зур яңалыклар, күтәрелеш чоры. Татар матбугаты барлыкка килү, милли театрга нигез салыну, классик дәрәҗәсенә күтәрелгән язучыларыбыз барлыкка килү (бер Тукае гына да ни тора!), әдәбият мәйданына хатын-кызлар аяк басу, заманча, яңа тәртипләргә корылган мәктәп-мәдрәсәләр ачылу, дини белемнәр белән беррәттән, дөньяви фәннәрдән дә бик яхшы мәгълүматлы булган мәгърифәтчеләр, педагоглар тәрбияләнү һ.б. – гасыр башы татар дөньясына килеп кергән яңалыкларның иң мөһимнәре әнә шулардан гыйбарәт. Тик шулай да һәрбер уңай үзгәреш, күтәрелешнең башында аерым шәхесләр тора. Татар фәне үсеше турында сөйләгәндә, әлбәттә, шул чорның иң күренекле галимнәре – М.Корбангалиев, Н.Надиев, Һ.Максуди, Ф.Туйкин, Һ.Атласи, Г.Гобәйдуллин, Г.Максудов һ.б. ны атау дөрес булыр. Бу зыялы затларыбызның күбесе – революциядән соң татар мәгарифе һәм фәнен әйдәп барган, яңа шартларда аның нигезен салган кешеләр. Кызганыч, XX гасыр башында мәйданга килгән, Совет чорында армый-талмый хезмәт иткән бик күп күренекле шәхесләребез, олпат затларыбыз кансыз репрессия чорының золымын күргәннәр, корбан ителгәннәр. Хөрмәтләп искә алуга лаек шундый шәхесләребез арасында күренекле фольклорчы, татар тел белеме һәм милли мәгарифебез үсешенә зур өлеш керткән галим һәм педагог, күпсанлы дәреслекләр авторы Хуҗа Бәдигый да бар.

Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигый 1887 елның 24 декабрендә Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзерге Мамадыш районы) Югары Бөрсет (Югары Кыерлы) авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Туган авылы мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1900 елда Казандагы мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Яхшы укуын, фикер куәтен, фәнни-педагогик эшкә сәләтен искә алып, аны үзе укыган мәдрәсәдә мөгаллим итеп калдыралар. Х.Бәдигыйның педагоглык хезмәтенә әнә шулай беренче орлыклар салына, авыр, үтә җаваплы, әмма гаять кызыклы мәгариф дөньясына беренче адымнар ясала. Бу вакытта инде ул тагын бер мавыктыргыч дөньяны ачып өлгергән була: бу – фән дөньясы. Шулай итеп, киләчәктә әлеге ике юл, берсен берсе тулыландырып, бербөтен булып, аның гомер юлы буйлап озата бара.

1906 елда, әле «Мөхәммәдия»дә укып йөргән вакытында, Хуҗа Бәдигый тормышында хәлиткеч, мөһим бер вакыйга була. Шушы елның көзендә, татар телен һәм халык иҗатын өйрәнү өчен, Казанга күренекле венгр галиме, төрки телләр белгече Дьюла Месарош (1883 – 1957) килә. Урта Идел халыкларының рухи һәм матди мәдәнияте белән кызыксынган галим Казан һәм Сембер губерналарындагы авыллар буйлап этнографик экспедициягә чыга.

«Мөхәммәдия» мөгаллиме Йосыф Акчура тәкъдиме белән аңа ярдәмче итеп Х.Бәдигыййны билгелиләр. Кыш буе венгр галиме татар телен өйрәнә, ә җәен алар икәүләп Казан арты авыллларында фольклор әсәрләре җыя. Шул рәвешчә, татар шәкерте фәнни эшкә беренче адымын ясый. Ләкин ул шулкадәр мавыктыргыч һәм тылсымлы булып чыга ки, Месарош эшен тәмамлап, Казаннан китеп барганнан соң да, Х.Бәдигый татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм өйрәнү эшен дәвам иттерергә карар кыла. «Мин мөхтәрәм остазымнан аерылганның соңында да эшемне дәвам иттем. [...] һаман шул халык әдәбияты артыннан йөреп, башлаган эшемне тәмам итәргә тырыштым», – дип яза ул үзе бу хакта. Моннан тыш, Х.Бәдигыййның чынлап торып фольклор белән кызыксынып



Кратная автобиография.

Я, Ходжа Бадигович Бадигов, гражд. б. Казанской губ. Мамадыш. уезда, Нижне-Сунской волости, дер. Верхнее Берсуда-ныкы тат. республики, родился в декабре м-це 24-го дня 1887 г. в семье б. Муллы. По окончании деревенской татар. школы в 1899 г. был направлен для дальнейшего учения в Казань, где я вступил в Медрессе „Мухаммадия"

По случаю смерти отца мне пришлось жить на свои средства. Летом крестьянствовал со своим братом в деревне, а зимой учился. Когда я стал более менее самостоятельным, с тех пор я личным трудом начал зарабатывать на стороне и делал сбережение на зиму. Себе подобных в бедных „Шакирдами" мы несколько летних сезонов работали у из стного богача Ахмет Хусаинова на суконной фабрике в качестве чернорабочих, а за тем в Казани в Мануфактурном магазине у Галикеевых, кроме того несколько сезонов подряд служил в „Малайках" на Нижегородской ярмарке. Революцию 1905 г. я встречал на школьной скамье, и поэтому имел некоторое представление о политических событиях тогдашнего времени. В годы революции я с моими товарищами (Гали Ачишевым) и Хусаин Ишмашевым под руководств

Хужа Бәдигыйнең кириллицада язылган автобиографиясеннән өзек. 1930 ел (Бәдигый фонды, тасв. 1, сак. бер. 3)

12

китүенә шул өлкәне су кебек эчкән халык шагыйре Г.Тукайның йогынтысы да булгандыр. Х.Бәдигыйга бөек шагыйрь белән күрешергә насыйп була, һәм аның: «Зур эш башлап җибәргәнсең, инде шул юлыңны дәвам ит», – дигән сүзләре, фатихасы яшь галимгә канатлар өсти. Шулай итеп, Х.Бәдигый 1912 – 1914 елларда үзе җыйган материалларны туплап, эшкәртеп, төрләргә аерып, «Халык әдәбияты» дигән гомуми исем астында «Мәкальләр», «Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», «Бәетләр», «Җырлар» дигән китапларын бастырып чыгара. Башка жанрларга караган үрнәкләр, кызганыч, янгын вакытында янып юкка чыга. Халык авыз иҗатының искиткеч тарту көчен тойган галим бу өлкәдә эшен тагын да дәвам иттерә. Зур фәнни эшнең нәтиҗәсе булган китаплары 1920 елларда да басылып чыга, ул җыйган материалларның күпчелеге мәктәп дәреслекләрендә урын ала. Бу вакытта ул Казандагы Гыйльми Үзәкнең фольклор комиссиясендә әгъза булып тора.

Фәнни юнәлеш буларак кына түгел, милләт язмышын ачыклауда да кыймәтле чыганакларның берсе булган татар халык авыз иҗатын өйрәнүгә этәргеч биргән зур шәхесләрнең тормышында очравы, әлбәттә, Х.Бәдигыйның эшчәнлегендә зур роль уйнаган. Ләкин һәр башлаган эшне уңышлы дәвам иттерер өчен, иң беренче чиратта үзеңә зур хезмәт һәм тырышлык куярга һәм, әлбәттә, үҗәтлек белән эшләргә кирәклеге билгеле. Бәдигый да үзалдына куйган бурыч-максатларына эре-эре адымнар белән барган, татар фольклорын фәнни өйрәнү эшенә бинихая зур өлеш керткән. Аның революциягә кадәр үк башланып, Совет чорында да уңышлы дәвам иткән бу эшенә татар галимнәре һәм зыялылары зур бәя биргәннәр. Х.Бәдигыйның фольклор өлкәсендәге хезмәтләренә зур әһәмият биреп, тәнкыйтьче һәм татар язучыларының әйдәманы,

Гыйльми Үзәк җитәкчесе Г.Ибраһимов аны К.Насыйри башлаган эшне 20 ел буена дәвам иттерүче дип атый, педагог һәм журналист Ф.Сәйфи-Казанлы 20 – 30 нчы елларда халык әдәбиятын тергезү юлында торучыларның берсе дип саный.

XX гасыр башында фольклорчы-галим һәм журналист буларак («Мөгаллим» имзасы белән «Әл-ислах» газетасында мәкаләләр бастыра) танылу алган Хуҗа Бәдигый Октябрь революциясеннән соң татар телен өйрәнү һәм укыту эшенә чума. Совет мәктәбе өчен укытучылар әзерләү, мәктәпләр өчен дәреслекләр төзү, методик ярдәмлекләр, кулланмалар язу эшен киң җәелдерә. К.Насыйри исемендәге Казан педагогия техникумында, Көнчыгыш академиясенең татар рабфагында, Өлкә совет-партия мәктәбендә, М.Вахитов исемендәге икенче баскыч мәктәптә татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә, татар-башкорт гаскәриләре өчен оештырылган махсус ликбез курсларында укыта.

Гамәли эшчәнлекнең нәтиҗәләрен фәнни нигезләү һәм гомумиләштерүләргә таянып, Х.Бәдигый татар тел белеме буенча хезмәтләр яза. Күренекле галим М.Корбангалиев белән берлектә язган хезмәтләре аеруча зур бәяләүгә лаек. Аларның «Ана теле сарыфы», «Ана теле нәхүе», «Гамәли тел сабаклары» китаплары татар морфологиясе һәм сарыфын өйрәнүдә зур бер казаныш булып тора. Бер кызыклы факт: әлеге хезмәтләрдә файдаланылган килеш сүзе, грамматик термин буларак, гамәлгә кереп китә, моңарчы кулланылып килгән падеж, игъраб сүзләрен алыштыра.

Әлеге үк авторларның иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә барлыкка килгән «Рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслеге», «Әлифба» китабы, зурлар мәктәпләре өчен язылган «Крестьян әлифбасы» да заманының иң популяр дәреслекләреннән саналган.

1926 елда Х.Бәдигый Ленинградтагы Көнчыгыш институтына укырга җибәрелә, күренекле тюрколог, академик А.Н.Самойловичта (1880 – 1938) укый, аспирантура тәмамлый. «Төрки телләрнең чагыштырма морфологиясе» дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы гына яклаганнан соң, Казан педагогия институтында укытучы, доцент, профессор вазифаларын үти. Бу чорда ул бик җентекле рәвештә татар теленең тарихы мәсьәләләрен өйрәнә. Бу эшнең нәтиҗәсе булып, «Татар әдәби теленең барышы» дигән хезмәте, фәнни мәкаләләре дөньяга килә.

Хуҗа Бәдигыйның туган телебезне һәм әдәбиятыбызны фәнни өйрәнүгә багышланган фидакяр хезмәте әле озак вакытлар дәвам итәр, яңа ачышлар ясалыр, милләтебез өчен әһәмияткә булган бик күп яңа китаплар язылган булыр иде, мөгаен. Тик язмыш шул чорның иң зыялы, иң акыллы, иң булдыклы галим затларына, шул исәптән Бәдигыйга карата та, мәрхәмәтсезлеген күрсәтә. 1938 елның 29 июнендә, Казан педагогия институтында эшләгән, фәнни эшчәнлеге чәчәк аткан чорында аны, ике бала атасын, «Идел-Урал буржуазмилли оешмасы эшендә катнашуда» гаепләп кулга алалар, 10 елга ирегеннән мәхрүм итү, 5 елга хокукларын чикләү турында хөкем карары чыгаралар. Нәкъ ике елдан соң, 1940 елның 22 июнендә, галим аклана. Тик төрмәдә күргән авырлыклар нәтиҗәсендә тәне изелгән, какшаган, җаны җәрәһәтләнгән, сыкраган Хуҗа Бәдигый иректә озак яшәми, күп тә үтми, шул ук елның 17 ноябрендә каты авырудан дөнья куя.

МУСА ҖӘЛИЛ ДИГӘН ИСЕМЕ, ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬ ДИГӘН ДАНЫ БАР

(Башлангыч сыйныф укучылары өчен)

Алсу ЛАТЫЙПОВА,

Әгерҗе районы Исәнбай урта мәктәбенең I квалификация категорияле башлангыч сыйныфлар укытучысы

Максат:

– Муса Җәлилнең тормыш юлын күзалларга өйрәнү;

– шигырьләрен белү; сөйләм телен баету; сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру; җырларын башкару;

– татар халкының герой-шагыйре иҗатына мәхәббәт хисләрен тәрбияләү.

Җиһазлау: шагыйрьнең портреты, Муса Җәлилгә багышлаган китаплардан күргәзмә, рәсемнәр, шигырьләргә иллюстрацияләр.

«Салют сиңа, Муса Җәлил» җыры яңгырый.

Алып баручы. Хәерле көн, балалар. Без бүген залыбызга герой-шагыйрь Муса Җәлилне искә алырга җыелдык. Муса Мостафа улы Җәлилов 1906 елның 15 февралендә Оренбург губернасы Мостафа авылында дөньяга килә. 1944 елның 27 августында Германиянең Плетцензее концлагеренда җәзалап үтерелә. 38 ел гомер... Нибары 38 ел яши ул бу якты дөньяларда, шул гомернең өч елы тоткынлыкта үтә. Кыска гомерендә гасырларга җитәрлек батырлыгы, иҗаты белән мәңгелеккә исемен тарих битләренә яза.

«Шагыйрь» шигыре.Ике малай ике өстәлдә язып утыралар. Берсе сөйләгәндә, икенчесе яза. Соңгы куплетта залның уртасына чыгып, бергәләп сөйләп бетерәләр.

Алып баручы. Чынлап та, төн утырып, шагыйрь нәрсә язды икән? Бәлки, ул үзенең ваемсыз, гамьсез бала чагы турында язгандыр. Аның да бит сезнең кебек кечкенә чаклары булган. **(Слайд)** Әйдәгез, шушы шигырьне тыңлап китик әле.

«Кечкенә дуслар» шигыре.

Экранда рәсемнәр күрсәтергә була.

Алып баручы. Гап-гади бер авыл малае бит ул кечкенә Муса. Әлбәттә, ул – эш яратып, авыл табигатен яратып, болыннарда, кырларда уйнап үскән малай. Урманнарга чыгып, кәккүк тавышларын бирелеп тыңлаган малай.

«Күке» шигыре.

Алып баручы. Балалар, ә хәзер менә бу рәсемгә карагыз. **(Слайд)** Бу – Муса Җәлил туган Мостафа авылының бер урамы. Ә менә бу йортта кечкенә Муса үскән. Бу авыл Оренбургтан 120 км ераклыкта булса да, Мусага бу араны күп тапкырлар узарга туры килә. (Шунысын да әйтеп үтим әле: Соль-Илецк-Тоз-Түбәгә барганда, юл Мостафа авылы янынан үтә. «Мустафино» дип язылган билге тора. Җәлил паркы олы юл читендә, һәм шагыйрьгә куелган бюст юлчыларга карап тора.) Бу урында Муса Җәлилнең «Имән» шигыреннән өзек тыңлап китсәк бик урынлы булыр. Менә бу Җәлил исемендәге бакчаны мин имән белән чагыштырам.

«Имән» шигыре.

Алып баручы. Ә имән янында, Җәлил паркында да кызлар-чәчәкләр биеп ял иткәннәрдер.

«Гөлкәйләрем». Хореографик композиция. (Мин ике вариант тәкъдим итәм.) 1 нче вариант «Гөлләрем» плюска. Кызлар чәчәкләр тотып биилә р. 2 нче вариант «Гөлләрем» минуска. Бер кыз тыныч кына шигырьне сөйли. Кызлар биилә р.

Алып баручы. Мусаның әтисе Мостафа приказчик, кибетче булып эшләгән. Әнисе Рәхимә исемле бик шигъри күңелле кеше булган. **(Слайд)** Аларның гаиләсендә алты бала. Муса алтынчы бала булып дөньяга

килә. Ул, алты яше тулгач, Ибраһим абыйсына ияреп, шушы авылның мәдрәсәсенә укырга бара. «Әле син яшь, бераз үсә төшкәч укырсың», – дип карыйлар Мусага. Ә ул: «Укыйм булгач укыйм, мине дә мәктәпкә җибәрегез», – дип үҗәтләнә. Әтисе дә укытучыга: «Абыйсы янында гына утырып торсын инде», – ди.

Мусаның беренче укытучысы – Габдулла Усманов аның бик тә сәләтле, зирәк, тырыш бала булуын язып калдырган. Ул тыңлап кына утырмый, ә бер елда дүрт классны тәмамлый. Җыр дәресләрендә беренче булып җыр башлый, тартынмыйча дәртләнеп җырлый торган була. Без дә Муса Җәлил сүзләренә язылган бер җырны җырлыйк әле.

«Сәгать» җыры. Бер төркем балалар җырлыйлар.

Алып баручы. Әлбәттә, инде без бу урында Җәлилнең «Беренче дәрес» шигырен дә тыңлап китәрбез.

Алып баручы. Балалар, бу шигырьдән соң минем сезнең белән уйнап аласым килде. Минем кулымда – хәрефләр язылган карточкалар. Ике бала чыгыгыз әле. Сиңа «А», ә сиңа «Б» хәрефеннән башланган сүз төзергә.

«Хәрефләрдән сүз төзү» уены.

Алып баручы.

Нинди зур бәхет,

Нинди үзгәреш.

Бигрәк күңелле

Беренче дәрес.

Алып баручы. Мусага 7 яшь тулгач, аларның гаиләсе Оренбургка күченеп китә. **(Слайд)** Шәһәр аларны үзенең зур пулатлары, җиргә сеңгән, ишелергә торган кечкенә өйләре, зур-зур бай кибетләре белән теләмичә генә кабул итә. Алар «Хөсәения» мәдрәсәсенең подвалында яшиләр. Муса өчен монда бер юаныч – «Белек» китапханәсенең якын булуы. Ул чын күңелен биреп китаплар укый. Көзен «Хөсәения» мәдрәсәсенең әзерлек сыйныфына укырга керә. Яшьтәшләреннән шактый алга китеп, күп белүче шәкерт-укучы була Муса. Төн утырып шигырь язганда шагыйрь шушы балачак елларын уйладымы икән әллә? Чөнки тыныч кына укыганда, 1914 елда империалистик сугыш башлана. Ирләрен сугышка озаткан апалар Мусадан кош теледәй генә хатлар яздыралар. Өч ел дәвам иткән бу канлы сугыш вакытында Муса ничәмә - ничә хат язганын берүзе генә белә. Соңрак ул хатлар гына язып калмый, үзе уйлап чыгарган җырлар белән бизи хатларны. Бу вакытта аңа әле 8–11 яшь кенә була. Тормышның матурлыгына сокланып кына яшәр чагы. Менә шушы шигырьләрдәге матур көз кебек ...

«Көз җитте» шигыре.

Алып баручы. Ә мәктәпкә укырга җыелган балалар түгәрәк ясап җырлы-биюле уеннар уйныйлар. Без белә торган бу уенны бик күптән уйнаганнар икән. Һәм Муса язган сүзләр белән ул болай җырланган.

«Күрсәт әле, үскәнем» җырлы-биюле уен.

Балалар утыралар. Шул вакытта куян битлеге кигән бала уртада ятып кала.

Алып баручы. Балалар, бу Куянга нәрсә булды икән?

Куян-малай. Ике кыз чыгалар.

«Куян» шигыре.

Малай чыга. Йомшак уенчык эт тоткан. Җыр җырлый.

«Маэмай».

Алып баручы. Балалар, Муса Җәлил

беренче шигырьләрен тугыз яшендә яза башлый. Аерым битләргә язу һәм саксызлык аркасында алар юкка чыга. Шуңа күрә ул дәфтәр битләрен дүрткә бөкләп китапчык ясый. Бу китапның да язмышы кызганыч тәмамлана. Әнисе Рәхимә апа, кечкенә бала елагач, аның кулына шушы китапчыкны тоттыра. Муса укудан кайтканчы, бу «китаптан» вак-вак кисәкләр генә калган була инде. Мондый әрнүле вакыйгалар кечкенә Муса тормышында күп була. «Борчылма, улым, – ди Рәхимә апа, – син тагын язарсың»... Аның беренче шигырьләре 1919 елда «Вакыт» газетасында басыла. Бу вакытта Муса Җәлилгә 13 яшь була. Аның бәхетле иҗади тормышы башлана. Җәлил шигырьләрен укуны дәвам итәбез.

«Суык бабай»,«Ишек төбендә», «Чишмә җыры»

Алып баручы. Ә менә бу «Чишмә» исемле шигырьгә композитор Җәүдәт Фәйзи музыка язган. Без дә ул җырны өйрәндек.

«Чишмә» җыры. Ж.Фәйзи музыкасы

Алып баручы. 1941 ел. 22 июнь. Явыз фашист илбасарлары иртәнге сәгать белән илебезгә бәреп керә. Халкыбыз дошманга каршы күтәрелә. Билгеле, татарның зыялы шәхесләре дә, язучылар, шагыйрьләр, композиторлар да фронтка юл алалар. Алар арасында шагыйрь Муса Җәлил дә була. Башта ул хәрби укуларда була, аннары 1942 елның гыйнварында сугышка китә. Шул елның 22 июнендә әсирлеккә төшү аның иҗади тормышында яңа бурычлар куя. Әсирлектә чагында да ул фашистларга каршы чын сугышчан көрәш алып бара. Җәлил үзенең иң көчле үлемсез шигырьләрен тоткынлыкта вакытта яза. Сез ул шигырьләр белән үсә-үсә үзегез дә укып танышырсыз. Ә бүген балалар өчен шушы авыр, газаплы елларда язылган берничә шигырен укып китәрбез.

«Кызыл ромашка»

Өч малай арткы планда басып торалар. Уртада «Кызыл ромашка», ике якта ике «Ромашка-кызлар» тезләнеп утырганнар. Шигырьне сөйлиләр.

Ромашкалар биюе. Малайлар утыралар.

«Соңгы җыр». (Малай сөйли.)

Алып баручы. Муса Җәлилнең уч төбе хәтле генә ике дәфтәргә язылган шигырьләре катлаулы һәм авыр юллар үтеп туган илебезгә кайталар. Ә аның «Җырларым» шигыре аша Туган илен чиксез яратуы, халкы белән хушлашуы, кыска гына гомерендә үз антына тугры калуын бәян итә.

«Җырларым».

Алып баручы. Балалар, бу «Җырларым» шигыренә икенче бер бөек шәхес, татарның беренче композиторы Салих Сәйдәшев көй яза. Ул бүген дә горур яңгырый. Әйдәгез, без аны Хәйдәр Бигичев башкаруындагы язмадан тыңлыйк. Белсәгез, сез дә кушылып җырлагыз.

Аудиоязмада (булса, видео) бер куплет бирелә. Бар да басып тыңлыйлар, җырлыйлар.

Алып баручы. 1944 елның 25 августында Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен фашистлар җәзалап үтерәләр. Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары, үлемсез шигырьләре өчен Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Әйе, аның Муса Җәлил дигән, герой-шагыйрь дигән үлемсез данлы исеме бар. Казаныбыз уртасында шагыйрьгә һәйкәл куелган Муса Җәлилнең үлмәс рухы Туган илгә кайтты.

«Җәлилгә» Г.Гәрәева шигыре.

Алып баручы. Балалар, Җәлилнең шигырьләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Аның батырлыгын, шигырьләрен дөньяның күп илләрендә беләләр. Милләтебезнең каһарман улы белән горурланабыз!

КУШМА СҮЗЛӘР

(3 нче сыйныфта татар теле дәресе)

Лилия ВӘЛИЕВА,

Сарман районы Җәлил гимназиясенең I категорияле башлангыч сыйныф укытучысы

Белем бирү максаты: кушма сүзләр турында төшенчә бирү; аларның ясалышын аңлату, дөрес язарга өйрәтү.

Планлаштырган нәтиҗәләр:

Предмет буенча: нинди сүзләргә кушма сүзләр дибез; нинди кушма сүзләрдә ике тамыр арасына ***ъ, ь*** билгеләре куела–шуларны үзләштерү

Шәхескә кагылышлы УУГ: уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру.

Регулятив УУГ: укытучы белән бергә уку максаты кую; укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; кагыйдәләрне истә тотып гамәлләр кылу.

Танып белү УУГ: логик фикерләүне үстерү гамәлләре башкару; тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру.

Коммуникатив УУГ: үз фикерләрен төгәл, ачык , аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү.

Тәрбияви максат:

укучыларда тырышлык, белемгә омтылу, киң күңелле булу кебек сыйфатлар тәрбияләү.

Төп төшенчәләр: кушма сүзләр.

Предметара бәйләнеш: әдәби уку, әйләнә-тирә дөнья, рус теле.

Эшне оештыру төрләре: фронталь, индивидуаль, парлап эшләү.

Чыганаклар: Татар теле. Ф.Ф. Харисов, Г.Р.Шакирова, Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек. – Казан: «Мәгариф – Вакыт»нәшрияты, 2013. Презентация Power Point.

Дәрес барышы

I. Психологик комфорт булдыру

Укытучы. Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! (Имин үтсен көнегез!) Кәефләрегез ничек соң?

Көтелгән җавап. Татар телен, анам телен, өйрәнергә диеп килдек!

II. Актуальләштерү

Укытучы.Укучылар, әйдәгез, тиз генә үткәннәрне кабатлап китик, минем сорауларга җаваплар бирегез. **(Акыл штурмы) Кем тизрәк?** сорауларга тиз арада җавап бирү.

– Сүзләр нәрсәләрдән ясала? *(Тамыр)*

(2 нче слайд)

– Тамырдан гына торган сүзләр ничек атала? *(Тамырдаш)*

– Тамырга сүз ясагыч кушымча ялганса, нинди сүз килеп чыга? *(Ясалма)*

– Килеш, сан кушымчалары сүз ясауда катнашалармы? *(Юк)*

– Тактада бирелгән беренче мәкальдә ясалма сүзләрне табыгыз. *(Тырышлык, ялкаулык.)* Бу мәкальне ничек аңлыйсыз?

1)Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер **(3 нче слайд)**

2) Сүз бер көнлек, тел гомерлек.

– Икенче мәкальдә ясалма сүзләр бармы? *(Көнлек, гомерлек)*

Бу мәкальнең мәгънәсен аңлатыгыз.

Укытучы. Укучылар, без бүген дәрестә төркемнәргә бүленеп эшләрбез. Шушы беренче мәкальдәге кебек, дәрестә сез тырышып эшләрсез, ялкауланып утырмассыз дип уйлыйм.

III. Уку мәсьәләсен кую.

Укытучы. Укучылар, бер табышмак әйтәм, җавабын уйлап карагыз әле.

(4 нче слайд)

Яшел сабак, эче ак,

Сабак өстендә табак;

Табагында – кибетләр,

Кибетләрдә – егетләр. *(Көнбагыш)*

(Җавабын белмәсәләр, рәсеме күрсәтелә.)

Укытучы. Дөрес, балалар, нәрсә соң ул көнбагыш?

– Бик дөрес. Аны кояш чәчәге дип тә йөртәләр. Әлбәттә, иң элек көнбагыш кешене тәме белән кызыктыра. Көнбагышта D витамины бик күп.

– Укучылар, әйдәгез, бу сүзнең тамырын һәм кушымчасын табыйк.

(Кушымчасы юк)

(Көнбагыш сүзе тактага языла. Бер бала чыгып тактада тамырын таба кушымчасы бармы-юкмы әйтә.)

Укытучы. Бу сүзнең кушымчасы бармы, ничә тамыры бар? Алар ничек язылган? Димәк, бүген нинди сүзләр турында сүз алып барырбыз? **Тема ничек яңгырар?**

(Кушылып языла торган сүзләр, кушма сүзләр) Рус телендә дә бармы шундый сүзләр? Аларны ничек атыйлар? *(Сложные слова)*

Мисаллар китерегез. *(Вертолет, самолет, водолаз)*

– Дәрескә нинди максат куярбыз? Дәрестә нәрсәгә өйрәнербез? *(Кушма сүзләрне, аерырга өйрәнербез)*.

Укытучы. Дәфтәрләрегезне ачыгыз һәм число, сыйныф эшен язып куегыз. Бүген атнаның нинди көне? Әйдәгез, искә төшереп китәбез *(Сишәмбе)*

Матур язу күнегүләре эшләп алабыз. Бер юлга Кк хәрефләрен дөрес итеп язабыз, икенче юлга көнбагыш сүзен язабыз.

Матур язу күнегүләре.

Укытучы. Укучылар, бер әкият укып китәм, тыңлагыз әле.

Борын-борын заманда яшәгән, ди, сүзләр гаиләсе. Аларның гаиләләре зур булган. Алар зур шәһәрдә яшәгәннәр һәм бер-берсенә кунакка йөрешкәннәр. Бер-берсенә кунакка йөрешеп якынаеп киткәннәр. Беркөнне «ак» сүзе белән «кара» сүзенең кунакка барасылары килгән. «Ак» сүзе «кош» сүзенә, «кара» сүзе «бодай» сүзенә кунакка киткән. «Ак» сүзенә «кош» ның саф һавалы йорты, «кара» сүзенә «бодай» ның иркен кырлары бик ошаган. Һәм алар шунда яшәп калганнар. Яңа гаиләләр **аккош, карабодай** булып тату гына яши башлаганнар. Аларның татулыгына кызыгып, башка сүзләр дә бер-берсе белән танышып, дуслашып, яңа гаиләләр корганнар. Шулай күп яңа сүзләр барлыкка килгән. Сабантуй, ташбака, гөлҗимеш..... санап бетерерлек түгел. Ә сез шундый кушма сүзләрне беләсезме? *(Мисаллар китерелә)*

Укытучы. Укучылар, әйдәгез, «**домино**» уенын уйнап китик. Һәр команданың да өстәлендә сүзләр язылган доминолар ята. Мин сезгә табышмак укыйм һәм тактага сүз язылган доминоны ябыштырам. Сез табышмакның җавабын белергә тиешсез. Җавапның бер иҗеген тактага ябыштырам, ә сез икенче иҗеген табып ябыштырырга тиеш буласыз. Беренче белгән төркемгә көнбагыш (көнбагыш рәсеме төшерелгән фишкалар) бирелә.

– Төнлә очарга ярата,

Көндез очмый, йокыга ята. *(Яр канат)* **(5 нче слайд)**

Аягын-башын яшерә

Таш күлмәге эченә. *(Таш бака)*

Күктә оча, суда йөзә,

Муены озын, горур кош *(Ак кош)*

Кызыл миләш өлгергәнен

Күзәтеп торган ул кош.

Җимешләрне берәм-берәм

Авыз итә...*(Кызыл түш)*

Укытучы. Ә бу сүзләрне тагын нинди төркемгә бүлеп була? *(Дөрес, кошлар һәм җәнлекләр.)* Сез алар турында нәрсә беләсез? Тулы информацияне кайдан алып була?

(Интернеттан, энциклопедиядән, китаплардан.)

– Афәрин! Сез бу эшне дә башкарып чыктыгыз. Димәк, кушма сүзләр ике тамырдан торалар.

IV. Яңа белемнәр ачу

Укытучы. Укучылар, мин сезгә хәзер җөмләләр укыйм, ә сез сүзнең нәрсә турында барганын белергә тиешсез:

1. Һәрбер тәрбияле баланың да кесәсендә була. Кулны, битне сөртү өчен кулланыла. *(Кулъяулык)* Рәсеме күрсәтелә. **(6 нчы слайд)**

2. Салкын көннәрдә башка, яки иң башларга ябыла. *(Шәльяулык)* Рәсеме күрсәтелә. **(7 нче слайд)**

3. Өстәл өстенә җәелә торган җәймә. *(Ашъяулык)* Рәсеме күрсәтелә. **(8 нче слайд)**

4. Ризык әзерләгәндә алга бәйләнә. *(Алъяпкыч)* Рәсеме күрсәтелә. **(9 нчы слайд)**

Рәсемнәр астындагы сүзләрнең язылышы.

Укытучы. Укучылар, бу сүзләр нинди сүзләр? *(Кушма)* Ике тамыр арасында нинди хәрефләр куелган? *(ъ,ь)* Ни өчен? *(Алар ике тамырны кушалар яки аералар.)*

Тактага карыйк әле, сезгә ике юлда сүзләр бирелгән, әйдәгез, кагыйдәсен искә төшерик.

1. Көньяк, берьюлы, күпьеллык.

2. Алъяпкыч, кулъюгыч, унъеллык. *(Тактада язылган)*

Шушы сүзләр ярдәмендә кагыйдәне искә төшерү:
кушма сүзләрнең икенче тамыры я,ю,е хәрефләренә башланса, ике тамыр арасына ъ, ь билгеләре куела; беренче иҗектә нечкә сузык булса я, ю,е алдыннан ь билгесен куябыз, беренче иҗектә калын сузык булса я,ю,е алдыннан ъ билгесе куела. **(10 нчы слайд)**

Ял минуты

Укучылар түгәрәк ясап басалар. Башларына сүзләр кигертелә. Балалар музыкага биеп әйләнәләр. Музыка туктау белән, балалар бер-бер-сен табып, парлап басарга, кушма сүз төзергә тиеш булалар (сабантуй, тимераяк,өчпочмак, аккош, төнбоек).

V. Белемнәрне ныгыту

Укытучы. Укучылар, хәзер дәрес-лекләрне ачабыз. 61 нче бит, 109 нчы күнегү белән танышабыз.

Җөмләләрне укыйбыз, калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр ничәшәр тамырдан ясалган?

Күнегүне дәфтәрдә эшлибез. Кушма сүзләрнең асларына сызабыз.

Димәк, кушма сүзләрне кушып язабыз.

Хәзер «Кем зирәк? Әйт тизрәк» уенын уйнап алыйк. Мин җөмлә укыйм, сез сүзнең нәрсә турында барганын белергә тиеш буласыз (кайсы төркем тизрәк җавап бирә, аларга көнбагыш фишкасы бирелә).

Озын борынлы бөҗәк – озынборын.

Дарулар сатыла торган бина – даруханә.

Татарның милли бәйрәме – Сабантуй.

Борыны мөгезгә охшаш хайван – мөгезборын.

Укучылар, әйдәгез карыйк әле нинди кушма сүзләр килеп чыкты икән?

VI. Рефлексия

Укытучы. «Почмак» уенын уйныйк. Минем тартмачыктан һәрберегез берәр сүз ала һәм шул сүзне тотып тиешле почмакка *(«Кушма сүзләр», «Ясалма сүзләр» почмагы.)* барып баса. *(Сүзләр тикшерелә, нәтиҗәләр ясала.)*

– Димәк, кушма сүзләр нинди сүзләр булды инде, алар ничек ясала?

Нинди кушма сүзләрдә ике тамыр арасына ъ,ь билгеләре куела?

– Хәзер нәтиҗәләр чыгарыйк, кайсы команда күп итеп көнбагыш җыйды икән?

(Төркемнәр алган фишкаларны санап, билгеләр куела.)

Үз-үзен бәяләү.Смайликлар белән. **(11 нчы слайд)**

VII. Өй эше. Төрле дәрәҗәдәге биремнәр:

1. Үзегезгә ошаган 3 кушма сүз белән җөмләләр төзеп язып килергә.

2. 61 б., 110 нчы күнегү, сүзләрдән кушма сүзләр ясап яз.

КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ. МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ «СӘГАТЬ» ШИГЫРЕ

(Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Рус төркеме)



Лилия ФАЗЛИЕВА,

«Адымнар-Алабуга» күптелле белем бирү комплексының I квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат:

Белем бирүдә: көндәлек режим төзү. М.Җәлилнең «Сәгать» шигырен өйрәнү.

Үстерелешле: укучыларның тыңлап аңлау, логик фикерләү сәләтләрен һәм диалогик сөйләмен үстерү.

Тәрбияви: укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек, янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дуслык хисен һәм дусларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

Дәреснең тибы: белем һәм осталыкларны системалаштыру.

Төп төшенчәләр: көндәлек режим, вакыт, сәгать.

Предметара бәйләнеш: әйләнә-тирә дөнья, сәнгать.

Эшне оештыру: парларда, индивидуаль.

Җиһазлау: дәреслек (Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гыйниятуллина Л.Ә. Күңелле татар теле. 3 нче сыйныф. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен. – Казан: Татармультфильм, 2013), проектор, ноутбук, презентация, А4 форматында кәгазьләр.

Дәрес этаплары	Укытучы эшчәнлеге	Укучы эшчәнлеге	Универсаль уку гамәлләре (УУГ)
I. Оештыру. Мотивлаштыру	Уңай психологик халәт яки эш атмосферасы тудыру. *(Талгын гына музыка уйный.)* – Хәерле көн, укучылар. Елмай әле, син елмайсаң Яратыр олы-кече. Дөньяда иң матур кеше – Елмайган, көлгән кеше. **(1 нче слайд)**	Дәрескә әзерлекне күрсәтү. – Хәерле көн. Бер-берсенә елмаялар.	*ШУУГ:* укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар булдырырга өйрәтү.

	– Әйдәгез, бер-беребезгә елмаеп, уңышлар телик һәм дәресебезне башлап җибәрик. Бүгенге дәресебез үзенчәлекле һәм матур булыр дип ышанам. – Балалар, бүгенге дәрескә Марат килмәгән икән бит! Кайда йөри икән ул? Ребята, сегодня, оказывается, Марат не пришёл на урок. Где он ходит? – Әнә бит Марат кайда икән! Ул кая ашыга? Вот же он где оказывается! Куда он торопится? **(2 нче слайд)** *(Марат, ашыгып, класска килеп керә.)* – Марат син нигә соңга калдың? – Син үзеңнең көндәлек режимыңны белмисеңмени? Ты разве не знаешь свой режим дня и почему его надо соблюдать? – Укучылар, Марат үзенең көндәлек режимын дөрес төземәгән икән бит! Әйдәгез, аңа ярдәм итәбез. Сез ризамы? Ребята, Марат, оказывается, не правильно составил свой режим дня! Вы согласны ему помочь? – Укучылар, әгәр дә сез Маратка булыша аласыз икән, мин сезгә сәгатьләр бирермен. Сәгатьләрегезнең күпме булуы сезнең белемегезне күрсәтер. Ребята, если вы сможете помочь Марату, я вам дам часики. Количество часиков покажет ваши знания. **(3 нче слайд)**	Балалар тыңлыйлар. Укучылар як-якка караналар. – Мәктәпкә, автобуска... – Мин бит җитешмәдем, юындым, киендем... Марат иңбашын күтәрә. – Без аңа бик теләп булышырбыз. Мы с радостью поможем ему. Укытучы сүзен тыңлыйлар.	*ТБУУГ:* тыңлап аңлау, нәтиҗә чыгару. *КУУГ:* диалогта катнашу, фикерләрне ачык һәм дөрес итеп җиткерү. Хезмәттәшлек булдыру. *РУУГ:* эшчәнлекне оештыра белү, җавапларны бәяли белү.
II. Белемнәрне актуальләштерү	– Балалар, безнең Марат узган дәресләребезне игътибар белән тыңламаган икән бит! Әйдәгез, өйрәнгән сүзләребезне искә төшереп китик.		*ШУУГ:* үзенең көндәлек режимын төзи һәм тормышта куллана белергә өйрәнүгә төшенү;

	Ребята, наш Марат, оказывается, не слушал наши предыдущие уроки! Давайте вспомним слова, которые мы изучали. **(4 нче слайд)** – Сәгать ничә? – Сколько времени? – Сәгать ничәдә? – Во сколько часов? – Сәгать икедә. – В два часа. – Дәрес әзерли. – Делает уроки. Сүзләрне укытучы артыннан кабатлау, хор белән әйтү. – Минем арттан кабатлагыз *(слайдтагы схема буенча)*. – Сәгать ничә? – Сәгать унике. – Сәгать ничәдә киләсең? – Мин сәгать дүрттә киләм. – Син сәгать ничәдә йокыдан торасың? – Мин сәгать җидедә йокыдан торам.	– Сорауларга җавап бирү. Балалар укытучы артыннан хор белән кабатлыйлар. **Үзбәя**	– укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар булдырырга кирәклеген аңлау. *ТБУУГ:* вакыт һәм режим төшенчәләре турында нәтиҗә чыгару. *КУУГ:* диалогта катнашу, фикерләрне ачык җиткерә белү. *РУУГ:* җавапларны дәресли һәм бәяли белү.
III. Белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру	– Балалар, без нинди сүзне актив кулландык? Мы какое слово активно произносили? *(Сәгатьне күрсәтәм.)* **(5 нче слайд)** – Димәк, дәрестә нәрсә турында сөйләшербез икән? О чём мы будем говорить на уроке? – Әйе, укучылар, без бүген сезнең белән сәгать, көндәлек режим турында сөйләшербез. Тулырак әйтсәк, М. Җәлилнең «Сәгать» шигырен өйрәнәчәкбез. **(6 нчы слайд)** – Сезнең бүгенге дәрестә нәрсә өйрәнәсегез, беләсегез килә? Ребята, что вы хотите сегодня узнать на уроке?	– *Сәгать* сүзен актив кулландык. – Сәгать, көндәлек режим турында. **Үзбәя** – Режим дня, про М. Джалиля и его стихотворение. **Үзбәя**	*ТБУУГ:* уку мәсьәләсен аңлау. *РУУГ:* фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү,планлаштыру.

IV. Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану	1. Сүзлек эше. – Иң элек, балалар, яңа лексика белән танышып китәрбез. Сначала мы познакомимся с новой лексикой: *сәгать* [сәгәт] – часы *даң-даң* [даң даң] –звон часов *таң* [таң] – заря *соңга калган* [соңга калган] – опоздал *карап йөр* [карап йөр] – будь внимателен **(7 нче слайд)** 2. Шигырь өстендә эш. – Хәзер М. Җәлилнең «Сәгать» шигыре белән танышып китик. Сейчас познакомимся со стихотворением М. Джалиля «Часы». *(Укытучы укуы, укучыларның сәнгатьле укуы; укучылардан беренче тәэсирләрен сораштыру; шигырьнең мәгънәсен үз сүзләре белән рус телендә сөйләтү.)*	Яңа сүзләр белән танышалар. Укытучы артыннан хор белән кабатлыйлар. **Үзбәя** Укытучыны тыңлыйлар, үзләре укыйлар, әңгәмәдә катнашалар. Шигырьнең мәгънәсен үз сүзләре белән рус телендә сөйлиләр. **Үзбәя**	*ШУУГ:* укучыларның үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар булдыруларын аңлау. *ТБУУГ:* шигырьне тыңлап аңлау. Нәтиҗә чыгару. Шигырьдән төп фикерне аерып алу. *КУУГ:* әңгәмәдә катнашу; – фикерләрне ачык һәм дөрес итеп җиткерү; – сорауларга җавап бирә алу. *РУУГ:* анализ барышын төзи, җавапларны бәяли белү.
Ял минуты	«Сәгать» җырын тыңлау, кушылып җырлау.	Тыңлыйлар, кушылып җырлыйлар.	*РУУГ:* үзкөйләү.
V. Үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү	– Укучылар, сәгать белән көндәлек режим арасында нинди бәйләнеш бар? Ребята, скажите, пожалуйста, какая связь есть между часами и режимом дня? – Чыннан да, сәгатьсез көндәлек режим төзеп булмый. – Әйдәгез, хәзер барыбыз бергә Маратның көндәлек режимын төзибез. Давайте, сейчас все вместе составим режим дня Марата.	– Без часов нельзя составить режим дня.	*ШУУГ:* укучыларда үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар булдырырга өйрәтү. *ТБУУГ:* нәтиҗәләр чыгару, гомумиләштерүләр булдыру.

	Сәгать 7 дә йокыдан тора. Сәгать 8 дә мәктәпкә бара. Сәгать 12 дә көндезге аш ашый. Сәгать 14 тә ял итә. Сәгать 15 тә дәрес әзерли башлый. – Сәгать 18 дә кичке аш ашый. Сәгать 21 дә йокларга ята. – Әйдәгез, хәзер эшләрегезне карап чыгыйк. Менә, Марат, бу синең көндәлек режимың булыр. Син моны исеңдә тот! *(Марат укытучы янына чыгып көндәлек режимын ала.)* **(8 нче слайд)**	Биремне парлап башкаралар. Эшләрен тикшерәләр. **Үзбәя**	*КУУГ:* парларда эшли белү, фикерләрне җиткерү, әңгәмәдә катнашу, диалог төзү. *РУУГ:* эшчәнлекне оештыра белү.
VI. Рефлексия	– Укучылар, без бүген дәрестә нәрсә өйрәндек? – Әйдәгез, эшкә нәтиҗә ясап алыйк. Сезнең алдыгызда үзбәя карталары ята. Сәгатьләрне санагыз һәм шул картага санын языгыз.	– Үткән теманы кабатладык. – Яңа сүзләр өйрәндек. – М.Җәлилне искә төшердек. – «Сәгать» шигырен укыдык. –Маратның көндәлек режимын төзедек. – «Сәгать» җырын җырладык. **Үзбәя**	*ШУУГ:* укучыларның үз-үзләренә карата таләпчәнлек, төгәллек кебек сыйфатлар булдырырга өйрәнүен аңлавы. *КУУГ:* әңгәмәдә катнашу. *РУУГ:* үзбәя.
VII. Өй эше	Өй эше биремен аңлату. 1. М. Җәлилнең «Сәгать» шигырен сәнгатьле укырга. 2. Сәгать рәсемен ясарга. 3. Үзегезгә ошаган 4 юлын ятларга. **(9 нчы слайд)** – Дәрес тәмам. Сау булыгыз, укучылар! Сез булдырдыгыз!	Өй эше биремене аңлашып бетмәгән өлешен ачыклыйлар. Өй эшен язып куялар. – Саубуллашалар.	*ТБУУГ:* биремне аңлау. *РУУГ:* эшчәнлекне оештыра белү.

ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КРОССЕНС ТЕХНОЛОГИЯСЕ

(Осталык дәресе)

Зөлфия ГАЛИМУЛЛИНА,

Кукмарадагы 4 нче урта мәктәпнең югары квалификация категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Осталык дәресе барышы

Укытучы. Хәерле көн, хөрмәтле коллегалар! Сезгә яхшы кәеф телим. Минем мастер-класста сезгә уңайлы булыр дип өметләнеп калам.

– Хәзер игътибарыгызны экранга юнәлтәбез. *(Видео куела.)*

– Әлеге видеоны карагач, сездә нинди фикерләр туды? *(Фикерләрен тыңлау.)* Фикерләрегез өчен рәхмәт.

– Әйе, балаларда күзаллау көчле. Визуаль мәгълүмат яхшырак истә кала һәм кулланыла. Бу феномен образ өстенлеге эффекты дип атала. Фильмнан күргәнегезчә, балаларның күзаллаулары, фантазияләре көчле. Шуңа күрә укучы дәрес вакытында информацияне үзләштерсен, аның креатив, иҗади фикерләве үссен өчен, нәкъ менә визуаль мәгълүмат куллану алымнары белән эшләү мәслихәт. *Кроссенс* шушы алымнарның берсе булып тора.

Бүген мин сезне «Кроссенс – татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә логик һәм иҗади фикерләү технологиясе алымы» дигән темага уздырылачак осталык дәресендә катнашырга чакырам**. (1 нче слайд)**

Хәзер сезне осталык дәресенең төзелеше белән таныштырып үтәм. **(2 нче слайд)**

Осталык дәресенең структурасы

1. Кереш. Максат һәм бурычны билгеләү.

2. Эчтәлекне ачу:

–дәрестә катнашучы контингентны билгеләү;

– кулланылган эш алымнары һәм технологиянең өстенлеген дәлилләү.

3. Гамәли эш. **(3 нче слайд)**

Бу технологияне татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә барлык сыйныфларда да кулланырга була. **(4 нче слайд)**

Укытучы. Бүгенге осталык дәресемнең девизы итеп, мин Г.Ибраһимовның сүзләрен китерер идем: «Күп белүгә караганда да, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләнгәнен табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр…» Г.Ибраһимовның XX гасыр башында әйткән бу сүзләре белем бирүдә яңа Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләрен тулысы белән ача. Икенче буын Федераль дәүләт стандартының мәктәп алдына куйган иң мөһим бурычларының берсе: мәктәпне тәмамлаганда, укучы үзалдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш. Һәм ул стандартның нигезе булып тора. Димәк, традицион дәресләрдән аермалы буларак, укытучы әзер материалны бирүче түгел, ә белем алуны оештыручы булырга, укучыны үзалдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрергә тиеш.

Бүгенге осталык дәресенең максаты: татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә логик һәм иҗади фикерләү технологиясе алымы – кроссенс белән таныштыру, әлеге алымны гамәли кулланырга өйрәтү.

Бурычларыннан берсе – кроссенс башваткычын төзергә өйрәтү. **(5 нче слайд)**

Перспективалар:

– укучы дәресләрдә актив катнашучы була;

– укучылар иҗади фикерләргә

өйрәнәләр;

– укучыларның мөстәкыйль, төркемнәрдә эшләүләрен оештырырга мөмкинлек бирә. **(6 нчы слайд)**

Осталык дәресендә кулланыла торган отышлы эш алымнары белән слайдта **(7 нче слайд)** таныша аласыз:

– төркемнәрдә эш;

– дискуссия;

– кроссенс технологиясе буенча башваткыч әзерләү.

Нәрсә соң ул «кроссенс»? **Кроссенс** – инглиз теленнән «фикерләр киселеше» дип тәрҗемә ителә. Әлеге алым язучы, педагог, математик Сергей Федин һәм техник фәннәр докторы, рәссам, фәлсәфәче Владимир Бусленко тарафыннан уйлап табылган. Бу хактагы язма беренче тапкыр 2002 елда «Наука и жизнь» журналында басылып чыга. **(8, 9 нчы слайдлар)**

Кроссенс – табышмак, башваткыч, ребус, 9 квадраттан торган зур шакмак ул.

Һәр шакмакта мәгънәләре белән бер-берсенә бәйле, туры килә торган рәсемнәр урнаштырылган. Слайдтан күренгәнчә, кроссенс төзүнең өч төрле ысулын аерып карарга була. **(10 нчы слайд)**

Кроссенс **гади һәм катлаулы** булырга мөмкин.

Гади кроссенста картиналар арасында бәйләнеш гади, укучылар әлеге кроссенсны рәсемнәр буенча гына аңлата.

Катлаулы кроссенста рәсемнәр символ ярдәмендә бирелә, шуңа күрә эчтәлекне уйлап, тирән итеп бирү сорала.

Кроссенсларны тел дәресләрендә дә, әдәбият дәресләрендә дә кулланырга була.

Кроссенсның берничә дөрес җавап варианты булырга мөмкин. Укучыларның игътибарын бер генә дөрес вариантка юнәлтергә кирәк түгел. Иң мөһиме – әлеге методның өстенлеге дә шунда: укучыларны иҗади фикерләргә өйрәтү.

Сезгә үзем төзегән башваткыч тәкъдим итәм. Ә хәзер бергәләп әлеге башваткычны чишеп карыйк әле. Башваткычны сәгать теле уңае буенча чишәргә кирәк. Анда мәкаль яшерелгән. Сезгә ярты минут вакыт бирәм.

– Кайсыларыгыз рәсемнәргә карап, мәкальне китереп чыгара алды? **(11, 12 нче слайдлар)**

– Дөрес. Әйдәгез, тикшерәбез.

– Кроссенсны чишү юллары белән таныштык. Хәзер аны *төзү алгоритмы*н тәкъдим итәм:

– тема, идеяне билгеләү;

– темага кагылышлы 8 – 9 элементны аеру;

– иллюстрация, картиналар сайлау;

– һәр сурәтнең үзенчәлеген билгеләү;

– охшаш бәйләнешләрне табу;

– шул вакытта кроссенс әзер була. **(13 нче слайд)**

Төркемнәрдә эш

Укытучы. Хөрмәтле коллегалар, хәзер бергәләп кроссенс төзеп карыйк. Һәрберегезнең алдында – рәсемнәр. Шул рәсемнәргә карап, кайсыгыз кроссенсның темасын, идеясен әйтә ала?

– Әлеге идеяне китереп чыгару өчен нинди элементлар кирәк?

– Нинди рәсемнәр сайладыгыз?

– Ә хәзер шушы рәсемнәр ярдәмендә башваткычны сәгать теле уңае белән чишәрлек итеп төзегез. Сезгә 2 минут вакыт бирәм.

– Барыгыз да тырышып эшләдегез, рәхмәт. Ә хәзер мин сезгә кроссенс төзеп карарга тәкъдим итәм. Өстәлдә – рәсемнәр һәм 9 квадраттан торган буш шакмак. Сезгә рәсемнәрне билгеле бер эзлеклелектә әлеге шакмакларга урнаштырырга һәм кроссенсны 3 минут эчендә чишәргә кирәк булачак. *(Рәсемнәр таратыла, төркемнәрдә эшлиләр.)*

– Кайсы төркем әзер?

– Кроссенска нинди исем бирерсез? *(Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы.)* **(14 нче слайд)**

Укытучы. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Указы белән быел республикабызда Цифрлаштыру елы бара.

– Ә икенче төркем башваткычка нинди исем куйды? (*Әткәм-әнкәм йорты – алтын бишек. Татар халык мәкале.)* **(15 нче слайд)**

– Хөрмәтле хезмәттәшләр, кроссенс технологиясен куллану нинди нәтиҗәгә китерә? **(1 нче төркемгә)** Аларны дәреснең кайсы этапларында кулланырга мөмкин? **(2 нче төркемгә)** Хәзер төркемнәрдә шушы сорауларга җавап бирербез. Сезгә уйлар өчен 1 минут вакыт бирәм.

Көтелгән җаваплар:

1 нче төркем. Темаларны үткәндә, дәрескә кроссенс алымын кертеп җибәрү укучыларның кызыксынуын, фикерләү сәләтен тагын да үстерә.

2 нче төркем. Кроссенсларны дәреснең төрле этабында кулланырга мөмкин:

– өй эшен тикшергәндә (таяну схемасы буларак);

– дәреснең темасын, максатын билгеләгәндә;

– белем һәм күнекмәләрне ныгыту, кабатлау дәресләрендә;

– иҗади төрдәге өй эше итеп бирергә була.

– Мин сезнең белән килешәм. Фикерләрегез өчен рәхмәт.

Кроссенс технологиясен куллану дәресне кызыклырак, җанлырак итә. Әлеге технологияне куллану, баланың иҗади мөмкинлеген, укуга кызыксынуын һәм мөстәкыйльлеген үстерә, күзаллауларын киңәйтә, фикерләү сәләтен камилләштерә. Шулай итеп, кроссенсның максаты – нәрсә дә булса өйрәтү түгел, ә укучының мөстәкыйль рәвештә эзләнүе өчен шартлар тудыру.

Рефлексия

Укытучы. Хөрмәтле коллегалар, бүгенге осталык дәресенең сезнең өчен файдасы булдымы? Ни өчен?

– Тәкъдим ителгән эш төре сезгә авыр тоелдымы? Ни өчен?

– Кроссенс технологиясен үз дәресләрегездә кулланачаксызмы? **(16 нчы слайд)**

– Кроссенсны технологик алым буларак, бер үк сүз төркеменә караган өч сүз ярдәмендә тасвирлагыз. Мәсәлән, **сыйфат:** кызыклы, файдалы, катлаулы; **исем:** ассоциация, логика, алым; **рәвеш**: заманча, татарча, ... ; **фигыль:** уйлата, кызыксындыра. **(17 нче слайд)**

– Фикерләрегез өчен рәхмәт. Бүгенге «Осталык дәресе»н татар халкының «Белемлелекнең чиге юк» дигән мәкале белән тәмамлыйсым килә.

– Игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт! Сезгә гаилә бәхете, сәламәтлек, шатлык-куанычлар телим! **(18 нче слайд)**

15

НИЧӘ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘШӘСЕҢ?

«Нишли белә?» грамматик структурасы (Рус төркемендә татар теле, 5 нче сыйныф)

Гөлнара НОГМАНОВА,

Әгерҗедәге 1 нче гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәрес тибы: яңа материалны өйрәнү.

Максатлар:

Укучының эшчәнлеген формалаштыру максаты: укучыларда яңа эш ысулларына күнекмә формалаштыру: күзәтү, анализ ясау, эзләнү, алгоритм төзү.

Эчтәлек максаты: «Нишли белә?» грамматик структурасы турында укучыларда яңа белем формалаштыру һәм сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

• *Шәхескә кагылышлы:* укучы үзлегеннән белемен арттыру мотивациясе нигезендә, үз эшчәнлеген оештыра алу осталыгына өйрәнәчәк.

Метапредмет нәтиҗәләре:

Регулятив универсаль уку гамәлләре:

– укучы яңа уку мәсьәләсен куя һәм уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белергә өйрәнәчәк;

– укучы куелган максатларга ирешү юлларын планнаштырырга, очраган авырлыкларны чишү алымнарын табарга өйрәнү мөмкинлеге алачак.

Танып белү универсаль уку гамәлләре:

– укучы тиешле мәгълүматны таба, сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә сала белергә өйрәнәчәк;

– дәлилләр нигезендә нәтиҗә ясарга өйрәнү мөмкинлеге алачак.

Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:

– укучы төрле фикерләрне исәпкә алырга, үз фикерләрен телдән төгәл итеп җиткерә һәм дәлилли белергә өйрәнәчәк;

– күмәк эшчәнлектә гомуми нәтиҗә чыгарырга өйрәнү мөмкинлеге алачак.

Предмет буенча:

– укучы «Нишли белә?» соравына җавап бирергә өйрәнәчәк;

– укучы «Нишли белә?» грамматик структурасын сөйләмдә куллана белергә өйрәнү мөмкинлеге алачак.

Эшне оештыру: төркемнәрдә, парларда һәм индивидуаль эшләү.

Дәреснең урыны: «Тел кешене дус итә» бүлегендә икенче дәрес.

Җиһазлау: Нигъмәтуллина «Татарча да яхшы бел», Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014, биремле карточкалар, рәсемнәр, компьютер, экран, проектор, дәрес презентациясе.

Дәреснең технологик картасы

Дәрес этаплары	Укытучы эшчәнлеге	Укучылар эшчәнлеге	Универсаль уку гамәлләре
1.Мотивлаштыру (уңай психологик халәт тудыру, дәрескә игътибар булдыру)	*Исәнмесез, укучылар! Утырыгыз.* *– Әйдәгез әле, укучылар, игътибарыгызны экранга юнәлтеп алыйк. Бу мәкальне ничек аңлыйсыз? Тәрҗемә итегез.* *Җиде йортның телен бел,* *Җиде төрле белем ал.* *– Сезнең каршыгызда җиде төрле милләт вәкилләренең йорт рәсемнәре эленеп тора.* *Сез шушы җиде йортларның ишеген ачарга әзерме бүген?* *Йортларга керү өчен нәрсә белергә кирәк?* *Мәктәп– икенче йортыбыз. Сез монда ничә тел өйрәнәсез?* *– Бүген татар теленнән яңа белемнәр алырга әзерме?*	Исәнмесез, хәерле көн. Узнай язык семи домов, узнаешь семь знании. Сколько языков будешь знать, настолько умнее будешь. Әйе. Һәр йортның телен белергә кирәк. Дүрт тел өйрәнәбез: рус телен, татар, инглиз һәм немец телләрен. Әйе.	*Шәхси эшчәнлек:* укуга мотивация булдыру. *Регулятив эшчәнлек:* укучылар һәм укытучы арасында хезмәттәшлек,җылы мөнәсәбәт оештыру. *Коммуникатив эшчәнлек:* авазларның дөрес әйтелешен кабатлау.

2.Актуаль-ләштерү	Яңа белемнәр алганчы, өй эшләрен тикшерик.Сезгә төрле дәрәҗәдәге биремнәр бирелде.Дәреслекнең 16 нчы битендәге, 4 нче күнегүне эшләүчеләр эталонга карап эшегезне тикшерегез. (Сорауга җавап язарга.) Эталон: Гадәттә, математикадан мисаллар эшләргә, рус әдәбиятыннан хикәя укырга, инглиз теленнән текстны тәрҗемә итәргә, тарихтан сорауларга җавап бирергә кушалар. 15 нче биремне эшләүчеләр эшләрен эталон буенча тикшерәләр. (Тексттагы русча сүзләрне татарчага тәрҗемә итеп укырга.) Эталон: Маратка ярдәм кирәк. Марат мәктәптән кайтты да әнисенә сөйли башлады: – Безнең укытучы өйгә биремнәрне күп бирде. Ә беренче дәрестән соң вахтёр апа кыңгырау чылтыратырга оныткан, шуңа күрә тәнәфестән соңга калдык. Әни, бүген мин математикадан «биш»ле алдым, өй эшеннән. Ә рус теленнән диктанттан «дүрт»ле – ике хата бар. Әнисе сорый: – Ә татар теленнән ничәле, улым? Марат дәшми. Ничек уйлыйсыз? Ни өчен Марат сорауга җавап бирми? Сезнеңчә, татар теленнән аның билгесе нинди? Өй эшен эшләгәндә нинди авырлыклар очрады? У кого возникли затруднения при выполнении домашнего задания? – Звонок – кыңгырау. Вахтёр–алынма сүз. Әлеге текстта әзер килеш кулланыла.	Һәр укучының үз җавабы. – Звонок сүзенең тәрҗемәсен белмәдем. – Вахтёр сүзен тәрҗемә итә алмадым.	*Коммуникатив эшчәнлек:* әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлау *Танып белү эшчәнлеге:* сорауларга дөрес җавап бирү *Регулятив эшчәнлек:* белгән һәм белмәгән күнекмәләрне чагыштыру.

	– Сезнеңчә, Маратның татар теленнән билгесе нинди? Иҗади эш эшләүчеләрне тыңлыйбыз. *Бирем:* Марат белән әнисенең сөйләшүен дәвам итегез. – Марат татар теленнән дә «биш»ле алсын өчен нишләргә кирәк? Сезнең алдыгызда үзбәяләү картасы бар. Өй эше өчен үзегезгә билгеләр куегыз. **Үзбәяләү картасы – Карта самооценки** **ФИ**_____ Тема 1. Өй эше 2. Алгоритм (төркемдә эш-работа в группе) 3. 7 нче күнегү 4. Диалог (парларда эш – работа в парах) 5.Карточкалар белән эш 6.Грамматик структураны кулланып сөйләү	– Минемчә, «өч»ле. Укучылар диалогларын сөйлиләр. Татар телен өйрәнергә кирәк,чөнки ул – татар баласы. Үзбәя.	
3. Проблеманың урынын һәм сәбәбен табу, уку мәсьәләсен кую	Мин кичә бер йорт янынан узганда, менә нинди сөйләшү ишеттем. Сез дә тыңлап карагыз әле. https://www.youtube.com/watch?v=105Vl6UeaXs 1.Татар теленә тәрҗемә итегез: – Алёша—русский. Я – татарин. Мама разговаривает **по-русски.** Алёша говорит слова **по-татарски.** 2.Сорауларга җавап бирегез. Малай ничә телдә сөйләшә? Сез ничә телдә сөйләшәсез?	1.Алёша – рус. Мин – татар. Әни **русча** сөйләшә. Алёша сүзләрне **татарча** әйтә. 2.Малай ике телдә сөйләшә. Мин ике телдә сөйләшәм. Мин өч телдә сөйләшәм. (һәр укучының үз җавабы).	*Шәхси эшчәнлек:* укуга карата кызыксыну хисе уяту, укучы ролен үзләштерү. Коммуникатив эшчәнлек: әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлау, аралашу күнекмәләрен формалаштыру, сорауларга җавап бирү. *Танып белү эшчәнлеге:* чагыштырып нәтиҗә ясый белү.

<table>
<tr>
<td></td>
<td>Алёша нишли белә?
Безнең Никита нишли белә?

Какие возникли трудности?

Можете ли вы объяснить ваши ошибки, какова проблема?</td>
<td>– Я не знаю как ответить на вопрос «Нишли белә?»

– Не знаю в какой форме поставить глагол.</td>
<td></td>
</tr>
<tr>
<td>4. Проблеманы чишү проектын төзү</td>
<td>– Димәк, без бүген дәрестә нишләрбез?

– Дәреснең темасы нинди булыр?

Дәрестә нинди эш алымнары кулланырбыз?

(Теманы дәфтәргә язып куябыз.)</td>
<td>«Нишли белә?»структурасын өйрәнербез. «Ничә телдә сөйләшәсең?» соравына җавап бирербез.

«Ничә телдә сөйләшәсең?» соравы.

«Нишли белә?» грамматик структурасын өйрәнербез. «Ничә телдә сөйләшәсең?» соравына җавап бирербез.

«Ничә телдә сөйләшәсең?» соравы.

«Нишли белә?» грамматик структурасы.

Тәрҗемә итәрбез, күнегүләр эшләрбез, диалог төзербез, дәреслек белән эш.</td>
<td>Танып белү эшчәнлеге: сорауларга дөрес җавап бирү, мөстәкыйль рәвештә уку мәсьәләсен әйтү.

Танып белү эшчәнлеге: проблема кую һәм адымлап чишү.</td>
</tr>
<tr>
<td>5. Проектны тормышка ашыру. Модельләштерү. (үзләштерү дәрәҗәсен тәртипкә салу)</td>
<td>1.Тактадагы таблица белән танышыгыз. Нинди үзенчәлек күрдегез?

<table>
<tr><td>Нәрсә эшлә?</td><td>Нәрсә эшли?</td><td>Нәрсә эшли белә?</td></tr>
<tr><td>ал</td><td>Ала – вычитает</td><td>ала белә</td></tr>
<tr><td>куш</td><td>Куша – прибавляет</td><td>куша белә</td></tr>
<tr><td>тапкырла</td><td>Тапкырлый–умножает Бүлә –</td><td>тапкырлый белә</td></tr>
<tr><td>бүл</td><td>делит Сөйләшә–</td><td>бүлә белә</td></tr>
<tr><td>сөйләш</td><td>говорит</td><td>сөйләшә белә</td></tr>
</table>
</td>
<td>Мы видим, что в первом столбике даны глаголов начальной форме.

– Во втором – глаголы в настоящем времени.

– В третьем столбике мы увидели, что в структуре «Нишли белә?» глаголы тоже употреблены в настоящем времени.

Дәреслек белән эш.</td>
<td>Танып белү эшчәнлеге: иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру, сорауларга дөрес җавап бирү, үзара бәяләү.

Танып белү эшчәнлеге: алган белем күнекмәләрен кулланып, модель төзү.

Регулятив эшчәнлек: анализлый белү

Коммуникатив эшчәнлек: мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару.</td>
</tr>
</table>

	2. Сезнең нәтиҗә дәресме? Дәреслекнең 21 нче битен ачып, кагыйдә белән танышыгыз. 3.Укучылар, хәзер төркемнәрдә тема буенча алгоритм төзергә тәкъдим итәм. 4.Алгоритмны кулланып, сүзләргә кушымчалар ялгагыз. Укы... белә, яз... белә, сикер... белә, бүл... белә, әйт... белә, сыз... белә, җырл(а)... белә, сан(а)... белә. – Биремне үтәгәндә, авырлыкларга очырадыгызмы? Вы справились с заданием? Ял минуты. «Без инде хәзер зурлар» Без инде хәзер зурлар, Күп эшли безнең куллар: Без тузан да сөртәбез, Гөлләргә су сибәбез, Ашарга пешерәбез, Идән юа беләбез. Савыт - саба юабыз, Әнигә булышабыз. Менә нинди зурлар без! Без нишли беләбез?	– Без дөрес нәтиҗә ясаганбыз. Төркемнәрдә эш **Беренче төркем төзегән алгоритм.** Нишли белә? Глагол наст.вр. (-ә,-а,-й,-ый, и)+белә Ул куша белә. Ул бүлә белә. Яза белә. Сөйли белә Укучылар чылбыр буенча җавап бирәләр. Укый белә, яза белә, сикерә белә, бүлә белә, әйтә белә, сыза белә, җырлый белә, саный белә. – Да, но мы ещё не можем правильно подобрать окончания глаголов. Укучылар шигырьне яттан сөйлиләр һәм хәрәкәтләр ясыйлар. Пешерә беләбез, юа беләбез, сибә беләбез...	*ШУГГ:* үз мөмкинлекләрең-не белү-белмәү чикләрен чамалау. *ТБУУГ:* фикерләүдә логик чылбыр төзү. *РУУГ:* эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү. *КУУГ:* мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, иптәшеңнең гамәлләрен бәяләү.

6. Беренчел нығыту	1.Сез мәктәптә дүрт тел өйрәнәсез. Аларның кайсысында бик яхшы сөйләшәсез? 2.Ә дәреслектәге малай ничә тел белә? Нинди телләр белә? 20 нче биттәге рәсемгә карагыз һәм җавап бирегез. 3. 7 нче күнегүдәге укучы нишли белә? Тиешле сүзләрне куеп, шигырьне укыгыз. **Тапкырлый** беләм, **бүлә** беләм, Куша ..., ала ..., Төрле мәсьәлә чишәм, Ике телдә сөйләшәм. Менә күпме һөнәрем! Мин аларның барысын да Мәктәбемдә өйрәндем. Биремне үтәгәндә, авырлыкларга очрадыгызмы? Вы все ещё испытываете затруднения? 4.Алган белемнәрне диалогта кулланып карыйк. Күршеләргә кунакка барабыз. Сораулар: 1) Ничә телдә сөйләшәсең? 2) Син нишли беләсең? 3) Әтиең, әниең, апаң... нишли белә?	Мин рус телендә яхшы сөйләшәм. h.б Малай 5 тел белә, 5 телдә сөйләшә белә. Француз телен, төрек телен, немец телен, татар телен, рус телен белә. Тапкырлый белә, бүлә белә, мәсьәлә чишә белә, ике телдә сөйләшә белә. Да, надо ещё потренироваться. Парларда бер-берсенә сораулар бирәләр. Мин ике телдә сөйләшәм. Мин скрипкада уйный беләм. Әтием футбол уйный белә.Әнием бәлеш пешерә белә.	*ШУУГ:* үз уңышларың /уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү. *РУУГ:* үз эшчәнлегеңне контрольгә алу.
7. Мөстәкыйль эш эшләү (алган белемнәрне нығыту, күнегү эшләгәндә дөрес куллану)	1.Хәзер белемнәрне кулланып карыйк. Карточкалар белән эш 1.Тиешле кушымчалар языгыз. Вставьте окончания. Кушымчалар:-ча /-чә, -чы/-че. Татар..., рус..., мари..., удмурт...,., грузин..., төрек... 2. Тәрҗемә итегез. Умеет разговаривать по-французски. Лена умеет петь. Гена говорит на трёх языках. Он умеет играть на скрипке.	Карточкалардагы биремнәрне дәфтәрдә эшлиләр.	*Танып белү эшчәнлеге:* тиешле мәгълүматны табу, билгеләү, үзара бәяләү. *Регулятив эшчәнлек:* белгән һәм белмәгән күнекмәләрне чагыштыру, үзара бәйләү, нәтиҗә ясау.

	Эталонга карап, бер-берегезнең эшен тикшерегез. 1.Татарча, русча, марича, удмуртча, грузинча, төрекчә. 2. Французча сөйләшә белә. Лена җырлый белә. Гена өч телдә сөйләшә. Ул скрипкада уйный белә.	Бер-берсенең эшен бәялиләр.	
8. Ысулны куллану (алган белемнәрне диалогик сөйләмдә куллану)	Ә сез ничә телдә сөйләшәсез? Сез нишли беләсез? Йортларның ишекләрен ачып карыйк (һәр укучы үз йорты янына баса һәм үз телендә исәнләшә, «Нишли белә» структурасын кулланып, үзе турында сөйли.3– 4 җөмлә) Бәяләү.	Сай. Мин – мари, өч телдә сөйләшәм. Мин җырлый беләм. Әнием пәрәмәч пешерә белә. – Мин – грузин. Ике телдә сөйләшәм. Мин рәсем ясый беләм. – Умаеч. Мин – удмурт, ике телдә сөйләшәм. Мин бии беләм... Үзбәя.	*Коммуникатив эшчәнлек:* аралашу күнекмәләрен формалаштыру. *Регулятив эшчәнлек:* үзбәя һәм үзара бәя бирү.
9. Рефлексия Уку мәсьәләсе чишелешенә, дәреснең максатына ирешү дәрәҗәсен ачыклау.	Дәрестә нинди уку мәсьәләсен билгеләдек? – Нәрсәләр белдек? Ничә йортның ишеген ачтык? – Үзегезгә билгеләр куегыз. Өй эше. 1) 22 нче бит, 11 нче һәм 12 нче күнегүләр. 2) Карточкалар белән эш. Түбәндә бирелгән сүзләрне татарча-русча парлап әйтегез һәм таблицаны үрнәктәгечә тутырыгыз Иркен сөйләшәм *перевожу со словарём* Сөйләшә белмим *разговариваю свободно* Авыр өйрәнәм *не умею разговаривать* Бераз аңлыйм *учу с трудом* Сүзлек белән тәрҗемә итәм *немного понимаю* Татарча иркен сөйләшәм – разговариваю свободно	«Нишли белә?» структурасын өйрәндек. Дусларымның ничә телдә сөйләшкәнен белдек. – Җиде йортның ишеген ачтык. Без бүген төрле телләрдә исәнләшергә өйрәндек. Үзләрен бәялиләр.	*Регулятив эшчәнлек:* үзбәя һәм үзара бәя бирү. *Танып белү эшчәнлеге:* логик фикерләү чылбырын булдыру.

КИЛӘЧӘК ЗАМАНДАГЫ ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ЗАТ БЕЛӘН ТӨРЛӘНЕШЕ

(5 нче сыйныфның рус төркемендә үткәрелгән дәреснең технологик картасы)

Венера ИШМӨХӘММӘТОВА,

Әгерҗедәге Тажи Гыйззәт исемендәге 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел (татар теле) һәм әдәбият укытучысы

Максат	*1. Белем бирү максаты:* киләчәк замандагы фигыльләрнең зат кушымчалары белән таныштыруны оештыру. *2. Фикерләү, күнекмәләрне үстерү максаты:* укучыларның үз фикерләрен әйтүгә, анализ ясауларына, дәрестә шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү өчен шартлар тудыру. *3. Тәрбияви максат:* рәхмәтле булу сыйфатын тәрбияләү өчен шартлар тудыру.
Бурыч	Укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү. Укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив,шәхескә кагылышлы) формалаштыру.
УУЭ	*Шәхескә кагылышлы УУГ:* – укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру. *Регулятив УУГ:* – хәл ителгән һәм хәл ителергә тиешлене чагыштырып, уку бурычларын кую; – үзконтроль һәм үз эшчәнлегеңне бәяли белү. *Танып белү УУГ:* – укытучының сорауларына җавап бирә, кирәкле мәгълүматны таба белү. *Коммуникатив УУГ:* – Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү, фикер алышуда катнашу. – Сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү, – Парларда, төркемнәрдә эшли белү.
Төп төшенчәләр	Фигыль, киләчәк заман, зат кушымчалары.
Предметара бәйләнеш	Әдәбият
Төп ресурслар **Өстәмә ресурслар**	Куллану өчен дәреслек: Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. «Татар теле / Татарский язык. 5 сыйныф» *Техник чаралар:* Компьютер, экран, проектор, Power Pointта презентация. Дидактик карточкалар, тест
Эшчәнлекне оештыру формасы	Фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә эш.

Дәрес этаплары	Укытучы эшчәнлеге	Укучы эшчәнлеге	Көтелгән нәтиҗә
1 нче этап. Оештыру этабы. Максат: дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт тудыру	– Исәнмесез, укучылар! Укучыларынның исәнләшүеннән соң: – Утырыгыз. – Минем исемем Венера Мәгъсүм кызы. Мин үзем генә килмәдем. *(Тупка күрсәтеп)* Аның исеме Күзлебүкән. Әйдәгез әле, сезнең белән дә танышыйк. Туп ыргытып барысының да исемен сорап чыга.	– Исәнмесез, укытучы апа! Туп тоткан укучы үзе белән таныштыра.	КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү

2 нче этап. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.	– Балалар, бүген дәрестә без кабатларбыз, яңа тема өйрәнербез, аны ныгытырбыз. – Әгәр яхшы эшләсәгез, Күзлебүкән сезнең белән калачак. Тырышып эшлибезме?	– Әйе, тырышып эшлибез.	ШУУГ: үзмаксат кую
3 нче этап. Белемнәрне актуаль–ләштерү. Яңа материалны үзләш–терүгә ихтыяҗ тудыру. Максат: хәзерге һәм киләчәк заман фигыльләр турында элек үзләштергән белемнәрне мөстә–кыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру	– Укучылар, узган дәрестә сез нинди тема өйрәндегез? – Нәрсәләр белдегез? – Ә сез тагын нинди заман беләсез? – Соравын беләсезме? – Кушымчалары? – Ә хәзерге заманның тагын нәрсәсен өйрәндегез? – Әйдәгез, искә төшерәбез. – Ә киләчәк заманны шулай үзгәртә аласызмы? – Димәк, бүген нәрсәгә өйрәнәчәкбез? – Дәрес ахыранда без нәрсә эшли белергә тиеш? – Ә ни өчен без теманы өйрәнәбез? Ул безгә ни өчен кирәк?	Көтелгән җаваплар: *– Киләчәк заман.* *– Соравы – Нишләячәк?* *– Кушымчалары -ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк.* *– Хәзерге.* *– Нишли?* *– -а, -ә, -ый, -и.* *– Затын.* *– Мин барам.* *Син барасың.* *Ул бара.* *Без барабыз.* *Сез барасыз.* *Алар баралар.* *– Юк.* *– Киләчәк заманны зат белән төрләндерергә.* *– Киләчәк замандагы фигыльләрне зат белән төрләндерә белергә тиешбез.* *– Дөрес итеп сөйләр, дөрес итеп сөйләшер өчен.* **Үзбәя.** Үзбәя өчен критерий: сорауларның барысына да дөрес җавап бирсәгез, «5» куясыз. Хаталар булса – «4». Әйткәч кенә искә төшерсәгез – «3».	ТБУУГ: хәзерге заман белән киләчәк заманны чагыштырып, теманы, максатны формалаштыру РУУГ: кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу КУУГ: тыңлый белү, диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу
4 нче этап. Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү **Максат:** киләчәк замандагы фигыльләрне зат белән төрләндерә белүгә ярдәм итү	– Укучылар, хәзер дәфтәргә числоны, теманы язабыз. – Яшел карточкадагы биремне дәфтәрдә эшлибез. *(Бирем 2 вариантта бирелә. Беренче вариант текстан калын сүзнең төрләнешен күчерә, икенче вариант – нечкә сүзнең. Бирем: кушымчаларга сызарга.)*	Укучылар язалар. Биремне укыйлар, тәрҗемә итәләр. 2 укучы такта янында кушымчаларны гына күчерә, калганнар дәфтәрдә кара белән бирелгән сүзләрне күчереп язалар.	ШУУГ: укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру; парларда һәм төркемнәрдә эшли белү РУУГ: уку бурычларын кую; максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану

	Тактадагы эш тикшерелә. – Сез ничек уйлыйсыз, без нинди кушымчаларны күчердек? – 1 вариантта нинди сүзләр: калынмы, нечкәме? – Ә 2 вариантта? – Әйдәгез әле, калын һәм нечкә сүзләрне искә төшерик. **Ял итү.** Безнең кызлар нечкә сүзләр булалар, ә малайлар – калын. Нечкә сүз әйтсәм, кызлар баса, калынны әйтсәм – малайлар. Сүзләрнең тәрҗемәсен дә кабатларбыз. Телдән эшләү. Бергәләп *киләчәк, барачак* сүзләрен төрләндерү. Парларда эшләү. Бер–бер-сенә сүзләрне төрләндереп күрсәтәләр. 1нче вариант – укыячак сүзен, 2 нче вариант – китәчәк.	Укучылар тактага карап, тикшерәләр. Үзбәя. Үзбәя өчен критерий: 6 – «5»; 4,5 – «4»; 3 – «3», 2,1 – «2» Көтелгән җаваплар. – *Зат кушымчаларын.* – *Калын?* – *Нечкә.* Я малайлар, я кызлар торып басалар. Сүзләрнең тәрҗемәсен әйтәләр. Укытучы артыннан кабатлыйлар. Башта беренче вариант, аннан икенче вариант бер–берсенә сөйлиләр.	ТБУУГ: тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу; төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау Коммуникатив УУГ: башкаларның сөйләмен ишетеп һәм тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү; үз фикерләреңә ышандыра белү
5 этап. Яңа белемнәрне ныгыту. Максат: белемнәрне күнегүләр ярдәмендә ныгыту мөмкинлеге булдыру	– Балалар, ә без бу теманы ни өчен өйрәнәбез әле? – Ә җөмләдә без фигыльләрне кая куябыз? – Әйдәгез әле, менә мондый схема карыйк: _____ _____ барачак. – Ә менә монда нинди сораулар куеп була? – Кем? – Кая? Төркемнәрдә эшләү. Сызыклар урынына сүзләр язу. 3 җөмлә килеп чыга.	Көтелгән җаваплар: – *Дөрес итеп сөйләр, дөрес итеп сөйләшер өчен.* – *Дөрес итеп җөмләләр төзер өчен.* – *Җөмләнең ахырына.* – *Барачак кем?* – *Барачак кая?* – *Әти, әни, апа, абый.* – *Кибеткә, урманга.* Киңәшләшеп эшлиләр. Тактта янында укыйлар.	РУУГ: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү ШУУГ: күршеңә ярдәм итүдә танып белү инициативасы күрсәтү КУУГ: мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү
6 нчы этап. Яңа белемнәрне үзләштерүне тикшерү. Максат: белемнәрне тикшерүгә шартлар булдыру	– Язма эш. Тест. **1. Мин танышачак...** Б. – мын Ә. – мен В. – мон **2. Без керәчәк...** А. –быз И. –без В. – сез **3. Алар язачак...** К. – лар Р. – ләр С. – нар	Тест эшлиләр.	ШУГГ: үз мөмкинлекләреңне белү–белмәү чикләрен чамалау РУУГ: эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү КУУГ: күршең белән хезмәттәшлек итү

	4. ... Казанга барачаксың. А. Мин Ш. Син Б. Ул **5. Сез китап укыячак...** А. – сез Б. – без Ә. – сыз **6. Найди слово с ошибкой** А. Китәчәкбез П. Кайтачакбез Б. Әйтәчәкбез Слайд аша тикшерәбез. Җавапларр дөрес булса, «Бик шәп» дигән сүз килеп чыга.	Соңыннан карточкаларны алмаштырып, бер–берсенекен тикшерәләр, эшләрен бәялиләр. Бәя. Критерийлар: 6 – «5»; 4,5 – «4»; 3 – «3»	
7 нче этап. Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү. Максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату	1 нче бирем. *Язачак, беләчәк* сүзләрен зат белән төрләндерергә. 2 нче бирем. Схема буенча 3 җөмлә төзергә. __ ___ язачак. 3 нче бирем. Киләчәк заман фигыльләрне кертеп, «Казанга барачакмын» дигән текст төзергә. (4–5 җөмлә) Өй эше язылган карточкалар өләшелә.	Укучылар, теманы ни дәрәҗәдә үзләштерүләреннән чыгып, өй эшен сайлап алалар.	РУУГ: үз эшчәнлегең белән идарә итү, өй эшен сайлаганда дөрес карар кабул итү белү
8 нче этап. Рефлексия. Дәрескә йомгак ясау. Максат: дәрестә эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау	– Әгәр сез киләчәк заман фигыльне зат белән төрләндерә аласыз икән, кызгылт–сары карточканы аласыз. – Әгәр сез схема буенча җөмләләр дә төзергә өйрәнсәгез, яшел карточканы аласыз. – Әгәр сез инде җөмлә генә түгел, ә текст та төзергә өйрәнгән булсагыз, кызыл карточка аласыз. – Укучылар, бүген нишләргә өйрәндегез? Укучылар белән килешенгән (укытучы һәм укучы килешкән) билгеләр көндәлекләргә һәм журналга куела. – Балалар, ә сезнең ишеткәнегез бармы: «Бер рәхмәт мең бәладән коткара». Мин сезгә бүген чын күңелдән рәхмәт әйтәм. Сез бүген бик яхшы эшләдегез. Булдырдыгыз, рәхмәт сезгә! Күзлебүкән сезнең белән кала. Сау булыгыз!	Көтелгән җавап: *– Без бүген киләчәк замандагы фигыльләрне зат белән төрләндерергә өйрәндек.* *– Киләчәк замандагы фигыльләр белән җөмлә төзергә өйрәндек* Укучылар гомуми билге куялар. – Сау булыгыз! Рәхмәт!	КУУГ: бүтәннәрнең сөйләмен тыңлау һәм аңлау; үз фикерләреңне тулы, төгәл,ачык һәм аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау РУУГ: дөрес һәм ялгыш эшләнгән эшне аера белү; үзара контроль булдыру; үз эшчәнлекләрен бәяләү

РӘВЕШЛӘРНЕ ГОМУМИЛӘШТЕРЕП КАБАТЛАУ. РӘВЕШКӘ МОРФОЛОГИК АНАЛИЗ ЯСАУ

(6 нчы сыйныфта туган тел дәресе план-конспекты)

Гөлназ МУЛЛАГАЛИЕВА,

Актаныш районы
Пучы урта мәктәбенең югары
квалификация категорияле
татар теле укытучысы

Планлаштырылган нәтиҗә: үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Рәвешләрне төркемнәре, төркемчәләре буенча аера белү. Гомумиләштерү күнекмәсен үстерү.

Максат: рәвешләрне гомумиләштереп кабатлау һәм аларга морфологик анализ ясау тәртибен үзләштерергә ярдәм итү; белемнәрне гамәлдә куллана алу күнекмәләре булдыру; логик фикерләү, уйлау сәләтен, танып белү активлыкларын, бәйләнешле сөйләм телләрен үстерү өстендә эшләү; милли төбәк компонентларына таянып, туган якка мәхәббәт, телебезгә карата ихтирам, Р.Миңнуллин иҗатына кызыксыну, горурлык хисләре тәрбиләү.

Җиһазлау: дәреслек, класс тактасы, тестлар, компьютер, экран, презентация, проектор.

Дәрес барышы

I. Мотивлаштыру-ориентлашу.

Дөньяда иң-иң матур ил,
Ул – минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел,
Ул – минем туган телем.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
«Туган ил» дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.

Укытучы. Хәерле көн, укучылар! Бүген безнең туган тел, ана теле дәресе. Әйдәгез, бер-беребезне сәламлик әле.

II. Актуальләштерү:

2) Р.Миңнуллин шигырен уку.

Туган телемә

Асыл сүзләреңне, туган телем,
Биреп торчы миңа аз гына.
Бөтенләйгә түгел - вакытлыча,
Тик җитәрлек гомер азагыма.

Синнән алган һәрбер сүземне мин
Күз карасы кебек саклар идем.
Ул сүзләрнең затлыларын сайлап,
Дога итеп кенә ятлар идем.

Ул сүзләрне җырга әйләндергәч,
Мин кайтарып сиңа бирәчәкмен.
Исраф булмас ул сүзләрең миндә,
Җыры булыр алар киләчәкнең.

Әйтә алмыйм әле - ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне.

Укучылар, әлеге шигырь нәрсә турында? (Туган телебез турында.) Әйе, бүгенге көндә вазгыять башка,

телебезгә караш бераз үзгәрде. Ләкин без телебезне саклауда үзебездән өлеш кертергә тиешбез. Укучылар, әлеге шигырьнең авторы Р.Миңнуллин кем ул? Әлеге шәхес турында ниләр беләсез? (Ул – шагыйрь. Җырлар авторы. Ул – безнең якташыбыз.)

Укытучы. Әйе, укучылар Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин – безнең якташыбыз. Башкортстанның Илеш районында дөньяга килсә дә, балачагы, үсмер еллары үзебезнең Сөн буенда узгангамы, Актаныш районының Аккүз мәктәбендә белем алгангамы – ул Актанышны туган ягы дип саный һәм без дә, горурланып, аны якташыбыз дибез. Минем кулымда аның җырлар китабы. Ул минем өстәл китабым. Карап торышка кечкенә генә булса да, йөзләгән шигырь сыйдырган. Ә хәзер кабат шигырьгә әйләнеп кайтыйк әле. Бу шигырьдә төрле сүз төркеменә караган бихисап күп сүзләр яңгырады. Ә без сезнең белән алдагы дәресләрдә нинди сүз төркеме турында өйрәндек? Әйдәгез, әлеге шигырьдән шул сүз төркемен, ягъни рәвешләрне табыйк. Ә рәвеш турында нәрсәләр белдек?

Көтелгән җавап. Мөстәкыйль сүз төркеме булуын, төрләнми торган сүз төркеме булуын, ясалышы буенча төрләрен, мәгънәләре буенча төркемчәләрен...

Укытучы. Ә хәзер рәвеш сүз төркемен өйрәнүне тәмамлый торган соңгы дәреснең УМ формалаштырыйк әле. Димәк, укучылар бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр?

Көтелгән җавап. Рәвеш сүз төркемен өйрәнүне тәмамлый торган соңгы дәресне кабатлау дәресе дип атарга мөмкин. Без бүген рәвешләрне гомумиләштереп кабатларбыз. Үзбәя.

Укытучы. Нинди максат куярсыз?

Тема тактага һәм дәфтәрләргә языла.

III. УМ адымлап (өлешләп) чишү

«Рәвеш» темасын гомумиләштереп кабатлау.

1. Беренче бирем. Блум ромашкасы алымы.

Сораулар түбәндәгечә:

Гади сорау – Нинди сүз төркеме рәвеш дип атала?

Сорау –төпченү – Мәгънәләре ягыннан рәвешләр ничә һәм нинди төркемчәләргә бүленәләр?

Сорау –интерпретация (аңлатучы) – **теге яки бу күренешләрнең асылына төшендерү** (ни өчен?) Рәвеш нәрсәләр белән төрләнә?

Сорау –чагыштыру – Рәвеш сүз төркеменең сыйфат белән нинди уртак һәм аермалы яклары бар?

Иҗади сорау (прогноз) – Рәвешләр күбесенчә нинди әсәрләрдә очрый?

Практик сорау – Рәвеш сүз төркеменә караган сүзләр җөмләдә нинди вазифалар үти?

2. Икенче бирем. Конвертлар белән эш

1нче төркем: Рәвешнең ясалышы ягыннан төрләрен искә төшерәбез.

– Рәвешләрнең ясалышы ягыннан нинди төрләре бар? Мисал язарга.

Тамыр: аз, бик, еш, сирәк.

Ясалма: татарча, кичен.

Кушма: көнозын, бераз.

Парлы: тора-бара, тиз-тиз.

Тезмә: шул арада, тиз арада.

2 нче төркем. Нинди рәвеш ясагыч кушымчалар беләсез? (-дай,-дәй,-лата,-ләтә, -ча, -чә, - ын, -ен h.б.) Баганалап тезеп төшеп язарга, янына берәр мисал бирергә:

-ча // -чә яшьләрчә, заманча;

-лай // -ләй бушлай, бөтенләй;

-лата // -ләтә акчалата, икәләтә;

-дай // -дәй аюдай, җилдәй;

-тай // -тәй чәчәктәй, коштай;

-лап //-ләп яхшылап, еллап;

-ын // -ен кышын, кичен.

3 нче төркем: «Бер сүз белән әйт!» дип атала. Рәвешләрнең мәгънәләре берничә сүз белән бирелә, ә сез шул мәгънәне белдерә торган рәвешне бер сүз белән генә әйтегез.

(Укучылар чиратлап укый бара, рәвешне әйтә)

Үткән көн	кичә
Бик биектә	югарыда
Көтелмәгәндә	кинәт
Күз ачып йомганчы	тиз
Шушы елда	быел
Акча белән	акчалата
Татар телендә әйтү	татарча
Еш түгел	сирәк
Тау шикелле	таудай
Кичә түгел	бүген
Тиз түгел	әкрен

4. Дүртенче төркем:

Рәвеш төркемчәләрен искә төшерәбез.

– Рәвешләр нәрсәләргә карап төркемчәләргә бүленә?

– Рәвешләрнең ничә төркемчәсе бар? Ниндиләр?

Төркемчәсе	Сораулары	Мисаллар
Саф	ничек?	әкрен, салмак, тиз, кинәт
Күләм-чама	күпме?	күп, аз, байтак, шактый, еш, озак, сирәк, бераз
Охшату-чагыштыру	ничек?	олыларча, көзгедәй, русча, кешечә, җырдай, алтындай
Вакыт	кайчан?	былтыр, кичә, бүген, элек
Урын	кайда?	ерак, ары, бире, югарыда,
Сәбәп-максат	нигә? ни өчен?	юкка, бушка, тикмәгә, юри, әрәмгә, юктан гына

– Укучылар, сезнең алдыгызда үзбәя кәгазьләре. Һәр эш төреннән соң үзегезгә бәя куеп барасыз. Дәрес ахырында гомуми бәя куясыз.

Ял минуты.

Укытучы. Укучылар, без сезнең белән ял итеп алабыз. Ләкин ял вакытында берникадәр эшләп алырбыз. Бу биремнәребез «Кем зирәк?» дип атала. Сезнең алдыгызда конвертлар. Әлеге конвертларга халык авыз иҗаты әсәрләре яшеренгән. Сез аерым сүзләрдән мәкаль-әйтемнәр, табышмакларны төзергә тиеш буласыз. Төзеп бетергәч, кулларыгызны күтәрәсез.

3. Өченче бирем: «Кем зирәк?».

1 нче төркем: Булмаган җире *сирәк*, үзе *һәрвакыт* кирәк. (_____)

Алма агачыннан ерак төшми.

2 нче төркем: *Җәен* урманга патша, *кышын* кардан да *аста*. (_____)

Еракка куйсаң, якыннан алырсың.

3 нче төркем:

Бушка килә, акчага китә. (_____)

Ары йөгерде – сыйпады,
Бире йөгерде – сыйпады;
Ары килеп, бире килеп,
Бер почмакка утырды.
Тауга менүе кыен, төшүе ансат.

4 нче төркем:

Үзе **шардай,** эче **кандай,** тәме **балдай.**
Җәеп тотсаң, табактай,
Җыеп тотсаң, таяктай.
Башта уйла, аннары эшлә.

Укытучы. Укучылар, ә хәзер урыннарны алышабыз. Әлеге мәкаль-әйтемнәр һәм табышмаклардан рәвешләрне табабыз һәм асларына сызабыз. Бу эш тәмамлангач, тагын бер бирем үтисез: үзегез сайлап алып бер рәвешкә морфологик анализ ясыйсыз.

Укытучы. Ә хәзер, әйдәгез, морфологик анализ тәртибен карап чыгыйк әле. Игътибарны экранга юнәлтәбез.

Рәвешкә морфологик анализ ясау тәртибе:

1. Сүз төркеме

2. Төркемчәсе

3. Кайсы сүз төркемен ачыклавы

4. Сүз төзелеше буенча төре

5. Җөмләдәге вазифасы

2. Дәреслек белән эш. 277 нче күнегү. Җөмләләрне күчереп язарга. Рәвешләргә морфологик анализ ясарга.

Көтелгән җавап. *1. Еш — рәвеш, саф р., фигыльне ачыклый, тамыр сүз, җөмләдә — хәл. 2. Бүген — рәвеш, саф р. ,исемне ачыклый, кушма сүз, җөмләдә — хәл. 3. Һәрчак — рәвеш, вакыт р., фигыльне ачыклый, җөмләдә хәл була, ясалышы ягыннан кушма сүз. Олыларча — рәвеш, охшату-чагыштыру р. , фигыльне ачыклый, ясалма сүз, җөмләдә — хәл.4. Аеруча — рәвеш, күләм-чама р., рәвешне ачыклый, җөмләдә хәл була, ясалышы ягыннан ясалма сүз. Озак — рәвеш, саф р., фигыльне ачыклый, тамыр сүз, җөмләдә — хәл. 5. Сүзгә-сүз — рәвеш, саф р. , фигыльне ачыклый, парлы сүз, җөмләдә — хәл. 6. Бераздан — рәвеш, вакыт р. , фигыльне ачыклый, кушма сүз, җөмләдә — хәл. 7. Бертигез — рәвеш, саф р. , фигыльне ачыклый, кушма сүз җөмләдә — хәл.* Үзбәя.

4. Дүртенче бирем:

Укытучы. Хәзер, укучылар, критик фикерләү сәләтен үстерү алымнарын кулланып, төркемнәрдә эшлибез.

1 нче төркем:

Синквейн:

Рәвеш

Мөстәкыйль, 5 төрле

Төрләнми, эш-хәл билгесен белдерә, 6 төргә бүленә.

Рәвеш – төрләнми торган сүз төркеме

Мөстәкыйль.

2 нче төркем:

Диаманта:

Рәвешләр

Парлы, тезмә

(Фигыльне) ачыклый, җыйнакландыра, (сөйләмне) яңгырашлы итә

Төрләнми торган сүз төркемнәре

Билгене белдерә, сүз төркеме белән белдерелә, сорауларга җавап бирә

Асыл, нисби

Сыйфат.

3 нче төркем:

Блум кубигы белән эш

«Ни өчен». Ни өчен рәвеш мөстәкыйль сүз төркеменә карый?

«Аңлат». Аңлат: рәвешләр күбесенчә нинди сүз төркемнәрен ачыклыйлар?

«Атап әйт (әйтеп бир)». Атап әйт: төзелеше буенча рәвеш төрләрен.

«Уйла». Уйла һәм җавап бир: рәвешләр кайсы җөмлә кисәге булып **киләләр? (хәл, хәбәр, аергыч)**

«Уртаклаш». Уртаклаш, фикереңне әйт: рәвеш сүз төркеме белән сыйфатның уртак ягы нидә?

«Киңәш ит». Киңәш ит: рәвешләрне төркемчәләргә ничек аерабыз?

4 нче төркем:

«Рәвеш» темасы буенча кластер төзергә.

5 нче бирем: рәвеш темасын кабатлау буенча тест эшләү. Һәр төркемгә тестлар төрлечә төзелгән. Игътибарлы булыгыз.

Беренче төркемгә тест сораулары:

1. Рәвеш нәрсә белдерә?

а) предметның билгесен;

б) эш-хәрәкәтне;

в) эш яки хәлнең билгесен белдерә;

г) предметның санын.

2. Парлы рәвешләрне тап.
а) көн, төн;
б) көн-төн, иртә-кич;
в) бүген, быел;
г) ул елны, әллә нигә бер;

3. Кушма рәвешләрне тап.
а) бу көнне, бу елны;
б) бүген, быел;
в) алай-болай, укый-укый;
г) чиста, яхшы.

4. Рәвешнең дәрәҗәләре нигә төрле була?
а) 1;
б) 4;
в) 3;
г) булмый.

5. Охшату-чагыштыру рәвешләрен табыгыз.
а) иртәгә, яңа гына;
б) русча, сөйләшкәнчә, улыдай;
в) акча, салкынча

Икенче төркемгә тест сораулары:
1. Вакыт рәвешләрен билгеләгез.
а) бүген, кичен, иртәгә;
б) дүшәмбе, чәршәмбе;
в) җәй, көз, кыш;
г) сентябрьдә, җомга көнне.

2. Күләм-чама рәвешләрен табыгыз.
а) күп, җиңелчә;
б) җәен, кышын;
в) тиз, акрын;
г) җәй, кыш.

3. Урын рәвешләре:
а) эш яки хәлнең максатын белдерә;
б) эш яки хәлнең үтәлү урынын һәм юнәлешен белдерә;
в) эшнең үтәлү вакытын белдерә;
г) эшнең үтәлү рәвешен белдерә.

4. Сәбәп-максат рәвешләрен билгеләгез.
а) юкка, юри, тиккә;
б) юка, калын, нечкә;
в) ераккa, алга;
г) сәбәп-максат рәвешләре юк.

5. «Әнкәм бүген матур бер төш күргән» (И.Юзеев) җөмләсендә бүген рәвеше нинди җөмлә кисәге булып килгән?
а) аергыч;
б) хәл;
в) тәмамлык;
г) ия.

Өченче төркемгә тест сораулары:
1. Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?
а) Кайсы? Кайдагы?
б) Ничек? Кайда?
в) Ничә? Никадәр?
2. Рәвешнең ничә төркемчәсе бар?
а) 5;
б) 6;
в) 4.
3. Рәвеш ясалышына карап ничә төрле була?
а) 5;
б) 6;
в) 4.
4. Ясалышы ягыннан бу нинди рәвешләр? Татарча, аюдай.
а) Кушма;
б) Ясалма;
в) Тамыр.
5. Рәвеш күбрәк нинди сүз төркеменә ияреп килә?
а) Исем;
б) Сыйфат;
в) Фигыль.

Дүртенче төркемгә тест сораулары:

1.Кушма рәвешләр ничек языла?

а) Аерым,

б) Сызык аша,

в) Кушылып

2.Сәбәп-максат рәвешләренең сораулары?

а) Ничек?

б) Нигә?

в) Кайчан?

3.Охшату-чагыштыру рәвешен билгеләргә.

а) Шактый,

б) Тикмәгә,

в) Олыларча

4.Рәвеш нинди җөмлә кисәге булып килгән?

Ул урамнан тиз-тиз бара.

а) Тәмамлык,

б) Хәл,

в) Аергыч

5.Мәгънәле кисәкләргә дөрес таркатылган сүзне билгеләргә.

а) Алты-н-дай,

б) Олы-лар-ча,

в) Ак-ча-ла-та

IV. Рефлексия, бәяләү

1. Өй эше бирү:

1. Өй эшен дә, шушы тема белән бәйләп, ярымиҗади һәм иҗади итеп бирәм.

1) 280 нче күнегү. Текстны күчереп язасыз. Рәвешләрнең астына сызасыз, берсенә морфологик анализ ясыйсыз.

2) Рәвешләр кергән төрле халык мәкальләре табып язасыз. Берсенә морфологик анализ ясыйсыз.

3) Рәвеш кергән бер татар халык мәкален укырлык итеп, ребус төзисез.

2. Рефлексия.

Укытучы.Укучылар, дәресебезне йомгаклыйбыз. Бүгенге дәресебезгә нинди уку мәсьәләсе куйган идек? Ниләр башкардык? Максатларыбызга ирештекме?

Көтелгән җавап. Без бүген дәрестә рәвеш сүз төркемен кабатладык. Төрле структуралар буенча эшләдек. Максатыбызга ирештек дип уйлыйм.

Туган тел турында шигырь укыдык.

Тест ярдәмендә белемебезне тикшердек.

Халык авыз иҗаты әсәрләре – мәкаль-әйтемнәрдән рәвешләр эзләдек.

Укытучы. Укучылар, ә тормышта рәвешне кулланабызмы? Кайларда кулланабыз?

Көтелгән җавап. Рәвешләр сөйләмебездә, халык авыз иҗатында: мәкальләрдә, әйтемнәрдә, табышмакларда да киң кулланыла.

3. Үзбәя. Теманы аңлау дәрәҗәләренә карап, билгеләрне үзләре куя. Укытучының рәхмәт сүзе.

Укытучы. Үзегезнең эшчәнлегегезне ничек итеп бәялисез? Гомуми билгегезне карточкага куясыз.

Дәресебез тәмам. Рәхмәт. **ТИМ ЧИР ясыйк әле.** Бүгенге дәресебез ничек узды? Яхшы эшләдекме?

– Сезне киләчәктә телебезне үз итүче, яратучы кешеләр булып калуыгызны телим. Телебезне яратыгыз, саклагыз. Телебез яши икән, милләтебез дә яши дигән сүз.

– Дәрес тәмам, чыгарга мөмкин.

РЕНАТ ХАРИСНЫҢ «САБАНТУЙ» ПОЭМАСЫ

(11 нче сыйныф татар төркемендә татар әдәбияты)

Алсу ХӘМИДУЛЛИНА,

Кайбыч районының Олы Кайбыч урта гомуми белем бирү мәктәбе - цифрлы һәм гуманитар профильле белем бирү үзәгенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Дәрес тибы: яңа белемнәр үзләштерү дәресе.

Дәреснең максатлары:

1. *Дидактик:* Ренат Харисның Сабантуй» поэмасын үзләштерү, иҗатының үзенчәлекләре буенча күзаллау булдыру.

2. *Эшчәнлек ягыннан:* күзәтү аша текстны анализлау күнекмәләре формалаштыру, әсәрдә күтәрелгән тема, проблемаларны билгеләү, тел-стиль чараларына күзәтү ясау, дәреслек, сүзлек, терминнар, рәсемнәр белән эшләү алымнарын камилләштерү.

Көтелгән нәтиҗәләр:

Шәхси: гореф-гадәтләребезне белү, аларның кыйммәтләрен аңлау, әхлакый сыйфатлар формалашу, тарихыңны өйрәнүгә кызыксыну уяну.

Метапредмет нәтиҗәләр:

Регулятив УУГ: дәрескә куелган максатны аңлау, үз нәтиҗәләреңне бәяли белү, укучылар уку мәсьәләсен чишү өчен кирәкле эшчәнлек алып бару мөмкинлеге алачак.

Танып белү УУГ: дәреслек белән эшләү, укытучының сорауларына җавап бирү, гомумиләштерү, нәтиҗәләр ясау, укучылар укытучы җитәкчелегендә анализ ясау мөмкинлеге алачак, бирелгән мәсьәләләрне чишү юлларын табачак.

Коммуникатив УУГ: диалог алып баруга әзерлек, коллективта үз фикереңне җиткерә белү, укучы башка укучыларның фикерләрен тыңлау, аларга карата үз фикерен белдерә алу мөмкинлеген алачак, фикерен телдән төгәл һәм дөрес итеп әйтү турында уйлаячак.

Предмет УУГ: Ренат Харисның «Сабантуй» әсәре турында белү, тел-сурәтләү чаралары турында искә төшерү, тикшерү биремнәрен үтәү.

Кирәкле материаллар: 11 нче сыйныф татар әдәбияты дәреслеге (Ф.Г.Галимуллин, Л.И.Минһаҗева, Л.К.Хисмәтова авторлыгында рус мәктәбендәге татар балалары өчен дәреслек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016 ел), А.Тимергалин. «Миллият сүзлеге», «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» , рәсемнәр, проектор, тикшерү карточкалары. display?v=pq8ivu8ka21), ZipGrade – мобиль кушымтасы, кроссенс өчен рәсемнәр, дәрескә керү билетлары, үзбәя өчен «Уңышлар карточкасы».

Дәрес барышы

1. Уку эшчәнлегенә мотивация тудыру.

Укытучы. «Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан», – дигән Туфан Миңнуллин. Сез бу фикер белән килешәсезме?

Укучы. Әйе, Туфан ага милләтебез белән горурланырга чакыра, үзебезне хөрмәт итмәсәк, башкалардан кимсенеп яшәсәк, милләт булудан туктаячакбыз ди.

2. Актуальләштерү.

Укытучы. Һәр халыкның аны дөньяга таныткан бер үзенчәлеге була. Мәсәлән, Борынгы Греция үзенең Олимпия уеннары белән тарихка кереп калган. Укучылар, ә сез ничек уйлыйсыз, татарларны дөньяга танытучы үзенчәлек ул нәрсә икән?

Укучы. Ул – татарның Сабан туе.

Укытучы. Димәк бүген дәресебезнең темасы нинди булачак?

Укучы. Сабантуй турында сөйләшәбез,

Укытучы. Темадан чыгып нинди максатлар куябыз.

3. Уку максатын кую.

Укучылар.

1. Сабантуй турында белемнәрне искә төшерербез, әһәмиятен ачыкларбыз.
2. Сабантуй турында яңа белемнәр алырбыз.
3. Сабантуй турында язылган яңа әсәр белән танышырбыз.

Алдыгызда бәяләү карталарына һәр этапта үзбәя куярга онытмагыз.

	Эш төре	Билге (5 баллы шкалада)
1	Дәрес темасын билгеләү	
2	Дәрес максатын билгеләү	
3	Кластер (төркемдә эш)	
4	Сурәтләү чаралары буенча индивидуаль эш (таблица)	
5	Парларда эш	
6	Үземнән канәгатьлек хисе	
7	Уртача билге	

Ә нәрсә соң ул Сабантуй? Бу сорауга җавап бирү өчен, кластер алымын кулланып, Сабантуйга туры килгән төшенчәләрне языйк.

Сабантуй – милли бәйрәм, гореф-гадәт, уен-көлке чарасы, спорт уеннары.

Ә хәзер аңлатмалы сүзлектән бу сүзнең мәгънәсен карап китик. (Сабантуй (сабан – плуг, туй – свадьба, ягъни сабан туе – свадьба плуга, сабан бәйрәме мәгънәсендә) – искиткеч күңелле, шау-гөр килеп торган, бар халыкны бер мәйданга туплаучы әлеге бәйрәмнең тарихы бик борынгы төрки бабаларыбызга барып тоташа.)

Укытучы. Бу бәйрәм күп кенә язучы шагыйрьләребез, рәссамнарыбыз иҗатында да урын алган. Кайсыларында күрергә мөмкин.

– Гомәр Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» повесте

– Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар»

– Фатих Хөсни «Йөзек кашы»

– Л.Фәттаховның «Сабантуй» картинасы

4. Эшләү проектын төзү.

Алар һәркайсы Сабантуйны үзенчә сурәтли. Бүген укылачак «Сабантуй» әсәренең нинди үзенчәлеге бар икән?

Укучы. Ул 7 бүлектән тора, жанры буенча – поэма.

Укытучы. Укучылар һәр Сабантуй нәрсәдән башлана?

Укучы. Сөлге җыюдан.

Укытучы. Ни өчен сөлге җыйганнар?

Укучы. Ак сөлге – халкыбызның саф күңелен күрсәтүче символ, аның әләме.

Укытучы. Ә йомырка җыю нәрсәдән калган?

Укучы. Язгы чәчү тәмамлангач, җиргә йомырка тәгәрәтү йоласы башкарылган, бөртекләр эре, тере, йомры булсын дигән теләк белән. Йомырка түгәрәк, җир йөзенең символын да белдергән булуы мөмкин. Тереклек чыганагы.

Укытучы. Сөлге җыю йоласының вазифасы нидән гыйбарәт дип уйлыйсыз?

Укучы. Өйдән өйгә кереп, халыкны бәйрәмгә чакырганнар. Безнең якта да бу йола яшәп килә. Авыл яшьләре бу йоланы бик теләп башкаралар. ТНВ каналы төшергән видеоны карап китү

Сылтамасы:

https://yandex.ru/video/touch/preview/?text=ләбиб%20лерон%20видео&path=wizard&parent-reqid=1644394390771318-937879200046394841 7-sas2-2384-sas-l7-balancer-8080-BAL-5120&wiz_type=vital&filmId=15680120959457543505

5. Яңа материалны үзләштерү.

Текст белән таныша башлау.

Укытучы. Әйе. Беренче бүлек ничек аталган дип уйлыйсыз?

Укучы. Беренче бүлек Чакыру дип атала.

Укытучы. Әйе, поэманың юлларын укыйк һәм авторның аларга нинди мәгънә салуын билгелик.

Биеп барган ат тоягы – иң гаҗәеп кыңгырау. (Уятып, сискәндереп җибәрер өчен, игътибар җәлеп итү, кыңгырау белән чагыштырыла.)

Һәр йөрәккә җыру булып барып керә тавышы. (Җыру иске төрки телдә, Сабантуйның борынгы бәйрәм икәнен ассызыклый, күңелгә җыр кебек үтеп керә.)

Күңел бит ул асылында җирнең нәкъ үзе кебек. Кайсы яклары белән охшаш? (Җиргә – орлык, күңелгә өмет, дәрт салына, ул шытарга, үсәргә дулкынланырга тиеш, бөтен әйберен алгач та яши алырга тиеш.)

Укытучы. Сабантуйны автор нәрсә белән чагыштыра?

Укучы. Ул – мәгарә капусы.

Укытучы. Аңлатмалы сүзлектән мәгарә һәм капус сүзләрен эзләп табыйк. Укучы. Мәгарә – тау куышы, өн. Капус – капка.

Укытучы. Ни өчен мондый чагыштыру?

Укучы. Чөнки Каюм Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы» әсәрендә мәгарәдә елга бер мәртәбә генә ачылып, ел буена җитәрлек гыйлем алып чыгып булган, Сабантуй да, елга бер генә булып, җитәрлек көч, хис җыеп калырга кирәк.

Укытучы. Самавырга кайнау кайда? Сабантуй кайный инде.

Укучы. Бу охшату мәйданны күз алдында тотып әйтелә. Халык күп булу сәбәпле, ул кайнаган кебек.

Укытучы. Хәзер текстта сурәтләү чараларын билгели алу өчен, таблицага мөрәҗәгать итәбез. Индивидуаль биремне эталон буенча иптәшебез тикшерә һәм билге куя.

Мисаллар	Сурәтләү чарасы
Биеп барган ат тоягы – Иң гаҗәеп кыңгырау	
Күңел бит ул асылында Җирнең нәкъ үзе кебек	
Ачык капкаларда балкып	
Самавырга кайнау кая? Сабантуй кайный инде.	

Мисаллар	Сурәтләү чарасы
Биеп барган ат тоягы – Иң гаҗәеп кыңгырау	метафора
Күңел бит ул асылында Җирнең нәкъ үзе кебек	чагыштыру
Ачык капкаларда балкып	эпитет
Самавырга кайнау кая? Сабантуй кайный инде.	метафора

6. Беренчел ныгыту этабы.

Укытучы. Әсәрне язучы авторга игътибар итәбез. Ул кем? Дәреслекнең 227 нче битеннән карап китик.

Укучы. Күренекле җәмәгать эшлеклесе, халык шагыйре, публицист, 40 тан артык поэма, дистәгә якын шигъри цикллар, кантата, ораториләр авторы – Ренат Харис.

Укытучы. Аның әсәрләренең исемнәренә генә игътибар итик әле.

Укучы. «Идегәй» поэмасы, «Йосыф кыйссасы», «Гармунчы», «Ак сөлге», «Чулпы» әсәрләре.

Укытучы. Нинди нәтиҗә ясап була?

Укучы. Ул үзенең иҗатында татар халкының тарихына, йолаларына, гореф-гадәтләренә, милли үзенчәлекләренә игътибар итә.

7. Ныгыту, күнекмәләр формалаштыру этабы.

Укытучы. «Сабантуй» поэмасының Ат чабышы бүлегендә кемгә мөрәҗәгатен күрәбез.

Укучы. Әй Дәрдемәнд, безнең Сабантуйга кил!

Бурзай атлар ялын йолка җәйге җил, –

дигән юллар белән Дәрдемәндкә мөрәҗәгать итә.

Укытучы. Кем ул Дәрдемәнд, ни өчен нәкъ аңа эндәшә?

Укучы. XX гасыр башы шагыйре, алтын приисклары хуҗасы, меценат, татар милләте өчен борчылып, кайгырып яшәгән әдип.

Укытучы. Әйе, Дәрдемәндкә мөрәҗәгате юкка түгел, аның

Булат такмый кәмәрләгән конан бил,

Тази атлар җалын какмый биә җил.

Өшәнләнде даланың толпар аты,

Урал шоңкарының сынды канаты.

Конан – нәзек.

Тази – йөгерек.

Биә – бии,–

дигән шигыренә карата җавап яза ул. Нинди фикер әйтергә тели?

Укучы. Әй Дәрдемәнд, безнең Сабантуйга кил!

Бурзай атлар ялын йолка җәйге җил,

Атлар уза – куба дала тузаны,

Җылар җир юк киләчәкне кызганып, –

дип киләчәгебез өметле, иле өчен, халкы өчен җан атып яшәүче батыр егетләребез булганда, без яшәрбез дип оптимизм тудыра.

Укытучы. Сабантуй батыры дип кемнәр атала?

Укучы. Милли көрәштә җиңеп, тәкә алган батырларны атыйлар?

Укытучы. Ә Ренат Харис поэмасында ничек әйтелгән?

Укучы. Ул – менә сезнең каршында

җыелган эшчән халык.

Алар – сабан батырлары,

Бәйрәмнең олы түренә

Чыкты саналучылар -

Терлекчеләр, савучылар,

Мул иген алучылар.

Укытучы. Ни өчен аларга сабан батырлары дип әйтә.

Укучы. Савымчылар, терлекчеләр, кыр батырларын. Алар булмаса, икмәк үсмәс, сөт савылмас, ит пешмәс иде.

Укытучы. Ә сез алардан тыш нинди һөнәрләрне әһәмиятле дип уйлыйсыз. Килеп туган пандемия вазгыяте моны ачык билгеләргә ярдәм итте.

Укучы. Табиблар, укытучылар, элемтә хезмәткәрләре, журналистлар, банк хезмәткәрләре, программистлар һ.б.

Укытучы. Татарстан Республикасында 2022 елны Цифрлаштыру елы дип игълан ителүен барыбыз да беләбез, быел чыгарылыш сыйныф укучылары буларак, һөнәр сайлаганда ныклы ышаныч һәм акыл белән эш итүегезне теләп калабыз.

8. Рефлексия этабы.

Укытучы. Ә автор фикере буенча, Сабантуйның әһәмияте нидә? Парларда бу сорауга җавапларны текстан табабыз һәм аңлатырга әзерләнәбез.

Көтелгән җавап:

Сабан туе – ул бер көнлек,

Аның рухы дәвамлы…

Атна, ай, ел буена ул

Көчле итә,

Дәртле итә,

Тырыш итә гавамны

Гавам – халык массасы.

1. Ул халыкны тырыш итә, тырыш хезмәт яхшы бәяләнә, җитәкчеләр, авыл халкы арасында чыгып бүләк алу – үзең өчен дә, гаиләң өчен дә горурлык.
2. Дәртле итә – дәрт ул алдагы эшләрне эшләргә теләк, ышаныч уята,
3. Көчле итә – үзенең көчен сынап карый, көчсезрәк булса, тагын да яхшырак әзерләнергә стимул була.

Бу сыйфатлар милләтемә нигә кирәк? Югалмасын, алга барсын, башкалар алдында оятка калмасын, киләчәккә тапшырсын өчен, башкалар алдында түбәнсенмәсен, үзен лаеклы тотсын өчен кирәк.

Укытучы. Автор нәрсә әйтергә тели?

Ренат Харис Сабантуйның елга 1 тапкыр була торган күңел ачу чарасы булып кына калуын теләми. Тарихыбызны, матур сыйфатларыбызны, милли үзенчәлекләребезне саклап, киләчәк буынга тапшыруыбызны тели. Россия Федерациясендә 2022 ел Халыклар мирасы елы дип игълан ителде. Бу эшне һәр кеше үзеннән башларга тиеш дип саныйм мин.

Әйдәгез, дәрес башында башлаган кластерыбызны тулыландырып, бүгенге дәрестә өйрәнгән төшенчәләрне язып куйыйк. *(Кластер тулыландырганда, Сабантуй җыры тыңлана.)*

Халыкның тарихы, көче, өмете, бердәмлеге, дуслыгы, горурлыгы

Бәяләү карталарына билгеләрне куеп җыябыз, өй эше алабыз.

1. Р.Харисның «Сабантуй» поэмасын укырга.
2. «Мин авыл җирлеге рәисе (район башлыгы, республика президенты) булсам, Сабантуйны ничек үткәрер идем» темасына фикерләреңне язарга.

Сабантуй тарихы хакындагы тарихи язмаларны барлап чыгыш әзерләргә.

«Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналлары редакциясе
ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы
Бөтендөнья татар конгрессы

«АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫ – 2022»

бәйгесен игълан итә

I этап

Иҗади эш язып җибәр
Напиши эссе
(1 февральдән 20 июньгә кадәр)
Эшең magarif-uku.ru сайтында басылып чыккач та, «Мәгариф» редакциясеннән электрон яки басма сертификат җибәрүләрен сора.

II этап

Дәрес яки дәрестән тыш эшчәнлек конспекты язып җибәр
Отправь разработку урока или внеурочной деятельности
(1 июльдән 20 августка кадәр)

III этап

Ачык дәрес күрсәт
Проведи открытый урок
(Сентябрь аенда)

Конкурста I, II һәм III дәрәҗә Дипломга ия булучыларга акчалата премияләр бирелә:

I урын – 50 мең сум;
II урын – 30 мең сум;
III урын – 20 мең сум.

Шулай ук **5 номинация** буенча **10 ар мең** сумлык кызыксындыру премиясе дә карала.

Беренче тапкыр рус һәм татар тәрбиячеләре өчен махсус номинация:

«Иң яхшы тәрбияче – 2022» – 25әр мең сум

Конкурс Нигезләмәсе белән https://magarif-uku.ru/tt/category/avyl-ukytuchysy-2022/ сайтында таныша аласыз.

Белешмәләр өчен: (843) 222-06-09 magarif.aul@mail.ru